ЧЫН МИРАС

ФӘННИ-ПОПУЛЯР,
ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ

№1 / гыйнвар 2013



ТАРИХИ, ӘДӘБИ, МӘДӘНИ МИРАС, ТӘНКЫЙДИ ФИКЕР, ЗАМАН ӘДӘБИЯТЫ, ЯҢАЧА КАРАШ

«Меңъеллык Казан».
Аглая Липина эше.
Шамаил. Милли чигеш.
1999 ел

ЧЫН МИРАС
ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ
№1 (13) / гыйнвар 2013

Журнал «ТАТМЕДИА» ААҖ тарафыннан гамәлгә куелды.

2012 елның май аеннан чыга.

Индекс 54132

Баш мөхәррир —
Илфак Мирза улы ИБРАҺИМОВ

Баш мөхәррир урынбасары — җаваплы сәркатип —
Рамил Ханнанов

Редакция советы:
Марсель Әхмәтҗанов
Разил Вәлиев
Резеда Ганиева
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Дания Заһидуллина
Илдус Заһидуллин
Данил Ибраһимов
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Данил Мостафин
Рөстәм Мөхәммәдиев
Рафыйк Мөхәммәтшин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Индус Таһиров
Рамил Ханнанов
Рафаил Хәкимов
Әнвәр Хуҗиәхмәтов

Иҗат төркеме:
Илдус Заһидуллин
Диләрә Нәүрүзова
Дания Фәйзуллина
Ленар Гобәйдуллин
Ренат Миңнегалиев
Алия Мөбарәкшина

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Телефон: (843) 222-09-83 (17-90)
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

Заказ № С-79
Тираж — 2000 данә.
Формат 70 x 108 1/16
Журнал айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды: 10.01.2013

Эчтәлек

3 **Баш мөхәррир сүзе**

ТАРИХ

7 **XIX гасыр ахыры — XX йөз башы төрек-татар багланышлары.**
Исмәгыйль Төркуглы

18 **Казан ханлыгында төрки ислам мәдәнияте.**
Зәки Вәлиди Туган

34 **Газиз Гобәйдуллин хезмәтләрендә татар халкы тарихы.**
Диләрә Галиуллина

42 **Бабаларым мирасы.**
Альта Мәхмүтова

53 **Сагышлы мирас.**
Илдар Юзеев

СӘНГАТЬ

56 **Нинди иде безнең яшьлек!**
(Ринат Таҗетдиновка 75 яшь)
Әзһәр Шакиров

61 **Альтернатив... яки кинәсез кино.**
Әхтәм Зарипов

68 **Үткәнне сагыну һәм киләчәккә өметләр**
(«Туран» фондына 20 ел).
Розалина Шаһиева

ӘДӘБИЯТ

78 **«Төрки халыклардан мин берүзем...»**
Ренат Харис белән
Илдус Заһидуллин әңгәмәсе

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-49398 нче таныклык белән теркәлде.

Бәясе ирекле

Мәкалә авторларының фикере редакция хезмәткәрләренең фикере белән туры килмәскә дә мөмкин.

Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә.

Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.

Бу санда авторларның, А.Эшкинин, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры, «Туран» фонды архивларыннан фоторәсемнәр файдаланылды.

Тышлыкның 1 нче битендә — Спасс манарасы.
А.Эшкинин фотосы;
4 нче битендә — Шарф һәм сумка комплекты. Милли чигеш.
Лариса Чубукова эше.
«Туран» фонды коллекциясеннән

«ТАТМЕДИА» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

«ИСТИННОЕ НАСЛЕДИЕ»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

82 **Бәкер сазы.**
Ренат Харис

86 **Шәрекъ Ренессансы.**
Резеда Ганиева

91 **Тукай энциклопедиясенә.**
Резеда Ганиева

94 **Батырша.**
Фәүзия Бәйрәмова

102 **«Мин беренче чәчәкләрне эзлим...»**
(Газизә Сәмитованың тууына 150 ел).
Рәдиф Гаташ

106 **«Лаеклы булыйк без бу якты заманга...»**
(Хәйдәр Гайнетдин иҗатына күзәтү).
Нурфия Юсупова

109 **Шигырьләр.**
Хәйдәр Гайнетдин

112 **Урманчы кызы.**
Фәнис Яруллин

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР

118 **Иле барның теле бар.**
Гүзәл Нәбиуллина, Лилия Гыйләҗева

120 **Тарих сәхифәләреннән.**

Яңа китаплар.
Ләйсән Бәдретдинова

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Безнең журналга сез
54132 ИНДЕКСЫ
буенча һәр элемтә бүлегендә языла аласыз.

БАШ МӨХӘРРИР СҮЗЕ

Республикабызда тарихи һәм мәдәни мирасны саклау елында гамәлгә куелган «Чын мирас» журналы, уртак тырышлыгыбыз нәтиҗәсендә, кыска гына вакыт эчендә чын-чынлап тернәкләнеп китте… Журналыбызның барыр юлы, багланышы ачыкланды. Ул, исеменнән үк күренгәнчә, халкыбызның гасырлар дәвамында тупланган тарихи, әдәби, мәдәни мирасын замандашларыбызга җиткерүне иң олуг максаты итеп куя да.

Бүгенге югары технологияләр чорында, мәгълүмат кыры электрон чыганаклар челтәрендә шыплап тутырылган мәлдә, традицион басма өр-яңа булуга карамастан, замандашыбызны кайсы ягы белән кызыксындырыр соң, дигән сорау туар… Без ул хакыйкатьне дә онытмыйбыз. Журналның электрон чыгарылышына да нигез салына. Matbugat.ru челтәрендә аның беренче үрнәкләре инде дөнья күрде… Ә традицион басма рәвеше ул безнең күпсанлы галимнәребез, әдипләребез, сәнгать белгечләре өчен милли мирасыбызны танытучы мәйдан, трибуна да булып тора. «Чын мирас» мирасның үзен дә, мирас турындагы фәнни-популяр әдәбиятны да пропагандалауны колачлый. Бер сүз белән әйткәндә, журнал киң катлау укучыларның ихтыяҗларына җавап бирә һәм бирәчәк…

Журналыбыз республикадагы Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, халыкара оешмалар, фәнни үзәкләр белән дә, чит илләрдәге халкыбызның тарихын, мәдәниятен өйрәнүче галимнәр белән дә хезмәттәшлек урнаштыра. Бүген журнал редакциясендә дистәләрчә галимнәр, әдипләребезнең өр-яңа язмалары басылып чыгу сәгатьләрен көтеп ята… «Милли идея», «И таш, сөйлә», «Тукай энциклопедиясенә», «Дөньяда сүзем калыр», «Күләгәдә калган шәхесләр» һ.б. даими рубрикаларда милли мирасыбызны укучыларыбызга җиткерәбез. Журнал Татарстанда һәм чит өлкәләрдә яшәүче милләттәшләребезнең төбәкләре тарихы, гореф-гадәтләре, йола-традицияләрен яктыртуга да урын бирә…

Әйе, «Чын мирас» үзенең киләчәген ачык күзаллый.

«Ә укучыларыгыз бармы соң?» — дигәндә: «Бар!» — дибез… Заман — зыялы затлар заманы… Һәрхәлдә, киләчәк зыялы яшьләребез кулында… Үз тарихын, үз халкының яшәү, акыл тәҗрибәсен үзләштергән инсан гына гомуми кешелек ирешкән кыйммәтләрне үзләштерә ала. Бу хакыйкатьне аңлаучылар күп, шулай булгач, безнең белән хезмәттәшлек итүчеләр дә, укучыларыбыз да көннән-көн күбәер дигән ышанычта калабыз.

Бергә булыйк, бердәм булыйк.

Яңа еллар мөбарәк булсын!

Илфак Ибраһимов



ТАРИХ

Гомерем минем — яну,
мәңгелек ут!
Синең гомерең
Тарих өчен бары бер минут.

Илдар Юзеев

Лаләле мәчете.
Истанбул

www.webpark.ru

XIX ГАСЫР АХЫРЫ – XX ЙӨЗ БАШЫ ТӨРЕК-ТАТАР БАГЛАНЫШЛАРЫ

ИСМӘГЫЙЛЬ ТӨРКУГЛЫ,
Мәрмәрә университетының Тюркология институты докторы

ИСТАНБУЛНЫҢ ПРЕМЬЕР-МИНИСТРЛЫК АРХИВЫНДА XIX ГАСЫР АХЫРЫ – XX ЙӨЗ БАШЫ ТӨРЕК-ТАТАР БӘЙЛӘНЕШЛӘРЕ ТУРЫНДА ШАКТЫЙ ГЫНА ДОКУМЕНТЛАР БАР. АЛДАГЫРАК ЧОРЛАРГА КАРАГАН ДОКУМЕНТЛАР БИК АЗ САНДА САКЛАНГАН. БЕЗНЕҢ МӘКАЛӘБЕЗДӘ СҮЗ РОССИЯДӘ ЯШӘГӘН ТАТАРЛАРНЫҢ АВЫР ВАКЫТЛАРДА ГОСМАНЛЫ ДӘҮЛӘТЕНӘ СЫЕНУЛАРЫ, ИКЕ ХАЛЫК АРАСЫНДАГЫ БАГЛАНЫШЛАР ТУРЫНДА БАРА.

Әйтергә кирәк, Госманлы дәүләте татарларның теләкләрен мөмкин булган юллар белән тормышка ашырырга тырыша. Хаҗга баручыларга матди ярдәм күрсәтелә, күченеп килгәннәргә — җир, бушлай белем алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәтенә алынырга теләк белдерүчеләргә эш, бернинди яшәү шартлары булмаган ярлыларга айлык хезмәт хакы бирелә. Петербургтагы Госманлы иле консулы ярдәме белән татарларның Россия хөкүмәте җитәкчелеге тудырган проблемаларын чишү юллары да карала. Нигездә, әлеге тарихи процесс (татарларның Төркиягә күченүе) һәрвакыт хәрәкәттә була, 1991 елдан соң да татарлар элеккеге СССР өлкәләреннән Төркиягә күченәләр, белем алыр өчен килгәннәренең бер өлеше һаман да ата-бабаларының эзләреннән йөри. Мәкалә, беренче чиратта, шушы материалларга нигезләнеп языла.

Бу язмабызда укучыларны Идел-Урал төбәге татарларының Госманлы дәүләтенә күченүләре, белем алу я башка сәбәпләр белән килгәннәрнең эшчәнлеге, аерым шәхесләрнең тор-

мыш юллары һәм кылган гамәлләре, аларның автобиографияләре, төрек дәүләте, мәгариф һәм мәдәнияте үсешенә керткән өлешләре, Госманлы зыялыларының татарлар хакындагы фикерләре белән таныштырырга уйлыйбыз. Әлеге хезмәт хәзергә бер тәҗрибә сыйфатында булып, киләчәктә яңа мәгълүмат һәм чыганаклар табылып, төрек-татар багланышлары тарихы тагын да тирән эчтәлектә язылыр дип өметләнәбез.

ИДЕЛ-УРАЛДАН ТӨРКИЯГӘ КҮЧЕНҮ ХӘРӘКӘТЕНӘ КҮЗӘТҮ

1783 елда Кырым ханлыгы Россия империясе тарафыннан яулап алына, Кавказда, Кырым, Төрекмәнстанда Россия йогынтысы көчәя. Нәтиҗәдә, Кавказ, Кырым төбәкләренә мөселман халыкларының ватаннарыннан күпләп күченүе башлана. Архив материалларыннан күренгәнчә, башта Идел-Урал төбәгеннән күчеп килүчеләр бик аз була. Ә йөз елдан соң бу төбәктән Госманлы империясенә килеп урнашучылар саны күп мәртәбәләр арта.

Документлар шуны раслый: татарларның күченүе Россия империясе хакимиятенең сәяси-дини басымы көчәю, иҗтимагый-икътисади тормыш шартлары кыryслану, 1891-1892 елларда Самара өлкәсендә һәм башка төбәкләрдә булган ачлык, 1853-1856, 1877-1878 еллардагы рус-төрек сугышлары нәтиҗәсе, шулай ук ирекле яшәргә теләү һәм белем алу кебек күп кенә сәбәпләр белән аңлатыла. XIX гасырның икенче яртысында патша самодержавиесенең мөселман мәктәп-мәдрәсәләренә басымы, рус телен мәҗбүри дәрес буларак укытырга җыенулары һәм 1891 елда муллаларның рус теленнән мәҗбүри сынау бирүләре турында канун кабул ителү, миссионерлар алып барган чукындыру сәясәте, патша Александр III һәм П.А.Столыпинның реформалары, 1897 елгы халык санын алу һәм башка вакыйгалар да мөһим роль уйный.

Мөһаҗирләрнең истәлекләрендә күченү сәбәпләре итеп шулай ук патша хөкүмәтенең мөселман мәктәп-мәдрәсәләрен ябарга, Коръәнне хаталар белән яңадан бастырырга җыенуы кебек фактлар күрсәтелә. 1892 елда Мәккә һәм Мәдинә шәһәрләренең 40 галим-голамәсе тарафыннан Истанбулга, хәлиф исеменә, гариза җибәрелә. Анда Россия мөселманнарының хәле, хөкүмәтнең миссионерларга матди ярдәм итүе, миссионерларның мөселманнарга карата кылган гамәлләре тәфсилләп аңлатыла. Галим-голамәләр үзләренең мөрәҗәгатендә хәлифтән Россиядәге дин кардәшләренә ярдәм итүен сорыйлар [1]. Казанлы Җәләлетдин Мөхәммәтов һәм аның берничә иптәше Россия мөселманнарының хокуклары чикле булуын һәм ирек эзләп Истанбулга китүләрен ассызыклый.

Татарларның Госманлы дәүләтенә күченү сәбәпләреннән иң игътибарга лаеклысы 1897 елның 28 гыйнвары көненә игълан ителгән халык санын алу була. Мөселманнар халык санын алудан куркалар, үзләрен христианнар исемлегенә кертерләр дип уйлап, Идел-Урал төбәгенең кайбер авыл җәмгыятьләре Госманлы дәүләтенә күченергә дигән фикергә киләләр. Халык санын алуга әзерлек барышында һәм халык санын алганда Казан губернасының куркып калган мөселманнары хакимияткә каршы чыга [2]. Татар язучысы Мәхмүт Галәү (1886-1938) «Мөһаҗирләр» исемле тарихи романында 1897 елгы халык санын алудан куркып, Төркиягә күченгән татарларның авыр, фаҗигале хәлен тасвирлый.

Кырым сугышыннан соң Госманлы дәүләтенә килүче мөһаҗирләр саны күпкә арта, шуңа күрә 1859 елда мөһаҗирләрнең дәүләт комиссиясе төзелә, бирелә күченеп килүчеләрне теркәү, исәпкә алу оеш-

тырыла. Габдерәшид Ибраһимов та Кырым сугышыннан соң татарларның Төркиягә күченүләре турында яза [3]. Кызганычка каршы, әлеге махсус дәүләт комиссиясе төзелгәнче, Идел-Урал төбәгеннән килгән мөһаҗирләр турында мәгълүмат юк диярлек, чөнки алар дәүләт ярдәме алу өчен теркәлмәгән булалар [4]. Без солтан Габделхәмит һәм аның ярдәмчесе Габделгазиз идарә иткән вакыттагы, ягъни 1881 елгы архив документлары белән таныш. Әлеге тарихи чыганакта мөһаҗирләрнең саны, күчену буенча дәүләт комиссиясенең эш нәтиҗәләре күрсәтелгән. Ләкин күченгән халыкның гомуми санын күрсәткән документ сакланмаган. Шуңа күрә 1859 елга кадәр килгән мөһаҗирләрнең Россиядә яшәү урыннарын һәм күченү сәбәпләрен төгәл әйтүе кыен.

Архив документларыннан күренгәнчә, күпчелек мөһаҗирләр Казан губернасыннан була. Шулай ук Самара, Уфа, Оренбург төбәкләреннән дә килүчеләр бар, аларның исемлеге Казан губернасы татарлары белән бергә бирелмичә, аерым язып барылган. Чыганакларда Казан губернасыннан килгән мөһаҗирләр үзләрен «казан мөһаҗирләре», ә кайберләре исә «казан татары» итеп билгели. Санкт-Петербургтагы Госманлы консуллыгы кәгазьләрендә алар «казан татары», «оренбург татары», «самара татары» дип теркәлгән.

Безнең мәгълүматлар буенча, госманлы дәүләтенә күченгән татарлар турында, беренче тапкыр 1791 елның 20 март көнне язылган тарихи документта искә алына. Чыганакта казанлы Сөләйман Чәләби исемле бер шәхес тарафыннан Истанбулда оештырылган вакыф турында сүз бара. 1837 елның 31 июлендә тагын бер казан татары Сөләйман ага тарафыннан вакыф төзелә. Сөләйман Чәләби һәм Сөләйман ага үз чорының бай кешеләре була. Ләкин аларның Истанбулга килү сәбәпләре турында бернинди хәбәр дә сакланмаган. Бу кешеләр беренче казан мөһаҗирләре булган дигән фараз бар.

1813 елның 22 ноябре көнне язылган икенче бер тарихи документта казан голамәсе Габделкәрим әфәнденең Истанбулга килүе турында сүз бара. 1820 елда ул, Госманлы дәүләтеннән акчалата ярдәмне киләчәктә дә алыр өчен, Финанс министрлыгына мөрәҗәгать итә. Гаризада аның хөкүмәттән 1813-1820 елларда ярдәм алырга теләве һәм Финанс министрлыгының ярдәм итүдән баш тарту сәбәпләре күрсәтелгән [5]. 1843 елда Финанс министрлыгына Әхмәд Җәмил исемле бер төрек тарафыннан гариза языла. Анда Казаннан мирза Мәхмәд Гариф һәм аның Габдулла исемле хезмәтчесе килүе һәм аларны каршы алу өчен бүленгән чыгымнар күләме бәян ителә.

Әйткәнебезчә, Кырым сугышыннан соң Госманлы империясенә күчеп килгән Казан мөһаҗирләренең саны арта. Мөһаҗирләр төркемләп түгел, ә аерым-аерым килгәннәр. Килүчеләрнең күпчелеге мулла, хаҗи, мөдәррис һәм шәкертләр булган. Документларга нигезләнеп, аларның дәүләт идарәсенә ярдәм сорап мөрәҗәгать итүләрен әйтә алабыз. Мәккә, Мәдинә, Шам кебек изге шәһәрләрнең документларында да казан татарлары турында еш искә алына. Әйтик, казанлы Мөхәммәтҗан исемле берәү 1847 елда Мәккәдә дәрвишләр өчен йорт — тәккә төзи. Ул хөкүмәттән үзенә хезмәт хакы һәм тәккәне киләчәктә матди яктан тәэмин итеп торуларын сорый. Казан мөһаҗирләренең күпчелеге дини белем һәм дин иреге алырга омтыла. Күп кенә татар мөһаҗире яшәү урыны итеп Шам шәһәрен сайлый. Аның сәбәбе Шам шәһәре — Нәкышбәндия тарикатенең бер тармагы булган Халидия тарикате үзәге булуда.

Казан төбәгеннән килгән мөселман мөһаҗирләре, нигездә, Иске шәһәр, Бурса, Айдын, Сивас, Амасья, Малатья,

Кыршәһәр, Самсун, Нигде, Трабзон, Балыкәсир кебек эре шәһәрләргә килеп урнашалар. Казан татарларының күп өлеше Иске шәһәргә урнашырга тели, чөнки монда инде татар мөһаҗирләре элек тә көн күргән. Госманлы дәүләте аларның теләкләренә каршы килми. Мисал өчен хөкүмәт 1899 елда килгән казан мөһаҗирләрен көньяк-көнчыгыш Анадулыдагы Малатьягә урнаштыру турында карар бирә, ләкин мөһаҗирләрнең Ахудҗан исемле вәкиле үзләрен Иске шәһәргә урнаштыруларын сорый. Нәтиҗәдә, мөһаҗирләрнең бер өлеше Иске шәһәргә, ә 50 кешелек төркем Малатьягә җибәрелә. Алар үзләренә биреләчәк җирләр турындагы документларга кул куйсалар да, иген басуларына карата аерым таләпләрен җиткерәләр. Шуңа бәйле рәвештә, соңрак килгән 174 кешедән торган 31 гаиләнең Иске шәһәргә урнашмаулары турында мәгълүмат бар.

1899 елның 3 апреле белән тамгаланган документта Казан төбәге ягыннан күченгән 111 кешедән торган 16 гаиләнең Малатьягә җибәрелүе турында хәбәр ителә. Ләкин алар, бүлеп бирелгән җир кишәрлекләренең буш урында һәм уңдырышсыз булуы сәбәпле, бу җирләрдән баш тарталар. Кире Россиягә әйләнеп кайту өчен, Самсунга юл тоталар [6]. Госманлы дәүләте мөһаҗирләргә Ватаннарына кире кайтырга рөхсәт бирми, аларга Самсунның Вәзир күпере вилаятенең Күфелик авылында 2346 дөнүмлек (гектар) җир тәкъдим итә.

Госманлы хөкүмәте дәүләт кануннары нигезендә мөһаҗирләрне җылы кабул итә һәм аларга урнашырга һәрьяклап ярдәм итәргә омтыла, ләкин кайтырга рөхсәт бирми. Мәсәлән, 1894 елда казан мөһаҗирләр төркеме Россиягә кире кайтыр өчен Трабзон шәһәренә килә. Хакимият аларның ниятләренә каршы төшә һәм аларга урнашу өчен яңа җир кишәрлекләре бирергә куша [7].

Кырым сугышыннан соң Госманлы дәүләтенең икътисади хәле начарая. Империя башка дәүләтләргә бурычка бата, ләкин икътисади хәле начар булуга карамастан, мөһаҗирләрне кабул итү тукталмый. Идел-Урал якларыннан, Кырымнан су юлы белән килгән мөһаҗирләрне башта Истанбулда кабул итәләр һәм бурычка алынган акчалар хисабына аларны Анадулыга урнаштыралар.

Дәүләт мөһаҗирләрне үз карамагына алуга карамастан, кыен хәлләргә дучар ителгәннәр дә булган. Йортларын һәм җирләрен сатканнан соң, патша хакимияте рәсми рәвештә мөһаҗирләрнең кире Россиягә китүләре тыелуы турында искәртә. Мөһаҗирләр арасында рәсми рәвештә Госманлы дәүләтенең гражданлыгын алмыйча гына качкын булып яшәүчеләр дә була. Моның сәбәбе — соңрак тыныч кына Россиягә әйләнеп кайту. Чит илләргә бурычлары булган һәм финанс авырлыклары кичергән Госманлы дәүләте меңнәрчә мөһаҗирләрне кабул итәрлек хәлдә булмый.

Күпчелек мөһаҗирләр рус телен һәм Россия империясе кануннарын белмәгәннәр. Шуңа күрә алар белән бәйле мәсьәләләрне арадашчылар хәл иткән. Бу арадашчыларны ахудҗаннар дип атаганнар. Документларда алар турында еш искә алына. Ахудҗаннар һәм Россия, һәм Госманлы империясендә мөһаҗирләр проблемасын хәл итүдә арадашчы булганнар. Араларында аферист-авантюристлар да булган. Мисал өчен Казан губернасы округ суды Чистай шәһәрендә Һидиятуллаһ исемле һәм Фатихуллин фамилияле кешеләрне хөкем итә. Бу кешеләр күченергә теләүчеләрдән ялган юллар белән акча җыеп йөргәннәр.

Госманлы империясенә күчәргә теләгән 400 гаилә, Россиядә йорт-җирләрен сатарга рөхсәт бирелмәвен хәбәр итеп, Госманлы империясеннән ярдәм сорап, Истанбулга гариза юллый.

Идел-Урал төбәгеннән мөһаҗирләр

төрле юллар белән, нигездә, Кырым, Ростов һәм Батуми шәһәрләренә, аннары пароходларга утырып, Истанбулга киләләр. Бу иң җиңел юл була. Шул ук вакытта мөһаҗирләрнең рәсми саналмаган юллар аша йөрүләре дә билгеле. 1899 елда Батуми чиге төбәге буендагы хәлләр турында язылган документлар бар. Госманлы империясе, мөһаҗирләрнең чикне нинди юл белән узуларына карамастан, барысын да кабул итә. Рәсми эш кәгазьләрендә законсыз юл белән килгән мөһаҗирләрнең кире Россиягә кайтулары турында мәгълүмат юк. Ләкин шуны да әйтеп китәргә кирәк: Россиядән кире Госманлы империясенә җибәрелгән мөһаҗирләр турындагы аерым документлар сакланган.

Госманлы империясе Истанбулга килгән мөһаҗирләрне күпмедер вакыттан соң Анадулыдагы төрле вилаятьләргә юллый. Матди хәле яхшы булган бай мөһаҗирләр Истанбулда калдырыла. 1881 елда Госманлы империясенең башкаласына килгән чиркәсләр, абхазлы, дагыстанлы, нугай, казанлы һәм кырымлы мөһаҗирләрнең гомуми саны 35224кә җитә һәм шуларның 19742се дәүләт ярдәменә мохтаҗ була [8].

Дәүләт мөһаҗирләргә һәрьяклап ярдәм итә: аларга җир кишәрлеге, өй җиткерү өчен төзелеш материаллары бирә. Шуңа өстәп бер ел дәвамында бушка азык-төлек белән дә тәэмин итә. Ләкин җирле халык һәм мөһаҗирләр арасында туган конфликтлар арка-

1857-1917 елларда Идел-Урал төбәгеннән Төркиягә күчкән мөселманнар саны*

	Элек яшәгән төбәкләр											
	Казан		Самара		Оренбург		Уфа		Тубыл		Билгесез шәһәрләр	
Ел	гаилә	кеше	гаилә	кеше	гаилә	кеше	гаилә	кеше	гаилә	кеше	гаилә	кеше
1857		3										
1861		27										
1862		11										
1863		400										
1870		2										
1881		35224**										
1894	439	363	510	300		1894		306	100			
1895		422										
1896		400										
1898		624			300		300				400	
1899		724		250				250				
1900	40	111										
1901	23	175										
1902	36	39										
1904		5										
1905												
1906	18	2									201	
1908										300		
1913									8			
1917												148
Барлыгы	556	38169	510	550	300	1894	300	556	108	300	601	148

* Чиркәсләр, абхазлар, нугайлар, казан татарлары

** Таблица Төркиягә күченергә теләүчеләр гаризаларында күрсәтелгән кешеләр исемлеге буенча төзелгән. Чынбарлыкта Россиядән килгән мөһаҗирләр санын чагылдырмый.

сында мөһаҗирләр башка районнарга күчерелә.

Аерым елларда Госманлы империясе Россиядән мөһаҗирләрне кертүне тыя. Моның сәбәбе мөһаҗирләр арасында холера, чума кебек йогышлы авырулар таралу була. Мисал өчен 1907 елда холера аркасында күченүләр тыела.

БЕРЕНЧЕ БӨТЕНДӨНЬЯ СУГЫШЫ ВАКЫТЫНДА ГЕРМАНИЯДӘН ТӨРКИЯГӘ КИТЕРЕЛГӘН ТАТАР ГАСКӘРИ ӘСИРЛӘРЕ

Беренче Бөтендөнья сугышы елларында Россия армиясендә якынча бер миллион тирәсе мөселман солдаты була. Сугыш башында ук Госманлы хөкүмәтенә Хәлим Сабитнең Германия һәм Австриядәге әсир татар солдатлары турында биргән рапортында күрсәтелгәнчә, Германиядә ун мең, Австриядә тугыз мең тирәсе әсир татар солдаты була [9]. 1916 елның март аенда Германиядәге татар әсирләренең саны 23 меңгә җитә. Татар әсирләре Зоссендәге Вейнберглагерь, Вунсдорф һәм Австриядәге Эгер лагерьларында башка мөселман әсирләреннән аерым тотылганнар. Аларның саны 10 мең чамасы булган. Башка лагерьлардагы әсир татарларның саны исә якынча 20 мең була. Госман Токимбет, Габдерәшид Ибраһим, Хәлим Сабит, пермьле Сәех Хөрмәтулла, Әхмәт Мөхетдин, Галимҗан Идрис исемле кешеләр Госманлы һәм Германия дәүләтләренең ярдәме белән татарларны Госманлы дәүләтенә күчерү өчен пропаганда алып баралар. 1916 елның маенда Төркиягә китерелгән мең кешелек төркемне Конья, Әфьюн, Иске шәһәр, Бурса, Әнкара, Адана, Билеҗик шәһәрләренә урнаштыралар [10]. Бу газаплы, авыр сугыш тәмамлангач кына алар туган якларына әйләнеп кайтырга ниятлиләр.

Германиядә алып барылган пропаганда нәтиҗәсендә 1916 елның март-май айларында йөзләп татар солдатыннан торган төркем Госманлы хакимияте чакыруы буенча Истанбулга китерелә, алардан «Азия батальон»ы оештырыла. Әлеге батальон Гыйрак фронтына инглизләр белән сугышка юллана. Бу батальон сугышчыларының бер өлеше сугышта һәлак була, 400 солдат, инглизләргә әсирлеккә эләгеп, Һиндстанга китерелә. Сугыш беткәч, 1920 елда бу әсирләр яңадан Истанбулга, аларның бер өлеше туган илләренә кире әйләнеп кайта. Истанбулда калганнарның бер өлеше соңрак Япония, Корея, Европа һәм АКШ кебек илләргә күченәләр [11].

1917 елның гыйнварында Госманлы дәүләтенең Будапешттагы илчесе Әхмәт Хикмәт (мөфти улы) ярдәме һәм солтан Мәхмәт Рәшид фәрманы белән Герма-

Истанбулда татар мөһаҗирләреннән Локман Тимкин һәм аның кардәшләре. 1925 ел

ния һәм Австриядәге әсирләр лагерьларыннан якынча ике йөз кеше Төркиягә кайтарылып, Бурса, Кыршәһәр, Адапазары, Әнкара, Болу вилаятьләренә урнаштырыла [12]. Документлардан күренгәнчә, Беренче Бөтендөнья сугышы вакытында әсирлеккә эләккән Россия мөселманнарының 200-300ләбе Госманлы империясендә кала. Ләкин аларның кайсы милләт вәкиле булуы турында мәгълүмат юк. Бары тик кайберләренең татар икәнлекләрен

БЕРЕНЧЕ БӨТЕНДӨНЬЯ СУГЫШЫ ВАКЫТЫНДА ТӨРКИЯГӘ КҮЧЕНГӘН МӨСЕЛМАН СОЛДАТЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕ

Исем һәм атасының исеме	яше	Туган урыны	Төркиягә күченү урыннары
Abdullah ibn-i Mirza	34	Самара	Муданя / Терлийе
Abdullah ibn-i Zarif	33	Уфа	Муданя / Терлийе
Molla Nur ibn-i Nureddîn	33	Пермь	Муданя / Ялычифтлик
Veli Ahmed ibn-i Timurbak	28	Уфа	Муданя / Ялычифтлик
Mir Seyyid bin Abdülğafur	32	Уфа	Кыршәһәр
Zâkir bin İmâdüddin	27	Оренбург	Кыршәһәр
Nureddin bin Selahaddin	32	Казан	Кыршәһәр
Molla Arif bin Molla Mehmed	35	Уфа	Кыршәһәр
Nezime şah bin Kamer şah	36	Уфа	Кыршәһәр
Carullah bin Zarif	?	Казан	Кыршәһәр
İmadüddin bin Ahmed Can	33	Оренбург	Кыршәһәр
Hayrullah bin Sem'ullah	33	Казан	Кыршәһәр
Mehmed Veli bin İzzetullah	33	Рязань	Кыршәһәр
Seyyid Battal bin Kemaleddin	28	Оренбург	Кыршәһәр
Mehdi bin Sadedin	28	Оренбург	Адапазары
İbrahim bin Nimetullah	26	Казан	Адапазары
Nakibullah bin Müslim	27	Уфа	Адапазары
Gayetullah bin İnayetullah	27	Оренбург	Адапазары
Seraceddin bin Hamdullah	30	Пермь	Адапазары
Bilal bin Hüsniddin	23	Саратов	Адапазары
Fahreddin bin Selahaddin	25	Оренбург	Адапазары
Gıyameddin bin Fahreddin	29	Сембер	Адапазары
İzzetullah bin Zinetullah	26	Уфа	Адапазары
Abdullah bin Kemaleddin	26	Уфа	Адапазары
Hacı Murad bin Bilaleddin	23	Самара	Адапазары
Nur Ali bin Mehmed Yusuf	27	Уфа	Адапазары
Hasan bin Abdullah	27	Томск	Адапазары
Mehmed Ceyd bin Ganiyyüddin	29	Казан	Адапазары
İsmetullah bin Nimetullah	24	Самара	Адапазары
Alemüddin bin Ziyaeddin	29	Казан	Адапазары
Efdaleddin bin Mehmed Feyzi	26	Оренбург	Адапазары
Nur Mehmed Bin Afetullah	28	Казан	Адапазары
Molla Nur bin Sıtkı	33	Пермь	Адапазары
Abdülgani bin Abdüşşar	29	Казан	Адапазары

Ziyaeddin bin Bahaeddin	25	Уфа	Адапазары
Musîbü'l-Atâ bin Alamüddin	27	Уфа	Измит
Hüseyin Can bin Ahmed Çavuş	30	Казан	Измит
Osman bin İbrahim	26	Пермь	Измит
Din Mehmed bin Ali	33	Пермь	Измит
Muhyiddin bin Mehmed şah	29	Пермь	Измит
Necmeddin bin Ferah şah	34	Пермь	Измит
Abdurrahman bin Feyzürrahman	32	Сембер	Измит
Ahmed şah bin Mehmed şah	28	Пермь	Измит
Nasreddin bin Seyfeddin	23	Сембер	Измит
Şehidullah bin Gantarullah	21	Уфа	Арсланбәй?
Arifullah bin Mustafa	33	Саратов	Измит
Habibünneccar bin Güldiyar	32	Уфа	Арсланбәй?
Menli Hayr bin Abdülkerim	23	Казан	Измит
Ahmedullah bin Hayrullah	26	Сембер	Арсланбәй?
Zakir Can bin Yahya	22	Уфа	Арсланбәй?
İlâceddin bin Ayneddin	35	Казан	Арсланбәй?
Abdüttahir bin Keşşaf	23	Самара	Арсланбәй?
Mehmed şefik bin Mehmed Diyar	27	Самара	Арсланбәй?
Haydar bin Bahtiyar	22	Уфа	Измит
Lütfullah bin Mehmed şerif	27	Самара	Ялова
Fazlı Ahmed bin Münasib	24	Уфа	Ялова
Mehmed Oğtar bin Mehmed şah	25	Казан	Ялова
Ahmed Can bin Mehmed Can	32	Уфа	Ялова
Abdülbekir bin Abdurrahman	24	Уфа	Ялова
Ahmedî bin Mehmedî	25	Уфа	Ялова
Menli Ali bin Alemeddin	24	Уфа	Ялова
Zeynullah bin şemseddin	28	Оренбург	Ялова
İbrahim bin Abdüssabah	32	Уфа	Ялова
Bayram Ali bin Zakir Can	21	Оренбург	Ялова
Selim Saray bin Mustafa	22	Уфа	Ялова
İsa bin Musa	28	Самара	Ялова
Mücahidîn bin Mîr Haydar	40	Оренбург	Ялова
Veliyyullah bin Mehmed Ali	28	Уфа	Ялова
Seyyid ali bin Abdülcennan	22	Уфа	Ялова
Molla Ali bin Abdülhalim	24	Уфа	Ялова
Ahtem Can bin Muhyiddin	25	Уфа	Адапазары
Menli Bay bin İzzetullah	32	Уфа	Адапазары
İbrahim bin İzzetullah	24	Казан	Адапазары
Ahmedüddin bin Bediüddin	28	Уфа	Адапазары
Miftahüddin bin Fahreddin	33	Казан	Адапазары
Yusuf bin Mübin	20	Сембер	Адапазары
Sabit bin ağabeydin	28	Казан	Адапазары
Sadreddin bin Abdülcabbar	22	Казан	Адапазары
... Can bin ...	33	Уфа	Адапазары
İbrahim bin Nimetullah	41	Сембер	Бурса
Abdulhak bin Abdullah	25	Самара	Адапазары
Nur Ali bin Mehmed Yusuf	27	Казан	Адапазары
Ziyauddin bin Bahauddin	25	Казан	Адапазары

www.webpark.ru

Osman bin şemseddin	32	Казан	Адапазары
Hacı Murad bin Bilâl	23	Самара	Адапазары / Феризли
Necibullah bin Müslim	27	Уфа	Адапазары
Efdaluddin bin Muhammed Feyzi	24	Оренбург	Адапазары
Sıracuddin bin Hamidullah	30	Казан	Адапазары
Alimcan bin Tuhfetullah	25	Уфа	Адапазары
Hasan bin Cabbar	32	Казан	Адапазары
Kıyamuddin bin Fahreddin	29	Казан	Адапазары
Abdurrahman bin Abdulaziz	28	Казан	Адапазары
Nafi‘ bin Ali	33	Казан	Адапазары
Ali bin Hüsniddin	25	Казан	Адапазары
Feyzullah bin Ali	25	Казан	Адапазары
Hüseyin bin Said	23	Саратов	Адапазары
Hüseyin bin Abdullah	27	Казан	Адапазары
Muhammed Can bin Süleyman	23	Казан	Адапазары
Bilâl bin Hüsniddin	23	Саратов	Адапазары
Abdullah bin Kemal	26	Уфа	Адапазары
Mehdi bin Sadeddin	28	Оренбург	Адапазары
Muhammed Cabir bin	29	Казан	Адапазары
Ganiyyüddin	25	Казан	Адапазары
Süleyman bin Seyfeddin	25	Казан	Адапазары
Alim bin Davud	26	Казан	Адапазары
Mehmed Celaleddin bin Mehmed Sultan	25	Казан	Адапазары
Osman bin şah Merdan	24	Саратов	Адапазары
Ali Haydar bin Ebubekir	39	Саратов	Адапазары
Muhammed bin Zekeriya	32	Самара	Адапазары
Şeyh İlyas bin Şehabeddin	29	Саратов	Адапазары
Abdullah bin Fahreddin	22	Казан	Адапазары
Sadık bin Fahreddin	30	Казан	Адапазары / Феризли
Alaaddin bin Cemaleddin	25	Казан	Адапазары / Феризли
Abdulmecid bin Muhammed	24	Саратов	Адапазары / Феризли
Mustafa bin Gafûr	24	Саратов	Адапазары / Феризли
Hasan bin Kasım	24	Саратов	Адапазары / Феризли
İshak bin Yunus	24	Саратов	Адапазары / Феризли
Fetheddin bin şerefeddin	24	Казан	Адапазары / Феризли
Mevlud bin Abdurrahman	30	Казан	Адапазары / Феризли
Mayrekşah(?) bin Ferruhşah	22	Казан	Адапазары / Феризли
Ebu şahman bin Osman	25	Казан	Адапазары / Феризли
Abdulğafur bin Zeynelabidin	25	Саратов	Адапазары / Феризли
Hasan bin İzzetullah	28	Сембер	Адапазары / Феризли
Cemaleddin bin Taceddin	35	Саратов	Адапазары / Феризли
Musa bin Sadık	25	Казан	Адапазары / Феризли
İsmail bin Sabit	26	Казан	Болу / Хендек
İbrahim bin Nimetullah	29	Казан	Болу / Хендек
/ılmüddin bin Ziyaüddin	27	Казан	Болу / Хендек
Nur Muhammed Gayetullah bin Gayetullah	24	Самара	Болу / Хендек
İsmetullah bin Nimetullah			

Molla Nur Muhammed bin Muhammed Sıtkı	33	Казан	Болу / Хендек
Abdulgani bin Abdussettar	29	Казан	Болу / Хендек
Abdulvehab bin Habibullah	32	Казан	Болу / Хендек
Seyfullah bin Veliyullah	28	Самара	Болу / Сапанча
Ahmed Zeki bin Molla Ali	24	Казан	Болу / Сапанча
Osman bin Seyfeddin	26	Казан	Болу / Сапанча
Bahaeddin bin Şerefeddin	26	Казан	Болу / Сапанча
İbrahim bin İzzetullah	24	Казан	Болу / Хендек
Yusuf bin Hamid	20	Сембер	Болу / Хендек
Zakir bin Safi	26	Пермь	Болу / Хендек
Ahundcan bin İbni Sahib	32	Уфа	Болу / Хендек
Sadreddin bin Abdulcebbar	22	Казан	Болу / Хендек
Ahmeduddin bin Bediuddin	28	Уфа	Болу / Хендек
Menlibay bin İzzetullah	33	Уфа	Болу / Хендек
Miftahuddin bin Fahreddin	33	Казан	Болу / Хендек
Ahmed Can bin Fahreddin	25	Уфа	Болу / Хендек
Habibullah bin Fazlullah	32	Казан	Бурса
Miras bin Taşdemir	35	Казан	Әнкара
İsfendiyar bin Abdulcemil	28	Уфа	Әнкара

исемнәре һәм туган, яшәгән урыннары буенча ачыкларга мөмкин [13].

1917 елның мартында Әхмәд Агауглы, Хөсәензадә Али бәй һәм Йосыф Акчура Германиядә әсир мөселман гаскәриләре лагерьларын зиярәт кылалар һәм аларның Госманлы дәүләтенә тугры хезмәт итә алуга мөмкинлекләре булмауны белдереп, хөкүмәткә рапорт бирәләр [14]. Бичара татар гаскәриләре… Башта рус гаскәре белән берлектә алманлыларга каршы сугышсын, соңрак әсир төшеп, озак кына Германия лагерьларында михнәт чиксен, Истанбул өчен Гыйрак фронтында инглизләргә каршы сугышта әсирлеккә төшеп, Һиндстанга китсен, шунда берничә ел җәфа чиксен, соңрак яңадан Истанбулга кайтып, күпме чиләнгәннән соң, Одесса аркылы туган илләренә кайтарылсын. Аларның Россиядәге язмышларын өйрәнү әлегә кадәр хәл ителмәгән фәнни мәсьәлә булып кала… Татар гаскәриләре язмышын Сталин чорында өйрәнү мөмкин түгел иде. Хәзерге вакытта татар тарихчылары бу гаскәриләрнең язмышын өйрәнеп, алар турында фәнни хезмәтләр язалар, документаль һәм әдәби кинофильмнар әзерлиләр.

Әдәбият

1. OATP, Y. MTV, 57/50.
2. OATP, Y. PRK. ASK, 117/21.
3. Abdürreşid İbrahim «Türkiye'de Tatarlar», Bayanülhak, sayı 791, 26 Mayıs 1911, s.3.
4. OATP, Y. PRK. KOM, 3/24.
5. OATP, C. HR, 4993; C. MF, 1882; C. ML, 13580; C. DH, 16997; C. MF, 3222.
6. OATP, Y. MTV, 188/117.
7. OATP, İ. DH, 1318. Ca/5; MV, 97/87.
8. OATP, ZB, 3/68.
9. Vahdet Keleşyılmaz, «I. Dünya Savaşı'nda Esir Askerler Üzerinde Panislamizm Propagandası Teşebbüsü», Kebikeç, sayı 10, İstanbul, 2000. s.36.
10. Vahdet Keleşyılmaz, «Teşkilat-ı Mahsusa ve Cermen Esir Kamplarındaki Tatarlar», Atatürk Yolu Dergisi, cilt 6, sayı 21. – Ankara, 1998. – s. 67-80.
11. Nadir Devlet, «I.Dünya Savaşında Osmanlılar Safında Savaşan Tatar Taburu», Osmanlı, cilt. 2. – Ankara 1999. s.575-577.
12. OATP, DH.SN.THR 73 / 5.
13. OATP, DH.EUM.SSM, 19 / 36.
14. OATP, DH.KMS, 44-1/50.

Төрекчәдән ***Алия Мөбарәкшина*** *тәрҗемәсе*

Дәвамы киләсе саннарда

КАЗАН ХАНЛЫГЫНДА ТӨРКИ ИСЛАМ МӘДӘНИЯТЕ

Кануни заманында* (1550 елда) Казаннан җибәрелгән бер хәбәр хаты**

ЗӘКИ ВӘЛИДИ ТУГАН

Казанга Гераттан музыкантлар һәм җырчылар китертелүе, Казан ханы Мөхәммәд Әмин ханның Герат ысулы белән шигырьләр язган шагыйрь булганлыгы да мәгълүм [1]. Болар янына чыгышы Әстерханнан булган һәм Казанда яшәгән Мөхәммәд Шәриф исемле, Шәрифи дигән такма исемле (псевдоним) бер шагыйрьнең 1550 елда көнчыгыш төрки теле белән язылган «Зафәрнамә-и вилаят-и Казан» әсәрен дә янәшә куярга кирәк. Ун битлек бу әсәр Кютахъя янындагы Тавшанлы төбәгендә Зәйтин угыллары китапханәсендә 2348 нче номерлы җыентыкның 60а-64б битләрендә теркәлгән. Казан халкының 1550 елның кышында рус патшасы Явыз Иванның Казан шәһәренә һөҗүме вакытында фидакарьлек белән сугышулары һәм рус патшасын борылып китәргә мәҗбүр итүләре турындагы бу әсәрдә 957 хиҗри елы мөхәррәм ае датасы тора (ягъни 1550 елның гыйнвар яки февраль аенда язылган). Ул заманнарда Урта Азия төрки мәмләкәтләрдә киң кулланылган чагатайчаның, аеруча Алишер Нәвои кебек мәшһүр шәхеснең язу теленең, Казанда үз ителүен күрсәтә торган бу документ «Сахиб-и дәүләтләре» гыйбарәсе белән аталып йөртелгән Госманлы дәүләте бөекләренең әлеге вакыйгаларга игътибарын җәлеп итәр өчен язып җибәрелгән булырга тиеш. Бу «Сахиб-и дәүләт»нең Кануни Солтан Сөләйман булуын фараз кыла алабыз. Хатны, җыентыктан күчереп, кайбер хаталарын төзәтеп, түбәндә китерәбез.***

*Кануни солтан Сөләйман — Госманлы империясенең унынчы солтаны.
**Дәвамы. Башы журналның 2012 елгы 8-9 нче саннарында.
***«Зафәрнамә-и вилаят-и Казан» исемле әсәрнең репринт басмасын тәкъдим итәбез. Текстның татар теленә тәрҗемәсе журналның киләсе саннарында дөнья күрәчәк.

ظفر نامۀ ولایت قزان

ضمایر صافیۀ ارباب اولوالابصار و خواطر زاکیۀ اصحاب ذوی الاعتبارغه آفتاب عالمتاب
تیکبن واضح وروشن ولایح ومبرهن تورور[1] کیم ولایت بلغار اقالیم سبعه (دین) یتنچی
اقلیم تورور، قمرغه منسوب ایرور یعنی قمر پرورشیدا تورور علی ما هوالمذکور فی الکتب
الریاضی. وتقی بو ولایت بلغار، قطب شمالیغه کمال قربیدین اواخر جوزا و اوایل سرطان دا
صلوات خمسه نینک بیریسی نینک یعنی صلوة عشا نینک وقتی تبولماس زیراکیم شفق امامین[2]
قشیدا عبارتدر حمرة دین، آنینک غیبوبتیدین بورون راق. بو اوقات معلومه‌دا وقت صلوة
فجر یعنی صبح صادق ظاهر بولور، اول سبب دین اول قومغه صلوة عشا واجب بولماس علی
ما هو المذکور فی کتب الفتاوی سیّما فی الکنز[3] والوافی[4] والکافی[5].

وتقی بو ولایت بلغارنینک پای‌تخت بلدۀ طیّبۀ محروسه دار الاسلام قزان حمیت عن حوادث
الزمان اسلام ولایت لاردین[6] یراق توشوب کفار سر حدیغه متصل تورور.

مصراع: همسایۀ بد مباد کس را

هیچ طرفدین انکا مدد و معاونت یتشماس مگر عنایت رب العالمین قرین و ملایکه لار
ناصرو معین بولغای‌لار اول سبب دین بلدۀ محروسۀ قزان شهرینک پادشاه‌لاری کفّار برلا
زمانه مقتضاسنچه مملکت رفاهیتی وکشایشی رعیّت فراغتی واسایشی اوچون مدارا برله آرادا
ایلچی بویلا[7] یوروشوب کیلش بارش قیلور ایردی‌لار

شعر:

اسایش دوگیتی تفسیر این دوحر فست: با دوستان مروت بادشمنان مدارا.

ثانیا صاحب السیف والقلم منبع الجود والکرم مرحوم و مغفور ابو الغازی صفا کرای
بهادر خان قزان ولایتیغه پادشاه بولدی ایرسا کفار برله دنیادا دینی و آخرتدا ایوی[8]
باشقالیقیدین ان الابرار لفی نعیم وان الفجار لفی جحیم یصلونها یوم الدین[9] آیة کریمه وقاتلوا
المشرکین کافه[10] أمرینا مأمور بولوب یجاهدون فی سبیل الله باموالهم و انفسهم[11] مقتضی‌سنجه
بو حدیث نبوی وفی الغزوة احدی الحُسنیین[12]: اِمّا الظفرو الغنیمة واِمّا الشهادة والجنة
مضمونیدین فرحناک

بیت:

غزاة اهلیغه عالمدا بو بر حسن لطافت بار ظفر تابسا غنیمت کر شهادت تابسا جنت بار

و بو خبر مصطفوی من رمی فی سبیل الله تعالی سهما عُدِل له محرّرا والمنبل به کالرامی
مضمونیدین نشأناك بولوب

قطعه:

1. Текстта: نور
2. Ягъни Имам Мөхәммәд һәм Йосыф.
3. Канз әд-дакаикъ. Хафиз әд-дин Әбел-Баракят ән-Нәсәфинең (үлеме 1310 елда) әсәре; карагыз: Кешф уз-зунун. Яңа басмасы, II, 1315; C. Brockelmann, Geschichte der arabiscen Literature, Sb.II, 265.
4. Шул ук авторның: әл-Вафи фи'л-Фуругһ исемле әсәре, Кешф уз-зунун, II, 1997, C. Brockelmann, II, 265.
5. Шул ук авторның алда телгә алынган әл-Вафи исемле әсәренә шәрхе (аңлатмасы), Кешф уз-зунун, 1378, 1997. Мөхәммәд әл-Хәким әл-Марвазинең дә фикъһка (хокук белеменә) караган бу исемдә әсәре бар (Brockelmann, Sb.I, 288,638), ләкин Шәрифи искә алган әсәр ул түгел. Чөнки Шамс әл-Аимма әс-Сарахсы тарафыннан аңлатмалар бирелгән бу әсәрдә төньяк өлкәләрдә ястү намазы мәсьәләсе юк. Шәрифи искә алган Нәсәфинең «әл-Кяфи» әсәре һәм ул әсәрдә бу мәсьәлә күтәрелгән. Карагыз: Шиһабеддин Мәрҗани. Назһурат әл-хак фи фардийат'-иша ва ин лам йагыб әл-шафак. Казан, 1870, б.120,147.
6. Текстта: لاردین
7. Bulius — латинча; bajulus — итальянча; Bailo - госманлы теленнән.
8. Ягъни җәннәт һәм җәһәннәм.
9. Коръән = Q. LXXXIL,14.
10. Q.IX.36.
11. Q.IX.20.
12. Q.IX.52. احدی الحسنیینнең башы һәм ахыры. Авторның яки кулланылган чыганакның өстәмәсе.

کیمکه بر اوق آتسا مشرکلار یوزیکا دین اوچون
کوییا حق یولیدا بربنده آزاد ایلاکای

بو أجردا برگا دور هر[1] کیم غزاة امیدیدا
بر اوق آتیلغای[2] ویا شمشیر بنیادایلاگای

و دخی بو حدیث نبوی[3] کیم رباط یوم و لیلة خیر من صیام شهر و قیامه و ان جری علیه عمله الذی یعمله و اجری علیه رزقه وامن من الفتّان معنیسن ملاحظه قیلوب

قطعه :

بر کیجه کوندوز غزاة امیدیله آط باغلاماق
یخشیدور برآی توتوش‌صوم وکیجه اعمال دین

اولسا گر رزق و ثوابی تیکوسیدور قربدا[4]
اولمسا امن اولغوسیدور فتنهٔ دجّال دین

الله تعالی حضرتیدین اجر جمیل و ثواب جزیل اوموتوب عداوت بناسی نینک اساسنی توزوب آراداغی اتحاد وداد رشته‌سنی اوزوب مخالفت ابوابنی مفتوح ومراسلت ایشکینی مسدود قیلیب انا ظالم[1] ان لم انتقم من الظالم تیو غزات وجهاد آطلاریغه آطلانیب شمشیر قتال و آبدار وکافرکش نی مبارك بیلینه بغلاب

شعر :

مرغ آبیان جوهر دریای تیغ او
هر یك بروز معرکه صیاد صدنهنك

جاهدوا فی سبیل الله با موالکم و انفسکم[5] تیزکونی[6] قولونا آلیب آیاغنی سعی و طلب اوزانکوسینا سوقوب فضّل الله المجاهدین علی القاعدین[7] درجه‌سیدین امیدناك بولوب ولاتحسبنّ الذین قتلوا فی سبیل الله امواتا بل احیا عند ربهم[8] الآیه مضمون شریفیدین انواع بهجت و سرور و اجناس مکرمت و حضور دست بریب توءتی الملك من تشاء و تنزع الملك ممن تشاء[9] میدانیده ان الله یؤید بنصره من یشاء[10] علمینی کوتروب ایة کریمهٔ کم من فئة قلیلة غلبت فئةً کثیرة[11] باذن الله تیو جنود مسعود اسلامنی آلیب اول کفار بدگیش و ضلالة أندیش کیم اولئك فی ضلال مبین[12] دورلار آلار اوستونا یوروب الارنی قتل ایلیب چاپیب سانسیز اسیرلار وساغش‌سز غنیمتلار کلتورور ایردیلار.

مدت مدیده وعهد بعید بو منوال اوزارنه کچار ایردی. اتفاقا قضا وقدر منادی سی نینک اینما تکونوا یدرککم الموت ولو کنتم فی بروج مشیّده[13] دیکان نداسی حضرت خان نینك مسامع شریفلاریغه یتشیب قل ان کنتم تفرون الموت فانه ملاقیکم[14] صداسنی اشتیب خان حضرتلری همان رضا بوینی قضا قولونا سونوب حق تعالی دین رحمت و مغفرت اوموتوب اناالله وانا الیه راجعون[15] تیو فاذا جاء اجلهم لایستأخرون ساعة ولا یستقدمون[16] مقتضیسینجه

1. Текстта: برکادوژ
2. Текстта: ایتلاکای
3. Текстта: قوی
4. Ихтимал: قبریدا; мондый хаталар язманы җыентыкка күчереп язган госманлы кешесе тарафыннан җибәрелгән.
5. Q.IX.41.
6. Текстта: تیزگوسنی
7. Q.IV.95.
8. Q.III.169.
9. Q.III.26.
10. Q.III.13.
11. Q.II.249.
12. Q.XXXIX.22.
13. Q.IV.78.
14. Q.LXII.8.
15. Q.II.156.
16. Q.VII.34.

تیریكلیك طوردین امید کسب حیاتلیق تمنّاسیدین انسا چکیب[1] کل نفس ذایقةالموت[2]
شربتینی کل من علیها فان[3] بزمیدا وسقاهم ربهم[4] ساقی-ی قولوندین ایچیب دارغرور
دین سرای سرورغه رحلت قیلدی ایرسا ذلك تقدیرالعزیز العلیم[5]

غزل:

آه واویلا اولومدین تنداکی جان تترایور
جاندین آیریلماق بلادور تیو ابدان تترایور

بو اولوم دور بارجانی[6] مغموم و محزون ایلاگان
بو اولومنینك خوفیدین چشمهٔ حیوان تترایور

ییر یوزیداکی اولوم نینك ضربتیدین خلق ارا
کوکداکی یولدوزلار و شمس درخشان تترایور

گه یوزین یرتیب قرارتیب گه قزاریب سارغایب
که قاچیب پنهان بولوب هم ماه تابان تترایور

دفع ایتیب بولماس اولومنی مال بیریب لشکر ییغیب
بوسببدین وهم ایتیب خان بلکه سلطان[7] تترایور

کونکلونا توشکان دین اوترو مرگ وهمی ناگهان
زلزله ایلاب بسی کوه وبیابان تترایور

ای شریفی مستعد بولماق کراك اولماس بورون
یوقسه دیناکدین نهسود این تترایور آن تترایور

کفار بوحادثهٔ گردون دین خوش حال بولوب بو واقعهٔ دنیای دون دین سویونوب اول
کافر بیدین و اول مشرك باکبروکین و اول مفسد روزکار ومفتن فلك رزنکار و ثانی
اثنین شیاطین وپیشوای لشکر ملاعین ایبان[8] بی ایمان فرعون صفت ونمرود هیئت برله اوزی
بشلاب لشکر انبوه گران سنك بسیار وعسکر مکروه باتوب وتفنك بی شمار تخمیناً سکز یوز
مینك لشکر برله الذین یقطعون ما أمر الله به ان یوصل ویفسدون فی الارض اولئك هم الخاسرون[9]
دورلار کیلیب بلدهٔ محروسهٔ قزان شهری نینك گرداگردینی احاطه ایلاب محاصره قلیب قوندیلر

لشکر کفار ازمورو ملخ کم نیستند - نسل یأجوج اند وآدم نیستند

غزل:

عجب برجای عشرت دور جهانده بو قزان شهری
مونینك تیك بولماغای عالمدا بردار الامان شهری

قزان تیك شهر معموری تبولماس دنیادا هرکز
قزان دین آش ایچادورلار نچاقلی[10] بو جهان شهری

بو بر ملکی ایرور قالمیش اباً عن جدخانلاردین
ایرور بو ییر همیشه دنیادا خان ابن خان شهری

1. Текстта: انسا چکیب. Radloff, Wb. I, 748: әңсә; 1434: (Казан сөйләшендә) иңсә.
2. Q.III.185.
3. Q.LV.26.
4. Q.EXVI.21.
5. Q.VI.96.
6. Текстта: بارجان
7. Ягъни Госманлы падишаһы.
8. Ягъни Иван, Иван Грозный.
9. Q XIII, 25
10. «Ничаклы». Казан сөйләшендә.

ییرن یورتین ساتیب[1] برماس آتاسی‌نینک یساقینی[2]
نچوک[3] کیلگای اوشول ملعون، ایماس دور بو ایبان شهری[4]

شریفی کیتما بویبردین غزاة امیدی گر بولسا
بوکوندین سونک دیگای‌لار کیم بودر صاحب قزان شهری.

بردروازه‌ده بو مملکت نینک ستونی بو خلایق نینک ره‌نمونی مرحوم پولاد بیک نینک
اوغلی ممای بیک برله نور علی میرزا زیدّ قدرهما مردان جنک آزمایی و مرد افکن
وجوانان دارا و اسکندر شکن‌لارنی ییغیب قاشیدا آلیب تورور ایردی

شعر:

مبارزلر تورور صف صف قاشیدا
قویوبن تاج نصرت‌نی باشیدا

ایرور میدان آرا هر بری بر شیر.
اوررورلار هر زمان دشمن‌غه شمشیر

تقی خان مورچالیداکی[5] دروازه‌ده[6] بهادرلیق میدانی‌نینک صفدری دلاورلیك پیشه‌سی‌نینک
غضنفری قوزیجاق اوغلان زیدّ اقتداره

شعر:

کورسا کفار ایله هر کیم حرب ضرب ایاّمیدا
دایما اسلام شمشیرین قولیدا استوار

دیماکای اول کیشی هرگیز عمریدا برکز تقی
لافتی الاّ علی لاسیف الاّ ذوالفقار[7]

اول هم بولسا جوانان هنرپیشه ودلاوران صواب اندیشه‌لارنی قشیدا آلیب تورور ایردی.
تقی بردروازه‌ده دلاورلار اهلی‌نینک سروری بهادرلیق معرکه‌سی‌نینک سکندری آق محمد
اوغلان زید عمره

بیت:

ایرور بزم ایچره جم رزم ایچره رستم
بویردین بولماسون هیچ سایه‌سی کم

شعر:

ای زنك گردن کَرَ‌کَش چرخ نیل رنك
خورشید مهرگه بود درمیان زنك

هر کیم اوق آتسا لشکر کفار یوزیکا
دیماسن آنی اوق‌تیو، کیم ایرور تفنك.

تقی بردروازه‌ده نسل سید المرسلین قطب الاقطاب سید آتا نبیره‌سی مرحوم و مغفور
سیدنینك اوغلی قول محمد سید دام فضله باشلاب جوانان درویش شمار وصوفیان ریاضت
آثارلارنی ییغیب آیة کریمه قل اننی هدانی ربی الی صراط مستقیم دیناً قیّماً ملة
ابراهیم حنیفا[8] مفهومیدین فرحناك و آیة شریفه ان الدین عندالله الاسلام[9] معنی‌سی برله

1. Текстта: سالیب. Тотык (заложник) итеп биреп, дип әйтергә теләгән булса кирәк.
2. Ягъни рус патшасы Иван IV, Алтын Урда ханнарына ата-бабалары дәвереннән бирле үтәп килгән «ясак» салымы.
3. Ничүк — ничек.
4. Ягъни бу Казан шәһәре «Иван» (ягъни рус) шәһәре түгел.
5. Текстта: موچالیدا کی
6. Ягъни кала диварларының Сөембикә һәм улы Үтәмешгәрәй яшәгән сарай ягында, каланча астындагы капка.
7. Ягъни Кузычак углан гомерендә һичбер вакыт «Ирләрнең ире — бары тик Гали генә, кылычларның иң үткене — бары тик «Зөлфакар» гына», димәгән. Ягъни мин Галидән батыррак, кылычым да «Зөлфакар»дан үткенрәк дип әйтә алырлык каһарман дияргә тели. «Колынчак-Кузычак» дастанында да нәкъ шулай.
8. Q. VI, 161.
9. Q. III, 19.

نشأنالك بولوب حق سبحانه و تعالى درگاهيغه سيغينيب حضرت رسالت پناهى روحى باشليغ جميع انبيا ورسل ارواح لاريدين استغاثه قيليب باباسي سيد آتا قدس‌سره روحى دين هم اذا تحيرتم فى الامور فاستعينوا من اهل القبور[1] مقتضى‌سنجه مددو معاونت استاب غزات آطيغه آطلانيب جنك اسبابنى مهيا قيليب كفار سارى يوزلانيب حاضر وناظر بولوب تورور ايردى.

تقى بردروازه‌ده دارارايت واسكندر درايت رستم مثال وبهرام امتثال باربولسون آتاليق

شعر:

الهى دنيادا اول بار بولسون همیشه فتح نصرت يار بولسون
بهادرليق داهم بولسا كمى[2] يوق بوكون تاپسا شهادت هم غمى يوق

اوز توابع ولواحق‌لارى برله تورور ايردى.

تقى بردروازه‌ده شهر بيكى بلغار ولايتى‌نينك حاكمى قره عيون السلاطين درة صدف العز والتمكين مدير امور الممالك السلطانيه مفتح ابواب الخزائن الخانيه سلالة الامرا بى بارس بيك زيد قدره‌نينك بهادرليق غيرتى حركت كاكليب دلاورليك يوراكى تبرانيب هر زمان دير ايردى كي،

قطعه:

من نه آن باشم که روز جنك بينى پشت من
آن منم كاندر ميان خاك وخون بينى سرى
هركه جنك آرد بخون خويش بازى ميكند
روز ميدان آنكه بگريزد بخون لشكرى.

بعض دلاوران نامدار و پهادران كام‌كار ناريخى[3] بيك و آى كلدى بيك و آق متاى بيك و جماعه حاجى‌لر نصرهم الله هر يرده كفار تبه كار هجوم قيلسالار اول يركا اوزلارين يتكوروب جان و دل برله مدد ومعاونت بيريب كفار سيه‌كار برله محاربه و مقاتله قيليب كافرلرنى ييقيب سونكولارين[4] سندريب غازيليق تشريفاتى برله مشرف ايردى‌لار.

القصه ايكى لشكر برى بريكا محاربه و مجادله و مقاتله‌غه قرشو توردیلر.

مثنوى:

درون صف‌دران صف بركشيدند
زماهى تابمه لشكر كشيدند
سپاه كوه پيكر فوج برفوج
چنان درروى دريا موج برموج
سراسر، باسنانها زره رستم
زسر تاپاى در آهن شده گم
كرفته هر طرف شيران جنكى
كمان‌چاچى و تير خدنكى

53. Мәүзугъ, ягъни уйлап чыгарылган бер хәдис.
54. Ягъни кимчелеге һәм гаебе.
55. Текстта — ноктасыз. Наррык бәк булырга тиеш, Чура батырның атасы.
56. Текстта: سوكولارين

بر سبیل تواتر ثابت و محقق بولوب ایردی کیم کفارنینک اشکریدا اون بر اوتلوغ
توب بار ایردی بر بخشی توبجی هم قاچیب کلیب ایکن ایردی اول توبلارنینک هر بر
اوتلوغ جادره‌سی[1] تخمیناً قزان تاشیغه بتمان[2] بار ایردی اولوغلیغی آط طوبره‌سی[3] چاقلی
ایردی اول یادره ایچیدا انواع طلسمات و اجناس تصرفات‌لار قیلیب ایردی‌لار کیم عقل

افلاطون حیران قلوب فهم ارسطو متحیر و سرکردان بولغای ایردی. اول یادره‌لار تیشبدین[4]
تمورلر برله تمورشاب بزلار[5] برله توقوب ایچیده نفت سپید قیوب کوکردلار سالیب کیچکنه
توفاچکه‌لار راست قیلیب ایچینده تورت بش تمور غاشیندین یادره‌لار سالیب مضبوط و مربوط
و محکم و مستحکم قیلیب قرانکغو کیچه‌لاردا کیم آثار ایردی‌لار دیکای ایردینکیز کیم
کصیّب من‌السما فیه ظلمات ورعد وبرق[6] تیو.

تقی اول اوتلوغ یادره‌لاردین کیچه‌لاردا سالیب چیقغان هواداغی اوچقون‌لارنی خیال
قیلغای ایردینکیز کیم کوک‌لاردا کی کواکب ثابتات و سیارات‌لارنی پارچاسینی یرکا توشتی تیو.
اول اوتلوغ یادره‌لار کیچه‌لار شهر ایچیدا هر یرکا کیم توشار ایردی هیچ کیم ایرسانینک
عرصه‌سی یوق ایردی کیم آنینک یویغینه[7] باروب سوندرگای؛

بیت

کرچه هر اوتنی کیلیب سوندرسا بولغای سوقیوب
بویلالیغ اوت‌نی‌کی هم سو برله بولماس سوندروب

امّا بعض جوانان باجرأت و دلاوران باهمت المرءیطیر بهمته دکان تیک[8] اوزلارین
اول اوتغه سمندر تیکین سالیب باستغانت ملک متعال واستشارت عقل فعال برله اول اوتنی
انداغ سوندرور ایردی‌لارکیم آثارو علامت‌لری قالماس ایردی.

شعر:

سوغه‌بالیق اوتغه سمندر کراك
ایش کونیدا مرد دلاور کراك

ایر کیشی کا همت اگر بولسایار
عاقبت الامر مرادین تبار

تقی دورت بیش هوایی توبلاری هم بار ایردی هر بر یادره تاشی برکوه پارهٔ ایردی
هر وقت کیم اول توبلار آتیلور ایردی اول یادره تاشی قوهٔ قسریهٔ محرکه برله قوش تیکین
اوچوب کالطیریطیر بجناحه هواغه کیم چیقار ایردی وتری الجبال تحسبها جامدة وهی تمرمر
السحاب[9] دایرهٔ افلاکده بر نقطه تیکین بولوب هوادا یعنی جوّالسمادا یوروب قوهٔ

قسریه‌سی توکان‌کان سونکرا میل طبیعی‌سی برله کیم توبان اینار ایردی باد صرصردین
تندراق قضا و قدر اوقیدین تیزراق اینیب

شعر:

قضا چون زگردون فرو هیشت پر
همه زیرکان کورکشتند و کر

1. جادره яки یادره сүзе, Radloff, Wb III, 376: русча «ядро» сүзен казанлылар әйтелеш рәвеше дип аңлата.
2. Ягъни Казанда кулланылган үлчәм берәмлеге буенча бер батман 32 килограммга тигез.
3. Торба — капчык.
4. Ягъни тышыннан, тышкы ягыннан. Текстта: باشیدین
5. Бакыр. Казан сөйләше.
6. Q. II, 19.
7. Ягъни یاویقیغه — якынына.
8. Ягъни дигәндәй, дигән кебек.
9. Q. XXVIII, 88.

هر يركا توشسا ويرسل الصواعق فيصيب بها من يشاء[1] منطوقەسينجه اول يرنى بزوب يقيب هفت طبقهٔ زمين‌دين اوتار ايردى.

شعر :

زبالا چو سنكى بزير آمدى   زكاوزمين[2] بانك شير آمدى

بيت :

كويا آتى سمّاك وايندى تا فرق سمك
ممكن ايرماس دور بو ايش‌نينك مينكدا برو صفن ديمك

وساير ضرب زن‌لاركا وتوفنك‌لاركا حساب‌سان يوق ايردى بوتوب‌لارنينك صاعقهٔ آسمانى‌نينك لهمناك آوازلاريغه خلايق و همناك بولوب وترى الناس سكارى وما هم بسكارى ولكن عذاب الله لشديد[3] بر بريني تانيماس‌تيك بولوب ايردى‌لار لكل امرء منهم شان يغنيه[4] بيزلار حيران و متحير بولور ايردك كيم حق سبحانه و تعالى بو كافر بى‌دين و مشرك باكبروكين كا بو اساس دبدبه و بو لشكر و عسكر بو حشمت و سلطنت بريب بنده نوازليق قيلغانينا.

شعر :

سبحان من تحيّر فى ذاته سواه   فهم خرد بكنه كمالش نبرده راه

شعر :

اى كريمى كه از خزانهٔ غيب گبرو ترسا وظيفه خوددارى
دوستا نرا كجا كنى محروم توكه با دشمنان نظردارى[5]

القصه ايكى لشكر غرق آهنين بولوب بربريكا قرشوتوروب محاربه و مجادله كا مشغول بولدى‌لار

بيت :

ميان دو ديوار آهن بنا
يكى كوچه آموز شهر فنا

شعر :

در آمد دو لشكر بجنبش چو كوه
كزان جنبش آمد جهان را ستوه

زغريده نالهٔ كرناى
در افتاد وتب لرزه بردست وپاى[6]

اون كون آنداغ اوروشلار بولدى كيم كويا حشرو نشر ايردى.

مصراع :

آن[7] تيكين غوغا ايردى كويا محشر

چكاچاك خنجر بكردون رسيد
زشهر قزان خون بجيحون رسيد

بحمد الله والمنة و على نبيه الصلوة والتحيه توفيق الآهى و تأييد تا متناهى همطريق و عناية رب‌العالمين قرين و ملائك ناصرو معين بولوب آية كريمهٔ وهو يعلم اينما كنتم صداى

1. Q. XIII, 13.
2. Ягъни риваятьтәге мөгезләре өстендә җирне күтәреп торган үгез.
3. Q. XXII, 2.
4. Q. LXXX, 37.
5. Сәгъди (Саади)дән.
6. Фирдәүсидән.
7. Алдагы юлда очраган кебек, биредә дә төркичә «ул, у» урынына фарсыча «ан» кулланылган.

روح افزاسی مسلمانلارنینک مسامعلاریغه یتشیب آیة کریمه ان ینصرکم الله فلا غالب لکم[1]
مقتضیسنجه ولقد نصرکم الله فی مواطن کثیره[2] معنیسی صورت پذیر بولوندی کفار
بدکیش وخطا اندیشلارنی انداغ قیلدیلار کیم آثارو علامتلری صحیفهٔ روزکاردین محکوك
و مفکوك بولدی فقطع دابر القوم الذین ظلموا والحمد لله رب العالمین[3] قلمهنینک ایکی یازیسیدا
کفّار سیهکار انداغ اولوب[4] طعمهٔ سکان و لقمهٔ کرك وخرسان بولوب یاتور ایردیلار
کیم (64 b) آیاق بسارغه برچولا[5] یرتابولماس ایردی. فتری القوم فیها صرعی کانهم اعجاز
نخل خاویه فهل تری لهم من باقیه[6]

شعر:

فتاده در آن بهن دشت درشت
سرنا تراشیده چون خار پشت

القصه مونونك تیك اورو شلار اون آلتی شبانه روز متصل لاینقطع بولدی. اون یشنچی

کون لشکر کفار تبهکار مخذول و معزول و مردودو مقهور بولوب قایتتی الحمد لله الذی
نصر عبده واعز جنده هزم و الا حزاب وحده.

بیت:

بخت و دولت بکاردانی نیست
جز بتأیید آسمانی نیست

قطعه:

ساقلاسه هرکیمنی دوشمندن خدای لم یزل
حاجت ایرماس دور انکا کیماك زره, عالی حصار

ساقلاماس بولسا تقی (یوق) بو ایکاودین منفعت
سقلاسا ممکن ایماس بر تیلنی کسماك[7] ذوالفقار

رجا و کرم ارباب تحقیقلاردین و امید الطاف اصحاب توفیقلاردین اول تور کیم
هر محل بو «ظفرنامه» بو صاحب دولتلارنینك[8] منظور نظرلاری بولونسا بو فقیر کیم
معترف دور عجز و قصوری متّصف و منصف دور کناه و عصیانی برله آنینك مرادیغه
فاتحه با اخلاص دریغ قیلماغایلار رحمه الله عبداً قال آمینا.

وقعت هذه الواقعه فی شهر محرم الحرام سنه سبع و خمسین و تسعمایه منشی هذا الانشا
الغرا و مسود هذه الصحیفة البیضاء افقر العباد شریف حاجی ترخانی.

1. Q. III, 160.
2. Q. IX, 25.
3. Q. VI, 45.
4. Текстта: ادوب
5. Бу Казан һәм Түбән сөйләшләрендәге бер сүз. Мәгънәсе: зур бер чүмеч, талчыбыктан үреп ясалган чүмеч. (Radloff, Wb. III, 2023 Schopfluffel), Кашгарчада «чойлә». Ягъни аяк басу өчен бер чүмеч кадәр дә җир таба алмаслык.
6. Q. LXIX, 7.
7. کسون
8. Ягъни Госманлы Солтаны (Сөләйман Канунигә) һәм вәзирләренә.

«Зафәрнамә-и вилаят-и Казан» әсәрендә сүз алып барылган вакыйга, ягъни Иван IVнең 1550 елның башында Казанны яулый алмыйча кире китүе руслар өчен дәрәҗәле эш булмаганга, рус тарихчылары бу хакта бары тик «карлар эри башлаганга күрә, патша юллар киселүе бар, дигән фикер белән кире борылды», — дип кыска гына язып үтәләр (Карамзин, 1892, VII, 75; Соловьёв, VI, Изд-во Общ. Польза, 65-66). Без «Түрк вә татар тарихы» (Казан, 1912, Б.231) һәм Һади Атласиның «Казан тарихы» (Б.224-236), «Сөембикә» (б.20-25) хезмәтләребездә, бу мәсьәләдә бердәнбер чыганак рус елъязмалары булганга, шәһәрне саклауның бик кыен һәм каһарманнарча булганлыгы турында, Шәрифи хатындагы мәгълүматтан хәбәрдарсызлыгыбыз сәбәпле, яза алмаганбыз. Иван IV шәһәрне камавын 13 февральдә башлаган, 11 көн дәвам иткән сугыштан соң, 25 февраль көнне гаскәрләрен туплап, Казанны ташлап киткән. Шәрифи исә камалышның 16 көн дәвам ителүен, 17 нче көнне Иванның Казанны калдырып китүен теркәгән. Рус гаскәрләренең зур бер өлеше шәһәрне инде февраль башларында ук камалышка ала башлаган була. Шәрифи бу вакыйганың хиҗри буенча 957 елның мөхәррәм аенда булуын теркәү белән чикләнгән. Бу исә 1550 елның 20 гыйнвары белән 18 февраль арасы дигән сүз. Сафагәрәй хан 1549 елның мартында үлгән, урынына өч яшьлек улы Үтәмешгәрәй китерелгән, аның наибе (вакытлыча вазифасын башкаручысы) сыйфатында анасы Сөембикә ханлык иткән, чынбарлыкта исә хөкүмәт Кузычак угъланның кулында калган. Иванның Казанны басып алырга теләве Сафагәрәйнең үлеме сәбәпле, ханлыкта какшау, көчсезләнү хасил булды, дигән фикердән барлыкка килә. Бу хакта Шәрифи дә, рус елъязмачылары да уртак фикердә.

Казан шәһәр ныгытмасының капкалары алты дип күрсәтелгән. Башка чыганакларда болар Хан капкасы, Аталык капкасы, Түмән капкасы, Кабак капкасы, Муралы капкасы һәм Кырым капкасы буларак санала. Моннан тыш, бәлки алары һәркемгә ачык капкалар булмаганнардыр, Изболы һәм Алабуга капкалары да искә алына.

Сөләйман Кануни

Шәрифи шәһәрне саклауның капкаларга карап оештырылган булуын әйтә һәм, хәрби җитәкчеләрен дә атап, бу көчләрне тасвирлап бирә.

Иң беренче буларак, ул вакытта инде вафат Полат (Булат) бәкнең угылы Мамай бәк белән Нургали мирза идарә иткән капка искә алына. Рус чыганакларында бу Полат бәк «Расовның угыллары» белән бергә телгә алынган (Һади Атласи, Б.222). Расов, ягъни Рас яки Раст исемле бер бәкнең балалары арасында Юлбарс бәк күрсәтелгән (Атласи, Б.212). Нургали мирза нугай мирзаларыннан берсе булырга тиеш, исеме рус чыганакларында Муралы рәвешле язылган (Атласи, Б.226). «Муралы капкасы», мөгаен, бу шәхес белән бәйле.

Шәрифинең «Хан Мүрчәле» дигәне рус чыганакларындагы «Хан капкасы» булырга тиеш. Хан, ягъни Сөембикә белән угылы Үтәмешгәрәй урнашкан якның капкасы һәм андагы көчләрнең хәрби җитәкчесе Кузычак угълан исемле була. Рус чыганакларында «Кашчак Улан» дип бирелә. «Улан», ягъни «углан» — хан нәселеннән килгән, ханзадә дигән сүз. Боларның шактый өлеше Кырымнан килгән ханзадәләр булган. Казанны саклау уңышлы тәмамланса да, төп Казан халкы (болгар-чувашлар) арасында руслар яклы булучылар күпчелекне тәшкил иткән. Кырымнан һәм Нугайдан килгән ханзадәләр, мирзалар һәм аларның кешеләре (татарлар), киресенчә, русларга бик көчле каршы торганнар. Нәтиҗәдә, кырымлылар һәм нугайлылар Казанны калдырып китәргә мәҗбүр була. Әмма, Кузычак углан белән Барбулсын углан исемле ханзадәләр, руслар яклы чувашлар белән көрәштә җиңелеп, әсир алынып, Мәскәүгә җибәреләләр һәм шунда асып үтереләләр.

Бу сугышларда зур батырлыклар күрсәтелгән. Кузычак исә, Нарых угылы Чура батыр кебек, дастаннарга каһарман булып кергән. Дастан бу угланны «Колынчак батыр» исеме белән яшәтә. Колынчак батырның, Чура белән бергә Казанны руслардан коткару өчен, Кырымнан юлга чыгулары; шигырь әйтү ярышлары; Чураның сеңлесе Айсылуны Колынчакка бирүе; үзе Казанда вакытта Колынчакны бер тапкыр Кырымга җибәрүе; Чураның хатыны белән бу кызның аны Казаннан беразга Кырымга китертү өчен хәйлә корулары һәм башкарып чыгулары; хан казнасына ганимәтләр һәм төрле байлыклар килгәндә, моңа ханның «Кара дуван»ының, ягъни хәзинә хисапчысының бик нык сөенүе; шәһәр капкасына дошман килгәндә, менә хәзер кан коеп сугышачакбыз дип, моңа Колынчак белән Чура Батырларның сөенүе һ.б. турындагы шигырьләр бик мәшһүр (Карагыз: Мухаммед Османов. Ногайская хрестоматия. Петербург, 1883, С.24, 28; Березин. Турецкая хрестоматия, II, Казань, 1862, С.56). Шәрифи бу Кузычак угланны ислам тарихындагы хәзрәте Гали белән бер рәткә куйган.

Өченче капканы саклаган Ак Мөхәммәд углан исә рус чыганакларында Кузычак углан белән бергә искә алына. Үзләре генә дә түгел, аларның балалары да бергә телгә алына (Атласи, Б.239). Бу балалар, патшабикә Сөембикә казанлылар тарафыннан Мәскәүгә тапшырылганда, тотлык (рәһинә, заложник) итеп аның янында җибәрелгәннәр.

Рус чыганакларында шәһәрнең дүртенче капкасын саклаган Кол Мөхәммәд сәет тә искә алына (Атласи, Б.245). Бу кешенең бабасы «Сәйид Ата» Әхмәт Ясәви нәселеннән була, ул 1310 елда Харәзмдә үлә (карагыз: Көпрүлү Фуад. Беренче суфыйлар, 105-107; З.В.Туган. Төркият мәҗмугасы, II, 224). Шәрифи бу сәетне, «дәрвишлек иткән яшьләр белән суфыйларның башында булып», изге сугыш тойгысы белән кяферләргә каршы сугышучы итеп күрсәтә. Безнең өчен мөһим булган мәгълүмат — Казандагы сәетләрнең, Харәзмдә һәм Сырдәрья буйларында яшәгән Ясәви шәехләренең, «гази» булып, мөритләре белән бергә Казанны саклауда катнашулары. Димәк ки, Казанны «ислам шәһәре» итеп саклау Газан хан заманыннан бирле дәвам итеп килгән.

Бишенче капканы саклаган Барбулсын Аталык та «Барболсын Улан» исеме белән рус чыганакларында урын алган (Атласи, Б.235). Бу шәхес яшь хан Үтәмешгәрәйнең тәрбиячесе булган булса кирәк. Шәрифи аны дөньяга, дан-шөһрәткә әһәмият бирми торган, ләкин Дара, Искәндәр, Рөстәм

һәм Бәһрам Гур кебек каһарманнар дәрәҗәсендәге батыр итеп сурәтли.

Алтынчы капканы саклау Би Барс Бәк исемле бер олы затның җаваплылыгында булган. Ул да рус чыганакларында (Атласи. Сөембикә, Б.23) «Бий Барс Растов» исеме белән искә алына. Атасы «Раст» исемле бер бәк булган, шул шәхескә бәйле рәвештә Азак (Азов) каласына руслар тарафыннан Ростов (Растов) атамасы бирелгән. Рус чыганакларында Би Барс бәкнең 1551 елда Кол Шәриф мулла белән бергә Мәскәүгә илче итеп җибәрелүе турында мәгълүмат теркәлгән. Шәрифинең сурәтләүләреннән бу шәхеснең Казан шәһәре бәге (ягъни шәһәр идарәсе ышанычлысы), Болгар вилаяте хакиме һәм Казан ханының казначысы (казначей) булуы аңлашыла.

Шәрифи Казанны саклауда Нарых Бәк, Айкилде Бәк һәм Акматай Бәк исемле бәкләр идарәсендә җидәк (запас) көч тә булганлыгын белдерә. Газиләргә ярдәм кирәк булганда, алар ярдәмгә килгәннәр. Шәрифинең бу язмасын үз әсәре эченә керткән Госманлы кешесе кайбер исем һәм сүзләрне хаталы укыган. Нарых исеменең Нарыхи рәвешендә язылуы да бу күчерүченең ялгышы булса кирәк. Рус чыганакларында «Нарых» дастан каһарманы Чура Батырның атасы итеп, «Чура Нарыкович» исемендә күрсәтелә. Бу сугышларда Чура искә алынмый. Ул, Сафагәрәй белән аралары бозылу сәбәпле, берара Нугай Урдасына качып китә һәм шунда Сафагәрәй тарафыннан үтертелә, дип белдерелә (Атласи, Б.201). Шәрифи язган Айкилде бәк исә рус чыганаклары буенча (Атласи. Сөембикә, Б.23) 1551 елда казанлылар Мәскәүгә ханзадә Ходайкол углан җитәкчелегендә җибәргән илче төркеменең әгъзасы буларак искә алынган Айкилде Абыз белән бер үк шәхес булырга тиеш.

Шәрифи 1550 елның февралендәге җиңү белән Казанның тыныч киләчәге тәэмин ителде, дип уйлаган. Кузычак углан белән Барбулсын углан кебек кырымлы юлбашчылар исә, бу вакытлыча җиңүгә алданмыйча, җитди сугышка хәзерләнергә кирәк, дигән фикерне алга сөргәннәр. Ләкин болар туплаган мең кешелек мөҗаһит-сугышчы төмәненә (полк) төп казанлылар кермәү, шәһәр читендәге чувашлар исә аермачык Мәскәү яклы булып, кырымлылар һәм нугайлылар белән сугышу сәбәпле, бу зур хәзерлек чаралары бушка киткән. Кузычак углан белән Барбулсын угланның 5 мең кеше белән Казанны калдырып китүеннән соң, шәһәрне саклау, ныгыту эшләре шәһәрдәге татарларның Кырым, Нугай һәм башка җирләрдән килгән мөҗаһитләр белән уртак хәрәкәте буларак мәгълүм. Ләкин инде Казан 1550 елның башларында Иван IVне чигенеп китәргә мәҗбүр иткән куәтен югалткан була. Нәтиҗәдә, руслар, 1552 елда тагын да күбрәк немец тубы һәм 50 мең «хезмәтче татар» белән яңадан һөҗүм башлап, 2 октябрьдә Казанны басып алалар.

Шәрифинең язу теле кайбер урыннарда Төмән татар сөйләм телен чагылдыра (бирге, тотош, тизгин, аш ичә, чаклы, ничаклы, йиткирип, йиз, йәдрә, учур, түшти, су койуб сүндирү, түкәнгән, түбән, үтер, кырды, айак басарга бир чола йер табылмас). Бу исә әле XIV гасыр башларында да җирле казанлылар болгар телендә сөйләшкән булып, шәһәрдә «мөселман кавем-и татар» күбәйгәннән соң, татарларның теле гомумсөйләм теле буларак урнашканлыгын күрсәтә. Ягъни хәзерге «Казан татар теле» Шәрифи заманында шагыйрьләрнең әдәби теленә йогынты ясар дәрәҗәдә гомумиләшкән дигән сүз. Моның белән бергә Шәрифинең телендә госманлы теле тәэсире дә бар һәм моны, әлбәттә, кырымлылар китергән. Шәрифинең теле — гомумән,

Алишер Нәвои өслүбендә «затлы чагатай» әдәби теле. Ясәви төре гади төрки шигырьләр арасында очраган «Кол Шәриф» яки бары тик «Шәриф» такма исемле шигырьләрнең Шәрифи әсәрләре түгеллеге ачык билгеле. «Бакырган» китабының басма һәм язмаларында 36 касыйдә әлеге такма исем белән бирелгән. Бу Мөхәммәд Кол Шәриф яки Шәрифнең кем булуы да мәгълүм. Ул үзен «асылымны сорасаңыз, Яфәс углы Үзбәкмен» дип таныткан. Бу шәхес Бохара әстерханлыларыннан Габделгазиз хан заманында яшәгән һәм һиҗри 1190, милади 1697 елда вафат булган Мөхәммәд әл-Хөсәен исемле бер Ясәви шәехе булган. Аның «Хуҗҗәт әл-закирин» исемле фарсыча-төркичә катнаш тел белән язылган әсәре һәм «Диван-е Шәрифи» дип аталган фарсыча-төркичә катнаш телдәге җыентыгы Гали Әмири китапханәсендә, Рашид әфәнде өлешендә 372 номер белән саклана. Ләкин шуны да әйтеп үтәргә кирәк: Әхмәт Ясәвинең «Диван-ы хикмәт» җыентыгына кергән гади төркичә суфый шигырьләре арасында (Истанбул, 1882 басмасы, Б.255 һәм кабатланып Б.264) «Шәрифи» такма исеме белән бирелгән 18 юллык «хикмәт»е бар. Теле «Кол Шәриф»некеннән төзегрәк һәм Казан татар теленең эзләре дә табыла (мәсәлән: тойган, сөйгән, үткәрдең, черер, тилмерер). Бу шигырьнең әлеге «Мөхәммәд Шәриф Хаҗитархани»ның әсәре булуы мөмкин. Шәрифи фарсыча шигырьләр яза алган, Фирдәүсине һәм, гомумән, Иран классик әдәбиятын яхшы белгән, гарәпчәсе дә төзек, Коръәннән китергән алынмалары да урынлы. Математика гыйлеменнән хәбәрдар, физика термины булган «хәрәкәт-и касрия» (мәҗбүри хәрәкәт) гыйбарәсен кулланган. Әсәрдән аңлашылганча, төньяк өлкәләрдә җәен төн якты булганга, ястү намазының вакыты килмәү сәбәпле, бу намазның төшеп калуы белән бәйле һәм XIX гасырда кабат уртага чыккан низаглы, бәхәсле мәсьәлә Шәрифи заманында да Хафизеддин Нәсәфи карашына туры китереп хәл ителгән булган.

Төркиләр тарихы турында 1912 елда басылган хезмәтемдә (Б.198) болгарларга караган чыганаклар биргән мәгълүматка таянып, аларның сугышчанлыктан бик читтә торучы, «иелгән башны кылыч кисми» сүзен тотучы сәүдәгәр халык булганлыкларын язган идем. Болар руслар белән ислам мәдәниятен җәелдерү өчен түгел, бары тик саклану максаты белән сугышканнар. Шагыйрь Шәрифи исә (20-55 нче юллар) казанлыларны «мүддет-и мәдидә вә аһди бәгыйддән бире» (бик озак вакытлардан һәм бик ерак чорлардан бирле), аеруча Сафагәрәй хан заманында, Русиягә каршы бер-бер артлы яу чапкан, ганимәт һәм әсирләр алып кайтудан, дин өчен җиһад максатында сугышудан тәм тапкан бик сугышчан халык дип белдерә. Итальян Пауль Йови 1526 елга караган язмасында казанлыларны Русия белән тату яшәргә омтылучы бик тыныч табигатьле халык итеп сурәтли. Казан ханлыгы турында Алмания (Германия) илчесе Герберштейнның шул ук елларга караган язмаларында чувашларның татар гаскәренә укчы итеп алынулары, Казан татарларының исә бөтенләе белән сәяси һәм гаскәри халык, сугышчы рухлы булулары, Алтын Урданың башка татарлары белән чагыштырганда, тагын да алга киткән һәм утраклашкан булулары белдерелә. Хаҗи Мәхмүд әфәнде китапханәсендә 3394 нче номерлы мәҗмугада «Әстерхан сәфәре» турында теркәлгән Госманлы мәгълүматларында: «Казан татарлары» бик сәяси һәм «актив мөселман» халык булганнар; алар Госманлы дәүләтен Русиягә карата зур сәясәт алып барырга һәм бу максатта Идел белән Дон елгаларын берләштереп, Гилян белән Табаристан ярларын, ягъни Каспий диңгезе өлкәсен бөтенләе белән

Госманлы йогынтысы астына алырга этәргәннәр һәм күндерә алганнар, диелә. Берсенә-берсе каршы килгән кебек күренсә дә, бу мәгълүматларның һәр икесе дә дөрес. «Тынычлык, тату-лык яклы»лар өлкәнең борынгы халкы булган болгарлар булса, бик «хәрбче газиләр» (сугышчан газиләр) итеп тасвирланганнары исә, Чыңгызыйлар дәверендә мөселманлык кабул иткән һәм Казан шәһәрен корган татарлар булган. Бүгенге көндә җыеп бастырылган кабер ташлары язмалары да Казан һәм Болгар төбәкләрендә яшәгән мөселман халыкның ике төркеме булуына ишарә итәләр: бер өлеше XIV гасыр урталарына кадәр [2] дәвам иткән болгарча (чувашча) язмалар, куфи язуы белән гади ташлар өстенә язылганнар. Болгарлар белән өйләнешкән татар яки төрекмән кызларының кабер ташлары да шундый (Юсупов, 7 нче һәм 41 нче язмалар). Башкалары, Хорасан һәм Азәрбайҗанда Илханлы һәм Тимурлылар дәверендә булганча нәфис һәм камил сәнгать әсәре итеп ясалганнар, көнчыгыш төрки теле белән яки гарәпчә, нәсх яисә сөлес язуы белән язылганнар. Болары татарларның әсәрләре. Әлбәттә, «татар» исеме борынгы Госманлы чорында Анадулыда да булган кебек, «монгол» дигән мәгънәдә түгел. Бу сүз Карахытай һәм Чыңгызыйлар белән бергә көнчыгыштан килгән көнчыгыш төркиләре дигәнне аңлата. Кабер ташы язмалары кебек, Шәрифинең шигырьләре дә бу (көнчыгыш төрки) телне чагылдырган сүз һәм гыйбарәләрне безнең көннәргә кадәр китереп җиткергән. Мондый тарихи истәлекләр арасында Иске Казан каберлекләрендә табылган, яхшы сакланган 900 / 1494 елгы кабер ташын һәм язуын күрсәтергә мөмкин (Юсупов, 54 нче таш). Мин баштарак нәшер ителгән хезмәтләремдә (Төрки-татар тарихы, 1912, б.181 һәм Кереш, б.64) казанлыларга татар исеме ялгышлык белән һәм рус йогынтысында тагылган булырга тиеш, дигән фикер белдергән идем. Госманлы чыганаклары, минем кайбер башка ялгышлыкларым белән беррәттән, бу ялгышымны да төзәтергә мөмкинлек бирде. Казанның русларга каршы сугышлар алып барган иң актив халкы болар булгач, димәк, инде XVI гасырның урталарында ук, госманлыларда «Казан татары» атамасы борынгы «болгар» урынына йөргән.

Шәрифинең әсәре кергән 2348 нче номерлы җыентык моннан тыш Лямигыйның «Гөлестан шәрхе», «Фарсыча-төркичә лөгать (сүзлек)» кебек хезмәтләрне дә эченә алган. Җыентыкның төрле урыннарында 970 елның җемадиуль-әввәл һәм җемадиуль-ахир айларында язылганлыгы күрсәтелгән. Бу — 1563 елның башы дигән сүз. Шулай булгач, Шәрифинең әсәре әлеге җыентыкка, 1550 елның башында язып җибәрелгәннән соң, бары тик 13 ел үткәч кертелгән булып чыга. Әсәрнең әһәмияте — ул заманнарда Урта Иделдә җәелеп алга киткән көнчыгыш төрки әдәбияты үрнәге булудан бигрәк, Казан шәһәрен саклауның ниндидер бер җирле хәрәкәт кенә булмыйча, Кырым, Әстерхан, Нугай иле һәм Сырдәрья төбәге газиләренең оешкан төстәге хәрәкәте булуын ачык билгеләүдә һәм шул ук вакытта, бу хәрәкәтнең инде XIV гасыр башларында ук көнбатыш Алтын Урдада яшәүче христиан динендәге халыкларның көчәюенә каршы тору чаралары булуын күрсәтүдә. Әлеге хәрәкәт Урта Идел буенда Тәбриз һәм Герат якларында Чыңгызый һәм Тимурлылар тарафыннан алга җибәрелгән мөселман төрки мәдәниятенең җәелүенә китергән. «Чура Батыр» дастанында «изге сугышның» идеалы «алга омтылган кяфернең гыйбадәтханәләрен җимерү, алар урынына ак мәчетләр төзү, аларда Аллаһ исеме белән азан укыту» дип билгеләнә. Нәтиҗәдә, Иделдә «каекчылар булган чувашлар» гына

түгел, Нократтан Түбән Новгородка кадәрге җирләрдә яшәгән «укчы чирмешләр» дә, Герберштейн әйтеп үткәнчә, чын мөселман булганнар, Казан руслар тарафыннан басып алынганнан соң, Төркия хөкүмәтенә, әгәр шәһәрне коткарырга теләсәләр, 66 мең сугышчы белән ярдәм итәргә кирәклеген белдерәләр. Казан татарлары, Идел-Дон каналын төзүне Госманлы дәүләтенә тәкъдим иткән вакытта, Әстерханның басып алынуы һәм юллар өзелү сәбәпле, өмет калмаганга, шул ук тәкъдим белән Хива һәм Бохара ханнарына [3] мөрәҗәгать итәләр. 1535 елда Кануни тарафыннан башланган русларга каршы актив сәясәттән рухланып, җанланып киткән Казан газиләре, 1552 елда шәһәрнең басып алынуыннан һәм 1555 ел башкүтәрүләреннән соң, руслар тарафыннан я бастырыла, я Кырымга һәм Уралга качып китәргә мәҗбүр ителәләр. 1567 елда Идел-Дон каналы омтылышының һәм Әстерхан сәфәренең барып чыкмавы, 1572 елда Дәүләтгәрәйнең үлеме, инде «сугышчы татарлар» урынына руслар тарафыннан нигездә Касыйм шәһәрендә җитештерелгән «хезмәтче татарлар» (служилые татары) катламының руслар янында актив көч булып урнашуы кебек җитди үзгәрешләрнең тәэсире, XVII-XVIII гасырларда башкорт башкүтәрүләре вакытында бу ачык күренә. Шул рәвешле, Казанда «газа — изге сугыш» традициясе, 1298 елда бу шәһәрнең корылуы белән башланып, 1550 елга кадәр бөтен көчкодрәте белән бер ярым гасыр дәвам итеп килгән.

Казан шәһәре һәм төбәгенең атамасы Тимур хатларында «Газани», Госманлы документында «Газания» рәвешендә гарәпчә кушымча белән кулланылган. Бу бер затка караганлык кушымчасының, «Газан» исеменә кушылып, «-ныкы» мәгънәсе биргәнлеге ачык. Хаҗи Мәхмүд әфәнде тарафыннан 3394 нче номерлы документта, Газан ханның Болгарга газиләр җибәрүе күрсәтелмәсә дә, «Мәхмүд Газан хан заманында» мөселман татарлар булган бер «җәмәгать»нең, ул заманда Казан исемен алган мәшһүр илгә «газа» өчен килеп, бу җирләрне «ватан» кабул итүләре һәм «Казан татары исеме белән танылулары» белдерелә. Болар һәм читтән килгән башка «газиләр» бирегә ул заманнарда Азәрбайҗанда һәм Хорасанда җәелгән, андагы төркиләр тарафыннан үз ителгән Иран мәдәнияте һәм традицияләрен китергәннәр. Моңа күрше татарларда, нугай, башкорт, казахларда булмаган, бары тик Казан татарларында гына очрый торган гыйбарәләр һәм гореф-гадәтләр дәлил булып тора. Болар арасында, алдарак сүз алып барылган «бистә» сүзеннән башка, ризык исемнәреннән — «бәлеш» (фарсыча «балиш» мендәр дигән сүз), җәмгыять тормышыннан — «мулла»дан «муллазадә», «шейх»тән «шәехзадә», «сейид»дән «сәетзадә» кебек рус чыганакларына да Казан татарчасы сүзләре кебек кергән [4] гыйбарәләрне күрсәтергә мөмкин. 1526 елда Казан хакында кайбер мәгълүматлар калдырган Германия илчесе Барон Герберштейн [5] Казанда «сәет»ләргә карата күрсәтелгән олы ихтирам турында: «Хан боларны каршыларга чыгар, ат өстендә килүче сәетнең кулын үбәр, башка бәкләр аның атының тезгенен, калган дәрәҗәле кешеләр сәетнең аягын үбәрләр», — дигән. Бу исә «сәет»ләргә карата шигыйлекнең йогынтысы белән Газан һәм Улчайту ханнар заманында башланып, Азәрбайҗанда гомумиләшкән бик нечкә хөрмәтнең бер күренеше.

XIII гасырда Болгар җирләрендә яшәгән халыкның күпчелеге, һичшиксез, «болгарлар» була. XIV гасырда исә бу хәл үзгәрә. Төньяк Болгар Бату (Сайын) ханның үз иле булганнан соң, бирегә татарлар күпләп урнаша

башлый. Чөнки әлеге ханның «олы хатыны» Буракчын хатын, Рәшидеддин мәгълүматлары буенча, 70ләп буынга аерылган бик зур «Алчы татар» кавеменнән була. Бу «хатын»ның һәм ханның сарай кешеләре арасында төп таянычны әлеге татарлар тәшкил иткәннәр. Мөселман болгарларының Батуның нәсел-нәсәбе арасында ислам мәдәниятен бик тырышып җәелдерүләре аңлашыла. Батуның оныгы Туктагу хан, саманидларга хас гадәтләргә тугры булып калса да, мөселман Конграт бәкләре нәселеннән булган анасы Улчайту хатын кебек, мөселман була [6]. Аның дәвамчысы булган улы Илбасар исә чын һәм диндар мөселман була [7]. Туктагуның кардәшенең улы, бөек Үзбәк ханның атасы Тугрулча да чын мөселман була [8]. Туктагуның һәм соңрак Үзбәкнең вәзирләре булган Конграт бәкләре Салчудай Күрегян белән Котлыктимүр Күрегян дә мөселманнар. Әлбәттә, болар мөселманлыкны җәелдерүдә ярдәм итәчәк газиләрнең һәм өндәүчеләрнең Газан хан тарафыннан үз «йорт»ларыилләре булган төньяк Болгарга җибәрелүен зур канәгатьлек белән каршылаганнар. Читтән килгән татарлар «Сайын хан йорты»на электән килеп урнашкан Алчы татар кебек кавемнәргә кушылганнар, мөселман һәм дәрәҗәле катлам болгарлар тора-бара боларның телен кабул иткән.

Казан татарлары һәм Көнбатыш Себернең «Төмән татарлары» теле XVI гасырда да бер-беренә якын торган. Төньяк районнарда яшәгән бу татарларда авыл тормышы һәм хуҗалыгы беркадәр алга киткән булган. Үтәмеш Хаҗи боларның Урал якларында урнашканнарына «Мангыт карияләре (авыллары)» дигән. Казан халкына — Болгар, Төмән халкына Найман культурасының [9] йогынты ясаган булуы күренә. Анадулыдагы татарларга карата Хафыз Абру «Кара татар төрекмәннәре» атамасын куллана [10]. Әлбәттә, алар монголча түгел, көнчыгыш төрки телендә сөйләшкәннәр [11]. «Алакчын татарлары» да булган. Казан татарларында көнчыгыш төрки әдәбияты киң җәелгән, Төмән татарларында исә тимерлеләр белән рәсем, сәнгать өлкәсендә үзара багланышар булганлыкка ишарәләр бар [12]. Боларның Бохара белән бәйләнешләре XVI гасырдан соң да дәвам иткән. Шул рәвешле, ислам мәдәниятен җәелдерү үзәкләренең берсе булган Казанда һәр атна җыелышып «Мәснәви-Мәүләна» укыган төркемнәр дә булган [13].

Төрекчәдән
***Асия Рәхимова** тәрҗемәсе*

Искәрмәләр

1. «Yeni Turkistan» (Яңа Төркестан). — Стамбул, 1927. — №2-3. — Б.27-28.
2. Сакланып калган һәм датасы укылган иң борынгы болгарча кабер ташы язмасы һиҗри 756 / милади 1355 елга карый.
3. Halil Inalcik. Belleten. — XII. — S.339-373.
4. Полное собрание русских летописей. — XIX. — С.319.
5. Rerum Moscoviticarum Commentarii, 1862. — Русча басмасы. — С.146.
6. Мурад Ремзи. Тальфикъ, I. — С.500-501.
7. Шул ук әсәр, I. — С.590, 602.
8. Натанзи. Тарих-и Му'ини. Тегеран басмасы. — Б.82.
9. Төмәндә «Тайбуга Йорты» Үтәмеш Хаҗидан башка тагын рус чыганакларында да искә алына. Бу Тайбуганың Чыңгыз тарафыннан Төньякка куылган Найман ханы Тайбуга булуын күрсәткән дәлилләр бар. (Вильяминов-Зернов, Касим цари (Касыйм ханы). — II. — С.386-92; Строгановлар туплаткан мәгълүмат). Бу җирләр XVII гасырда ук «Найман мәмләкәте» исеме белән карталарга кертелгән. (Sven Medin, Southern Tibet. — I. — S.26; VII. — S.17).
10. British Museum. Or. 1577, vr. 326.
11. Зәки Вәлиди Туган. Кереш. — Б.258, 663, 433. Бу мәсьәләгә, Узун Йайладагы татар кабер ташларын өйрәнгәннән соң, тагын да ачыклык керәчәк. Алакчын татарларының теле турында карагыз: Central Asiatic Journal. — VII. — S.66.
12. Islam Tetkikleri Enstitusu Dergisi (Ислам тикшеренүләре институты журналы). — I. — 1954. — S.84.
13. Мурад Рәмзи. Тәлфикъ. — II. — S.433.

ГАЗИЗ ГОБӘЙДУЛЛИН ХЕЗМӘТЛӘРЕНДӘ ТАТАР ХАЛКЫ ТАРИХЫ

ДИЛӘРӘ ГАЛИУЛЛИНА,
тарих фәннәре кандидаты,
Казан (Идел буе) федераль университеты доценты

Татар халкы тарихында тирән эз калдырган шәхесләр күп. Алар арасында озак вакыт югалып, онытылып калганнары да аз түгел. Шуларның берсе — тарих фәнендә, беренче татар профессоры Газиз Гобәйдуллин. Галимнең тормыш юлы һәм иҗаты турында соңгы вакытта күп язылды. Аның иҗатын күккә чөеп мактаучылар да, тискәре караучылар да очрый. Шунысын әйтергә кирәк: 1920-1930 елларда яшәгән һәм иҗат иткән кешеләрнең мирасына бәя бирү аеруча авыр. Ләкин объектив фикер йөртү, аек акылга таянып нәтиҗә ясау — тарихчының төп бурычы. Ул заманда яшәгән кешеләрне тәнкыйть итү җиңел, ә узган вакыйгаларга дөрес анализ һәм аңлатма бирү бик күп факторларны искә алуны сорый.

Г.Гобәйдуллин иҗатына һәм тормыш юлына бәя биргәндә, аның гаиләсен искә алмый мөмкин түгел. Гаилә Г.Гобәйдуллинның тормышында зур роль уйный. Балаларны тәрбияләү белән әниләре Өммегөлсем (Айтуганова) шөгыльләнә. Аның турында җылы сүзләрне Габделкадыйр Гобәйдуллин үзенең автобиографик иншасында язып калдыра. Бу инша 1911 елны III ирләр гимназиясендә рус теленнән имтихан биргәндә языла: «Ул, мин укый белмәгән вакытта, мине китаплар белән кызыксындырды. Безне үз янына җыеп, төрле дини китаплардан өзекләр укый иде: дөньяның барлыкка килүе, Адәмнең җәннәттән куылуы ту-

рында һ.б. Ул үзе күп укыганга һәм белгәнгә күрә, һәрвакыт безнең бәхәсләребезне чишә белә иде. Аның уңай тәэсире миңа гына түгел, бөтен гаиләбезгә тарала иде. Узган ел безнең барыбыз өчен дә кадерле әниебез вафат булгач, хәзергә кадәр бетми торган ниндидер бушлык барлыкка килде» [1].

Гобәйдуллиннарның барлык балалары да фәнгә сәләтле булып үсәләр. Ләкин өлкән уллары Габделгазиз үзенең энесе һәм сеңлесенә караганда күпкә сәләтлерәк икәнен күрсәтә. Шулай да кечкенәләр абыйларыннан калышмый. Кадыйр Гобәйдуллин 1920 елларда этнограф һәм оста каллиграф булып танылa. Ул Көнчыгыш академиясендә каллиграфия укыта. Кызлары Мәрьям шулай ук этнограф буларак танылa, Татарстанда һәм Азәрбайҗанда этнография фәне үсешенә зур өлеш кертә [2].

Гобәйдуллиннар гаиләсе турында сөйләгәндә, икетуган энесе Гали Рәхимне дә (Гали Габдерәхимов) искә алмый мөмкин түгел. Аны күбрәк әдәбиятчы буларак беләләр, ләкин ул тарих белән дә шөгыльләнгән. Гали Рәхимнең татар чыганакларына кагылышлы рус телендә язылган мәкаләләре билгеле. Мәсәлән, «О новом списке татарского исторического сочинения XVII века», «О двух надгробных камнях XVII века» [3] дип аталган хезмәтләре шундыйлардан. Беренчесендә сүз Кадыйр Гали Бәкнең елъязмалар җыентыгы турында бара. 1922 елны Г.Барудиның архивында шул әсәрнең моңа кадәр билгеле булмаган нөсхәсе табыла. Беренче тапкыр бу чыганакны 1851 елда И.Березин бастырып чыгара. Гали Рәхим бу ике кулъязмага күпкырлы анализ ясый. Аның фикеренчә, чыганаклар икесе дә тулы түгел һәм алар бербөрсен тулыландыралар. Профессор М.Госманов Гали Рәхим ясаган текстуаль анализга югары бәя бирә, икенче кулъязманы сыйфатлырак һәм тулырак дип таба [4]. Икенче мәкаләсендә Гали Рәхим XVII гасырга караган ике кабер ташына атрибуция ягыннан, текстологик һәм лингвистик анализ ясый.

Татар галимнәренең бу чорда язылган хезмәтләрендә тарих һәм әдәбият үзара тыгыз бәйләнгән, чөнки әсәрләрнең авторлары бер үк вакытта язучы да, тарихчы да булганнар. Мисал итеп Г.Гобәйдуллин һәм Г.Рәхимнең фундаменталь әсәреннән «Татар әдәбияты тарихы»н әйтеп үтәргә кирәк. Аның беренче өч кисәге — 1922-1924 елларда, ә соңгысы — «Татар әдәбияты: феодализм дәвере» — 1925 елда басылып чыга [5]. Китапның концепциясен Г.Гобәйдуллин төзи, ә материал җыюга Гали Рәхим зур өлеш кертә. Хезмәт Татарстан автономияле җөмһүриятенең Халык мәгариф комиссариаты каршындагы Академик үзәк тәкъдиме буенча языла. Кулъязмалар башта Г.Ибраһимов тарафыннан укыла һәм тикшерелә, ләкин беренче өлеше басылуга, ул бу хезмәтне нык тәнкыйтьләп чыга [6]. Соңрак матбугатта үзенең тәнкыйть мәкаләләре белән Г.Сәгъди дә чыгыш ясый. Г.Ибраһимов фикеренчә, хезмәтнең төп җитешсезлеге тарихи һәм әдәби процессларның марксистик яктан күрсәтелмәвендә [7]. Г.Сәгъди хезмәттә язучыларның шәхси иҗатына тиешле дәрәҗәдә бәя бирелмәгән дип саный [8]. Уңай бәя биргән күренекле фило-

1. Автобиография Абдул-Кадыра Губайдуллина // Эхо веков. — 1998. — №3/4. — С.187; Айтуганов-лар — атаклы сәүдәгәрләр һәм җәмәгать эшлеклеләре (Татарский энциклопедический словарь (ТЭС). — Казань, 1999. — С.19.)

2. ТЭС. — Казань, 1999. — С.161-162.

3. Рахим А. О новом списке татарского исторического сочинения XVII в. // Вестник Научного общества татароведения. — Казань, 1927. — №7. — С.133-148; О двух надгробных камнях XVII в. // Материалы по охране, ремонту и реставрации памятников. — Казань, 1929. — С.14-21.

4. Усманов М.А. Татарские исторические источники XVII-XVIII вв. «Сборник летописей». — Казань, 1977. — С.222.

5. Газиз Г., Рәхим Г. Татар әдәбияты тарихы өчен материаллар җыю юлында бер тәҗрибә. — Казан, 1922 / 1924. — Т.1-3; Татар әдәбияты тарихы. Феодализм дәвере. — Казан, 1925. — Б.313.

лог Җ.Вәлиди хезмәтнең иң әһәмиятле ягын татар халкының тарихы, мәдәнияте буенча материаллар бер хезмәттә тупланган булуда күрә [9].

Бу сүзләргә дәлилне Г.Гобәйдуллинның Гали Рәхимгә 1928 елның 16 гыйнварында Азәрбайҗанның Ганҗә шәһәреннән җибәргән открыткасында күререгә мөмкин. «Мин монда бүген ревизор буларак килдем. Кайбер материаллар да җыйдым. Бүген бер лекция укыдым. Минем белгәнемчә, монда төрки әдәбият тарихын безнең китапның беренче кисәге буенча укыталар. Миңа аның яңа кульъязмасын җибәр әле. Мин аны төрки телгә тәрҗемә иттерермен һәм бастырырга тырышырмын. Аны бик сорыйлар. Укытучылар сине дә, мине дә яхшы беләләр» [10].

Г.Гобәйдуллин белән Гали Рәхим үзләренең хезмәтләренә югары бәя бирәләр. Алар шуңа таянып педагогик-методик кагыйдәләргә нигезләнгән татар әдәбияты тарихы дәреслеген дә язарга уйлыйлар [11]. Ләкин 1926 елны Г.Сәгъдинең «Татар әдәбияты тарихы» дәреслеге басылып чыга. Бу китап Г.Гобәйдуллин белән Гали Рәхимнең хезмәтеннән тамырдан аерылып тора: заман таләпләренә туры китереп, марксистик методларны да кулланып язылган була. Ләкин әлеге дәреслекнең басылып чыгуы Г.Гобәйдуллин белән Гали Рәхимнәр хезмәтенең әһәмиятен киметми. Алар татар халкының язма мәдәниятен генә тикшерми, бәлки фольклорын, борынгы гореф-гадәтләрен һәм халык арасында иран, чагатай, госманлы әдәбиятының киң таралуын да гомуми барыш итеп карыйлар. Безнең фикеребезчә, «Татар әдәбияты тарихы» — милли тарихның һәм әдәбиятыбызның шул чор казанышларын үзенә туплаган иң гүзәл хезмәтләрнең берсе.

Г.Гобәйдуллинны без казан татарлары арасыннан чыккан беренче профессиональ тарихчы буларак беләбез. Аңа кадәр милли тарих өйрәнелмәгән дип әйтеп булмый. Г.Гобәйдуллин Октябрь инкыйлабына кадәр яшәгән татар тарихчыларының традицияләрен дәвам итә. 1917 ел вакыйгаларыннан соң күп кенә галимнәр, яңа тормышка яраклаша алмыйча, үзләренең эшчәнлеген туктата. «Яңа милли тарихчылар», марксистик методларга таянып эш итәргә тырышсалар да, «иске» мирастан арына алмыйлар. Сәбәбе аларның алган белеменә бәйле. Күп кенә татар галимнәре — кадими мәдрәсә шәкертләре. Бу мәдрәсәләрне совет чорында да, хәзер дә тәнкыйтьлиләр. Аларны җәдитчеләр үзләре дә аямаган. Биредә алган белем идеаль булмаган, ләкин бу мәдрәсәләрдән ислам динен, көнчыгыш телләрен, мәдәниятен яхшы белгән кешеләр чыккан. Г.Гобәйдуллин исә, дини белем белән генә канәгатьләнмичә, Казан университетына укырга керә. Аның дөньяга карашы формалашуда шушы ике уку йорты зур роль уйный. Мәдрәсәдә алган белемне ул ислам дине, җәдитчелек хәрәкәте, төрки халыкларның тарихы буенча хезмәтләр язганда киң куллана.

Булачак галимнең тарихи хезмәтләре 1917 елдан соң матбугатта күренә башлый. Без аны күбрәк феодализм чоры буенча белгеч дип беләбез, ләкин фәнгә тәүге адымын ул студент ча-

6. ЦГА ИПД РТ. Ф.81. Оп.1. Д.82. — С.7.

7. Ибраһимов Г. Татар әдәбияты тарихы өчен материаллар // Әдәбият һәм сәнгатъ турында хезмәтләр. — Казан, 1978. — Т.5. — Б.368.

8. Сәгъди Г. Әдәбият тарихымы, тарихи әдәбиятмы? // Безнең юл. — 1923. — №12. — Б.40-44; 1924. — №13 (1). — Б.40-44.

9. Вәлиди Җ. «Татар әдәбияты тарихы өчен материаллар җыю юлында тәҗрибәләр» китабыннан // Безнең юл. — 1924. — №5. — Б.228-230.

10. ИЯЛИ. Ф.81. Оп.1. Д.82. — С.7. (Төрки тел дип ул, билгеле, азәрбайҗан телен атый, ләкин искечә «төрки тел» дип яза.)

11. Шунда ук.

гында ясый һәм беренче хезмәтләре татар халкы тарихы белән бәйле түгел. 1915 елны «Шура» журналында студент Г.Гобәйдуллинның «Марко Поло хакында бер тәҗрибә» [12] дигән мәкаләсе басылып чыга. Соңрак бу хезмәт университетны тәмамлаганда диплом язмасы буларак тәкъдим ителә. Рус телендә язылган диплом эше сакланып калмаган. Шуңа күрә Г.Гобәйдуллинның алдан язылган мәкаләсенә нинди үзгәрешләр кертkәнлеге билгесез. Ул Марко Полоның язмасын Хубилай хан заманында империянең эчке тормышын чагылдырган әһәмиятле чыганак буларак анализлый. Мәкаләне, чын мәгънәсендә, фәнни хезмәт дип әйтеп була, чөнки автор чыганакларны тәнкыйди күзлектән карый, мөстәкыйль фикер йөртә һәм нәтиҗәләр ясый. Шулай ук Г.Гобәйдуллин Марко Полоның хезмәтен Рубрук, Плано Карпини язмалары белән дә чагыштыра. Аның фикеренчә, Марко Поло гади халыкның тормышын, гореф-гадәтләрен начар тасвирлаган, күбрәк хан, югары катлам кешеләре белән аралашкан һәм сарай тормышы турында кыйммәтле мәгълүмат, фактлар туплап калдырган.

Газиз Гобәйдуллин. 1936 ел

Тарихчы Г.Гобәйдуллинны күбесенчә феодализм дәвере кызыксындыра. Аерып алганда, казан татарларының тарихында тирән эз калдырган өч дәүләт язмышы: Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда, Казан ханлыгы аның фәнни эзләнүләренең үзәгендә тора. Шушы схема буенча татар халкының тарихын өйрәнүне иң беренче Ш.Мәрҗани тәкъдим иткән була. Соңрак бу традицияне, кайбер үзгәрешләр кертеп, үзләренең хезмәтләрендә Р.Фәхретдинов, Һ.Атласи, Б.Баттал һ.б. дәвам итәләр [13]. 1917 елга кадәр эшләгән тарихчылар да феодаль чорны өйрәнүгә өстенлек бирәләр, чөнки 1552 елдан соң булган вакыйгалар турында, көчле цензурага бәйле рәвештә дөресен яза алмыйлар. Шулай ук халык күтәрелешләре, милли хәрәкәт белән бәйле материаллар архивлардан бирелми.

Г.Гобәйдуллинның Болгар һәм Казан ханлыклары тарихына багышлап махсус язылган әсәрләре юк. Бу дәүләтләрнең тарихы галимнең гомуми хезмәтләрендә чагылыш тапкан. Мәсәлән, «Татар тарихы», «Русия тарихы», «Из прошлого татар» һ.б. [14]. Болгар һәм Казан ханлыклары турында революциягә кадәрге чорда Ш.Мәрҗани, Һ.Атласи һ.б. хезмәтләрендә яхшы тасвирлана. Шуның өстенә 1923 елны М.Худяковның «Очерки по истории

12. Газиз Г. Марко Поло хакында бер тәҗрибә // Шура. — 1915. — №11-18.

13. Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвәли Казан вә Болгар. — Казан, 1989. — Б.415; Атласи Һ. Себер тарихы. Сөембикә. Казан ханлыгы. — Казан, 1993. — Б.446; Баттал Б. Казан төркиләре. — Казан, 1996. — Б.190; Фәхретдинов Р. Болгар вә казан төрекләре. — Казан, 1993. — Б.287 һ.б.

Казанского ханства» [15] дигән монографиясе басылып чыга. Г.Гобәйдуллин бу хезмәткә югары бәя бирә [16]. М.Худяков, рус тарихчылары арасыннан беренчеләрдән булып Казан ханлыгының «варвар дәүләте» булмаганын дәлилли. М.Худяков Г.Гобәйдуллинның «Шаһгали (тарихи-психологик этюд)» дигән китап язуы турында хәбәр итә. Шулай ук ул бу хезмәтнең «рус дәүләте» тарафыннан тулысынча конфискацияләнүе турында да яза. Кызганыч, әлеге китап турында башка бернинди дә мәгълүмат табылганы юк.

Алтын Урда тарихын Г.Гобәйдуллин аеруча кызыксынып өйрәнә. Татарлар бу дәүләтнең тарихы турында язсалар да, фәнни яктан тирәнтен өйрәнмиләр. Рус галимнәренең хезмәтләрендә күбрәк тискәре караш чагыла, алар дала халыкларының тарихына рус бердәм дәүләте оешканны сурәтләгәндә генә мөрәҗәгать итәләр. 1917-1925 елларда язган эшләрен Г.Гобәйдуллин Алтын Урда ханлыгының төрле аспектларын өйрәнүгә багышлый. Моны мәкаләләрнең исемнәреннән дә күреп була: «Бик борынгы заманнардан алып Тимер балаларына кадәр төрки-монголларда хатыннарның тоткан урыны», «Кыпчак ханлыгының эчке төзелеше» һ.б. Соңгысы Г.Саблуковның «Очерк внутреннего устройства Кипчакского царства» дигән хезмәтенә таянып языла [18]. Алтын Урда ханлыгының таркалуы сәбәпләрен тарихчы түбәндәгеләр дип саный:

— XV гасырда Көнбатыштан Көнчыгышка үтә торган сәүдә юлы үзгәрә. Иран, Һиндстан, Кытайга илтә торган сәүдә юлы элек Идел аркылы Алтын Урда аша узган. Америка ачылганнан соң, күп сәүдәгәрләр арзанрак юлны — диңгез юлын сайлыйлар. Нәтиҗәдә, казна бушап кала;

— XV гасырда көчәеп киткән госманлы төрекләре Дарданелланы үз кулларына төшерәләр һәм Алтын Урда белән сәүдә иткән итальянлыларга зур салым салалар. Итальян сәүдәгәрләре бу ханлыкны читләп үтәргә мәҗбүр була;

— руслар ясак түләүдән туктыйлар;

— үзара барган сугышлар дәүләтне көчсезләндерә һәм таркалуга китерә.

Тарихчының бу фикерләре формалашуга М.Н.Покровскийның шул елларда популяр булган «сәүдә капитализмы» теориясе дә нык тәэсир иткән. Алтын Урда таркалганнан соң, аның нигезендә, галимнең фикеренчә, яңа дәүләтләр түгел, ә элеккеге вассаллар мөстәкыйльлек ала. Бу дәүләтләрнең эчке төзелешендә, сәясәтендә һәм мәдәниятендә Г.Гобәйдуллин Алтын Урда ханлыгының варисларын күрә [19]. Казан ханлыгы Алтын Урданың икътисади яктан иң алдынгы «Болгар олысыннан» оеша һәм монда феодализм институтлары күбрәк Көнбатыш Европа тибында була. Казан ханлыгы дәверен галим «алга киткән феодализм» чоры дигән термин белән атый [20]. Махсус рәвештә Казан ханлыгының җиңелү сәбәпләрен карамый, ләкин кайбер фикерләрен яза. Аның фикеренчә, зәгыйфь дәүләт көчлерәге тарафыннан яулап алыну тарихи кануннарга туры килә. Казан ханлыгы оешкан ва-

14. Газиз Г.Татар тарихы. — М., 1925. — 280 б.; Русия тарихы. — Казан, 1919. 124 б. Из прошлого татар // Материалы по изучению Татароведения. — Казань, 1925. — С.71-111.

15. Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. — Казань, 1923. — С.387.

16. Губайдуллин Г. Что сделано в области социальных наук в татарской республике в течение пяти лет // За пять лет. — Казань, 1925. — С.170.

17. Худяков М. Указ.соч… — С.14-15.

18. Газиз Г. Бик борынгы заманнардан алып Тимер балаларына кадәр төрек-монголларында хатыннарның тоткан урыны // Аң. — 1917. — №3-6; Кыпчак ханлыгының эчке төзелеше // Шәрекъ кызы. — 1918. — №5-6 һ.б.

19. Газиз Г. Татар тарихы. — М., 1925. — Б.99-100.

20. Шунда ук. — Б.103.

кытыннан бирле хәрби лагерьны хәтерләткән. Шуңа күрә югары мәдәни казанышларга да ирешә алмаган [21]. Тарихчы Мәскәүгә Казанны яулап алырга этәргеч биргән сәбәпләрне дә карый:

— Алтын Урда дәүләте таркалган вакытта, рус җирләрендә бөтенләй башка хәл — берләшү процессы бара. Феодализм чорыннан сәүдә капитализмына күчкәндә, Русия икътисади яктан уңайлы сәүдә юлында урнашкан Казан ханлыгына игътибар итә;

— Казанны яулап алу белән Русиядә җир җитмәү мәсьәләсе дә хәл ителә ала. Төп сәбәп халык санының артуында һәм югары катлауның яңа утарлар таләп итүендә;

— дини сәбәп тә була. Бөтен мөселманнарны рус христиан чиркәве дошман дип саный һәм аларны юк итәргә омтыла [22]. М.Худяков шулай ук «дини фанатизм» белән бәйле максатны махсус аерып күрсәтә [23].

Г.Гобәйдуллин фикеренчә, Казанны яулап алу феодаль тәртипләрнең җимерелүенә китерә һәм «сәүдә капитализмына» юл ача. Рус хөкүмәте басып алган җирләрдә яңа тәртипләр урнаштыруны феодаль сыйныфка каршы репрессияләрдән башлый. Руслаштыру һәм христианлаштыру сәясәте нәтиҗәсендә Казан феодалларының бер өлеше чукына, ә риза булмаганнары сәүдәгәрлек белән шөгыльләнергә мәҗбүр була. Русия эчендә татар сәүдәгәрләре зур уңышка ирешә алмый, аларга дәүләт тарафыннан төрле киртәләр куела. Ә менә рус «сәүдә капиталы» үтеп керә алмаган Урта Азиядә татар сәүдәгәрләре өчен киң мөмкинлекләр ачыла. Үзенең «Из истории торгового класса приволжских татар» дигән мәкаләсендә галим XVIII-XIX гасырда татар сәнәгатенең үсешен анализлый. Ул чордагы татар эшмәкәрләренең мануфактураларында крепостной крестьяннар эшләмәгән, шуңа күрә җитештерүчәнлек тә югары булган. Ул бу мануфактураларны капиталистик предприятиеләргә якын булган дип саный [24].

1917 елгы инкыйлабтан соң сыйнфый көрәш тарихын өйрәнү иң актуаль темаларның берсенә әйләнә. Аны анализлаудан Г.Гобәйдуллин да читтә калмый. Ул, беренчеләрдән булып, Степан Разин һәм Емельян Пугачёв җитәкчелегендәге халык күтәрелешләрендә татарларның катнашуын тирәнтен тикшерә [25]. Тарихчы бик кызыклы нәтиҗәләргә килә. Аның фикеренчә, татарлар һәм башкортларның Пугачёв күтәрелешендә катнашуы бер үк дәрәҗәдә тигез булмый. Башкортларның бөтен катлам вәкилләре диярлек Пугачёв ягына чыга. Сәбәбе бик гади. XVIII гасырда рус хөкүмәте башкортларны бөтен яклап кысрыклый, шуның нәтиҗәсендә 1735-1741 елларда көчле халык күтәрелешләре башлана. Галим фикеренчә, башкортларның Пугачёв ягында сугышуы сыйнфый характерда булмый, ә милли-азатлык көрәшен хәтерләтә. Татарларның милли-азатлык хәрәкәте XVI-XVII гасырларга туры килә, ә XVIII гасырда сүнә бара. Шуңа күрә Пугачёв явында татарлар арасыннан күбрәк «кара халык» катнаша. Г.Гобәйдулин бу юнәлешне өйрәнүгә зур өлеш кертә алмавын яза. «Пугачёв явында татар-башкорт-

21. Газиз Г. Идел буе өчен көрәш тарихыннан // Мәгариф. — 1923. — № 5-6. — Б.19-37; Из прошлого татар // Материалы по изучению Татарстана. — Казань, 1925. — С.75-111.

22. Газиз Г. Русия тарихы. — Казан, 1919. — Б.46; Татар тарихы. — М., 1925. — 141 б.; Из прошлого татар // Материалы по изучению Татарстана. — Казань, 1925. — С.75-111.

23. Худяков М. Указ. соч... — С.123.

24. Губайдуллин Г. Из истории торгового класса приволжских татар // Известия восточного факультета Азербайджанского университета Востоковедения. — Баку, 1926. — Т.1. — С.52-56.

25. Газиз Г. Стенька Разин һәм татар крестьяннары // Безнең юл. — 1923. — №8-9. — Б.28-30; Пугачёв явында татар-башкортлар // Безнең юл. — 1923. — Б.28-30 һ.б.

лар» мәкаләсендә ул татар һәм рус телләрендә басылып чыккан материалларны гына куллана алуын, ә Мәскәү һәм Петербург архивларында эшли алмавын искәртеп үтә [26].

Г.Гобәйдуллинның татар халкы тарихын өйрәнүгә, бигрәк тә Казан ханлыгы яулап алынганнан соң, татар җәмгыятендәге иҗтимагый, сыйнфый үзгәрешләрне барлауга керткән өлеше зур. Шушы уңайдан аның «Татарларда сыйныфлар тарихы: XVII, XVIII, XIX гасырларда» дигән хезмәтен әйтеп үтәргә кирәк [27]. Архив материаллары нигезендә язылган бу монография 1925 елда гына да ике тапкыр басылып чыга. Хезмәтендә тарихчы «сыйныф» төшенчәсен киңрәк мәгънәдә куллана: «сыйныф» дип мәдәни, иҗтимагый, икътисади ихтыяҗлары уртак булган кешеләр төркемен билгели. Ул XIX гасырда татар җәмгыяте алты сыйныфтан торган дип саный: аристократия, дин әһелләре, «служилые татары», сәүдәгәрләр, ясаклы һәм алпавыт крестьяннары [28]. Тарихчының бу фикере белән килешүе авыр, чөнки татар феодаллары XIX гасырда бик аз санда була, ә йомышлы татарлар дигән төркем сакланмый. Г.Гобәйдуллин яңа тормышка һәм сәясәткә яраклашырга тырышкан, шуңа күрә хаталар да җибәргән.

Инкыйлабка кадәр һәм 1920 елларда актуаль булган тагын бер проблема этноним белән бәйле була. Татар тарихчыларын «татар» этнонимының килеп чыгуы кызыксындыра. XIX гасырга кадәр җирле халык «татар» этнонимын танырга теләми. XIX гасыр ахыры — XX йөз башында этноним язмышы татар милләте язмышы белән турыдан-туры бәйләнештә кабул ителә башлый. Б.Баттал: «Ш.Мәрҗани белән К.Насыйри беренчеләрдән булып үзләренең тарихи хезмәтләрендә «татар» этнонимын кулланалар һәм аны яклап чыгалар», — дип яза [29]. Ш.Мәрҗани фикеренчә, бу атаманы тарих үзе беркеткән: «тирә-юньдә барысы да безне «татар» исеме астында таный». Ул атамада бернинди дә начарлык күрми, чөнки Батый хан гаскәрләренә безнең бернинди дә мөнәсәбәтебез юк иде, дип белдерә [30]. Ләкин бу четерекле мәсьәләне чишәр өчен Ш.Мәрҗанинең дә абруе җитми. Р.Фәхретдинов үзенең «Болгар һәм Казан төрекләре» дигән китабында «татарлар» дип Алтын Урда халкын гына атый. Казан татарларын «төрекләр» яисә «мөселманнар» дип атап йөртә. Бу этнонимга каршы чыгучылар арасында Г.Гобәйдуллин да була. «Милләтчелекнең бәгъзе әсаслары» дигән хезмәтендә ул халыкның «татар» атамасына каршы булуын бу исемнең руслар тарафыннан тискәре мәгънәдә кулланылуында күрә [31].

Этноним мәсьәләсен өйрәнүгә Г.Гобәйдуллин ике хезмәтен багышлый: «Төрекме, татармы?», «Татарларның килеп чыгышы мәсьәләсенә карата» [32]. Икесендә ике төрле караш, капма-каршы фикерләр яза. Беренчесендә ул «Идел буе төрекләре» (1918 ел) дигән атаманы яклап чыга. Аның фикеренчә, «татар» атамасы этнографик яктан да, лингвистик яктан да безнең халыкның килеп чыгышына туры килми. Иске кытай һәм көнчыгыш чы-

26. Газиз Г. Пугачёв явында татар-башкортлар // Безнең юл. — 1923. — №10-11. — Б.28-30.

27. Газиз Г. Татарларда сыйныфлар тарихы: XVII, XVIII, XIX гасырларда. — Казан, 1925. — Б.60.

28. Шунда ук.

29. Батал Б. Казан төркиләре. — Казан, 1996. — Б.190.

30. Мәрҗани Ш. Мөстафадел... — Б.27.

31. Газиз Г. Милләтчелекнең бәгъзе әсаслары. — Казан, 1918. — Б.5. (Башта бу эш 1913 елны «Аң» журналында «Милләтне ничек тәгриф кылырга?» дигән исем астында анкета сорауларына җавап буларак басылып чыга.)

32. Газиз Г. Төрекме, татармы? — Казан, 1918. — 11 б.; К вопросу о происхождении татар // Вестник научного общества Татароведения. — Казань, 1928. — №8. — С.130-140.

33. Газиз Г. Төрекме, татармы? — Казан, 1918. — Б.11.

ганакларына таянып, борынгы татар кабиләләре этник килеп чыгышлары белән монголлар булганнар дип саный [33].

Ун елдан соң тарихчы бу мәсьәләгә яңадан әйләнеп кайта һәм бөтенләй башкача фикер йөртә. Яңа мәкаләсендә ул «татар» атамасын яклый. Хәзер инде галим иске кулъязмаларның текстларын борынгы татарларның төрки халык булуын дәлилләү өчен куллана [34]. Кулъязмалар бик буталчык мәгълүмат җиткерә, шуңа күрә ялгышуы да җиңел. Ләкин этноним мәсьәләсе бу елларда сәясәт белән дә тыгыз бәйләнгән була. Революциядән соң яңа дәүләтнең эчке төзелеше буенча күп кенә проектлар эшләнә. Татарлар да үзләренекен тәкъдим итә, ләкин берсе дә кабул ителми. 1920 елны Татарстан автономияле җөмһүрияте төзелгәннән соң, этноним буенча дискуссияләрнең кирәклеге калмый.

Г.Гобәйдуллин — казан татарлары тарихын профессиональ өйрәнгән беренче татар галиме, дидек. Ул шулай ук башка төрки халыкларның тарихын өйрәнүгә дә зур өлеш кертә. Бу уңайдан аның И.Гаспралыга багышланган хезмәтләрен әйтеп үтәргә кирәк [35]. Кызганычка каршы, боларның күбесе соңгы елларда гына кабат дөнья күрде. Галим беренчеләрдән булып И.Гаспралының идеологиясе нигезләрен генә өйрәнеп калмый, ә татарлар арасында киң җәелгән җәдитчелек хәрәкәтен дә анализлый. «Гаспринский һәм тел» исемле мәкаләсендә XIX гасыр ахыры — XX йөз башы өчен актуаль булган милли тел мәсьәләсе күтәрелә [36]. И.Гаспралы бу чорда Русиядә яшәүче барлык төрки халыклар өчен «уртак тел» идеясен күтәреп чыга. Ләкин милли зыялылар 1905 елгы инкыйлабтан соң, киресенчә, һәр төрки халыкның үз әдәби теле булырга тиеш дип белдерәләр. Г.Гобәйдуллин, марксистик идеологиягә нигезләнеп, бу карашларны анализларга омтыла: әйтик, Гаспралы фикерен «Тәрҗеман»ның буржуаз газета булуы белән бәйли [37]. Дөрес, мондый фикерләр элегрәк тә яңгырый. Җ.Вәлиди, мәсәлән, 1914 елда ук И.Гаспралыны «буржуа идеологы» дип атый [38]. Г.Гобәйдуллин «уртак тел» идеясе барып чыкмауның төп сәбәбен аны гади халык аңламауда күрә, шуңа күрә XX гасыр башында «татар буржуа интеллигенты» ана телендә басма әдәбият кирәклеген бик яхшы аңлый [39]. Соңрак бу өлкәдә башка карашлар да барлыкка килә. Әйтик, И.Гаспралының иҗатын һәм тормыш юлын өйрәнүче В.Ю.Ганкевич атаклы реформатор аерым, махсус «Гаспралы теле» барлыкка китергән дип белдерә [40]. Ләкин XX гасыр башында Русиядә эчке сәяси, иҗтимагый вакыйгалар бу процессның җәелүе мөмкин түгел икәнен күрсәтә.

Г.Гобәйдуллин — татар тарихын Көнбатыш Европа стандартларына якынайткан шәхес. Халкыбыз тарихындагы күп кенә фәнни юнәлешләр аның тарафыннан өйрәнелә башлый һәм ул киләсе буын тарихчылары өчен нигез салып калдыра. Галимнең күпкырлы иҗаты, авыр һәм сикәлтәле тормыш юлы ихтирамга лаек. ■

34. Губайдуллин Г. К вопросу о происхождении татар // Вестник научного общества Татароведения. — Казань, 1928. — №8. — С.130-140.

35. Губайдуллин Г. К вопросу об идеологии И.Гаспринского (предварительные материалы) // Известия восточного факультета Азербайджанского университета Востоковедения. — Баку, 1929. — Т.4. — С.179-208; К вопросу об идеологии Гаспринского (продолжение изданной части) // Исмәгыйль Гаспралы. Тарихи документаль җыентык. — Казан, 2006. — С.307-332.

36. Губайдуллин Г. Гаспринский и язык // Эхо веков. — 1997. — №3-4. — С.205-214.

37. Шунда ук.

38. Шунда ук. — Б.213.

39. Шунда ук. — Б.211.

40. Ганкевич В.Ю. На службе правде и просвещению. — Симферополь, 2000. — С.193.

НИГЕЗ

БАБАЛАРЫМ МИРАСЫ

АЛЬТА МӘХМҮТОВА,
тарих фәннәре кандидаты,
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Ш.Мәрҗани исемендәге премиясе лауреаты

СОҢГЫ УНБИШ-ЕГЕРМЕ ЕЛДА БЕЗ ҮЗ ТАМЫРЛАРЫБЫЗ БЕЛӘН КЫЗЫКСЫНА БАШЛАДЫК. КҮП КЕНӘ ТӨБӘКЛӘРДӘ АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ ТУРЫНДА КИТАПЛАР НӘШЕР ИТЕЛӘ. ЛӘКИН АЛАРНЫҢ КҮПЧЕЛЕГЕН БЕРЛӘШТЕРГӘН БЕР ҮЗЕНЧӘЛЕКНЕ КҮРСӘТӘСЕМ КИЛӘ: АВЫЛНЫҢ БОРЫНГЫ ТАРИХЫ АРТЫК ДӘЛИЛ-ЭЗЛӘНҮЛӘРСЕЗ ГЕНӘ «АВЫЛ БОЛГАР (АЛТЫН УРДА, КАЗАН ХАНЛЫГЫ) ЧОРЫННАН БИЛГЕЛЕ» КЕБЕК МӘГЪЛҮМАТЛАРДАН УЗМЫЙ. КАЛЫН-КАЛЫН КИТАПЛАР ИСӘ, НИГЕЗДӘ, АВЫЛНЫҢ СОВЕТ ЧОРЫН ТАСВИРЛАУ ҺӘМ АВЫЛДАН ЧЫККАН ТАНЫЛГАН ШӘХЕСЛӘР БЕЛӘН МАКТАНУГА КАЙТЫП КАЛА.

Бибисара Әйзатулла кызы һәм Вәлиәхмәт Сәгъдетдин углы Субаевлар. Алабуга, 1949 ел

Ләкин авыл тарихы авылдан читтә яшәүче танылган шәхесләр тарихы гына түгеллеген онытмасак иде. Авыл тарихы — анда яшәгән һәр кеше тарихы, бу тарихта һәркем кадерле. Һәрбер авылның йөзен билгеләгән нәселләр, буыннан-буынга ихтирам белән искә алынучы яки онытыла язган шәхесләр була. Бу тарихны язу күп кенә эзләнүләр, хезмәт таләп итә. Һәм аны язуда гаиләләрдә сакланып килгән риваятьләр, нәсел шәҗәрәләре нигез була ала. Шәҗәрәләреннән өзелгән бүгенге буыннар өчен бу бигрәк тә мөһим. Шуны исәпкә алып, мин Чүпрәле районы Мунчәли авылына караган язмамны тәкъдим итәргә булдым.

Минем әнием, Вәлиәхмәтева Рөкыя Вәлиәхмәт кызы (1909, Мунчәли — 1982, Бәзәкә), Сембер губернасы Буа өязе Мунчәли (Мөчәли) авылында буыннан буынга мулла һәм мөдәррис хезмәтен үтәгән Субаевлар нәселеннән булган. Тормыш җилләре аны 1931 елда Татарстан Республикасы Алабуга (соңрак Бондюг) районы Бәзәкә авылы мәктәбенә татар теле һәм әдәбияты укытучысы буларак китергән. Һәм ул, 1934 елда шул авыл кешесе, ул елларда авыл советы секретаре булган Мәхмүтов Хаҗиәхмәткә кияүгә чыгып, 1978 елга кадәр Бәзәкәдә яшәде.

Үз эшен яратып башкарган әнием миңа үземне белә башлаганнан бирле үрнәк булды. Укытучы булырга теләгем барлыгын белгәч, аның, мине хуплап: «Безнең җиде буын бабаларыбыз балалар укыткан. Укытучы эшеннән дә хөрмәтлерәк, балаларны тәрбияләү, аларга белем бирүдән дә кирәклерәк эш дөньяда бар микән?» — дип әйткәне күңелемә уелып керде (миңа ул вакытта җиде яшь иде). Әлбәттә, кызыксынучан бала буларак, мин җиде буын бабаларым хакында сораша башладым. Ләкин, күпме генә белергә теләсәм дә, ул чагында әни алар хакында бернәрсә дә сөйләмәде. Без үскән заманда туган-тумача, гомумән, шәхси тормышка кагылган мәсьәләләр хакында сорашу ярамый, кызыксынуыбызны туктатырга ике сүз җитә иде: «Үскәч белерсең».

Чыннан да, үскәч белдем. Тарих 1917 елдан гына башлана, аңа кадәр караңгылык, наданлык хөкем сөргән гади халык тормышының бер кызыгы да булмаган, дип формалашкан кеше, үсеп җиткәндә, үз нәселебез тарихы белән кызыксынмаска өйрәнгән идем инде. Җиде буын бабаларыбыз тарихы белән дә мин бик соң, олыгайгач кына кызыксына башладым.

XX гасырның 70 нче еллар урталарында булды бу хәл. Архивта татар мәгарифе тарихына кагылышлы материаллар барлап утырганда, бабамның исеме кергән документка тап булдым. Ул 1909 елның 1 гыйнварына Сембер губернасы Буа өязендә эшләп килгән мәдрәсәләр һәм аларның мөдәррисләре исемлеге иде. Анда Мунчәли авылында ике мәчет һәм алар каршында ике мәдрәсә булуы, икенче мәхәллә каршындагы мәдрәсәне мәхәллә имамы Вәлиәхмәт Субаев җитәкләве һәм җәдид ысулы белән укытуы күрсәтелгән иде. Бу документ минем нәсел тарихы белән кызыксынуымны уятып җибәрсә дә, әнидән һәм әниемнең абыйсы Шаһвәли абыйдан (1906-1987) сорашудан артыкка китмәдем. Дөрес, алардан нәселебез тарихы хакында язуларын да сорап карадым. Ләкин алар да истәлекләре белән бүлешергә бик әзер түгелләр иде.

Шаһвәли абый миңа сәбәбен дә аңлатты. XIX гасырның икенче яртысы — XX гасыр башында имам һәм мөдәррисләр булып хезмәт иткән өч бабам нәсел тарихын язганнар икән. Ләкин төрле сәбәпләр аркасында бу өч кулъязма да юкка чыккан. Мөхәммәдәмин бабайның кулъязмасы XIX гасыр ахырында авылдагы зур янгын вакытында көлгә әйләнгән. Сәгъдетдин бабай аны яңабаштан язган. Әмма 1911-1912 елларда, төрле төбәкләрдә җәдидче муллалар арасында тентү-кулга алулар башлангач, Сәгъдетдин бабай барлык кулъязмаларын үз кулы белән яндырган. Бабам Вәлиәхмәтнең кулъязмасы 1931 елда, аны кулга алганда, юкка чыккан. «Минем тырышуларым да бушка булачак», — диде ул.

Шулай да очрашканда мин Шаһвәли абыйны сораштыра килдем. Аның хәтере яхшы, кызык итеп сөйли. Дөрес, ул олыгая барган саен, очрашулар сирәгәйде. Ниһаять, 1980 еллар башында нәсел тарихын язарга тотынуын әйтте. Шул вакытта ул миңа безнең заманга килеп җиткән шәҗәрәбезне дә язып бирде: Тәкәш — Ирәй — Сыбай — Мостафа — Гомәр — Мөхәммәдәмин — Сәгъдетдин — Вәлиәхмәт — Шаһвәли (Рөкыя — Альта).

Хәзер, Шаһвәли абый язмаларга һәм нәселебездә сакланган башка мәгълүматларга үземнең хатирәләремне, тарихи белемемне кушып, мин бабам һәм нәселебез тамырлары хакында язарга җөрьәт итәм.

Исеме билгеле булган иң борынгы бабабыз Тәкәш 1565 елда Касыйм ханлыгында Мишәр кара урманнары, сазлыклары эчендә, Ока елгасы буенда урнашкан бер утарда дөньяга килгән. Чыгышы нинди катламнан булуы хакында төгәл мәгълүматлар юк.

Тәкәш бабадан әүвәлгеләренең исемнәре безнең көнгә килеп җитмәсә дә, буыннан буынга сөйләнеп килгән риваятьләр нәсел тамырларын борынгы болгарларга бәйлиләр. Бу риваятьләрдә бабаларыбыз кышын Болгарда һәм аның тирәсендәге авылда, җәен далада яшәүләре, иген игү, ат үрчетү һәм сәүдә белән шөгыльләнүләре, зур яуда хуҗалыклары тар-мар ителгәннән соң исән калганнары, мишәр сазлыкларына барып җитеп, хуҗалыкларын яңартулары хакында бәян ителә. Риваятьләрдә бу вакыйгалар монгол яулары белән бәйләп сөйләнсә дә, чама белән исәпләгәндә, аларны рус князьләренең XIV гасыр ахыры — XV гасыр башындагы Идел буе яулары белән бәйләү чынбарлыкка якынрактыр дип уйлыйм.

Шаһвәли абый 1970-80 елларда яз-

Субаевлар нәселеннән бер төркем (сулдан уңга): утырганнар – Субаев Вәлиәхмәт кызы Рәкыя, хатыны Бибисара Әйзатулла кызы, килене Маһирә, улы Шаһвәли; басканнар – оныклары Гөлшат (Камәрия кызы), Альта (Рәкыя кызы), улы Вәлимөхәммәт, оныгы Рауза Мәхмүт кызы; аста – оныкчыгы Наилә (оныгы Лалә Мәхмүт кызының кызы), оныклары, Шаһвәли һәм Маһирә балалары Рәшит, Нәфисә, Хәсән, Мөнирә. Алабуга, 1958 ел

ган нәсел тарихында Тәкәш бабаның үзен сөйләтә: «Менә мин үзем 40-45 яшемдә — XVI-XVII гасырлар чигендә — шул Үкә (Ока) елгасы яныннан балутадан (сазлыктан) чыгып, кайта-кайта, шушы хәзерге Татарстанның Чүпрәле районы Мунчәли авылы урнашкан җиргә җитеп, тукталып калган кеше. Без алты гаилә килдек. «Нәрсәгез бар иде?» — дип сорасагыз, менә тыңлагыз. Иярле бер ат, бөтен тормыш кирәк-яраклары ат өстендә, шунда ук ике бала. Мин — атны җитәкләүче, артта хатыным сыер җитәкләгән. Сыер өстендә байтак кына өй җиһазы… Безгә урнашырга кирәк. Урман кирәк, су кирәк, болын кирәк. Менә инде ул урында алары бар. Табигать байлыгы яхшы… Без үзебезнең авылны элекке Болгар җирендәге булган бабайлар яшәгән авыл исеме белән атарга булдык. Ул Мөчәли».

Татар энциклопедиясендә Мунчәли 1666 елдан билгеле дигән мәгълүмат бирелгән. Ләкин Тәкәш бабаның вафатының елы безгә билгеле булмаса да, Мунчәлидә җирләнүе, аның улы Ирәй (Гәрәй) бабабызның 1615 елда Мунчәлидә тууы, авылны, кимендә, ярты гасырга «картайта». Шулай ук шәҗәрәбез һәм риваятьләр Мунчәли авылына нигез салган нәселләрнең берсенең башында Тәкәш бабаның булуын фаразларга да мөмкинлек бирә.

Гәрәй баба сөйләгәннәрдән: «Эшләр яхшырып киткән сыман булды. Ипигә туя башладык дигәндә, безнең авылны учётка алып киттеләр. Ул вакыт безнең авыл егерме-егерме биш йорттан тора иде… Бу бик авыр хәлгә китереп чыгарды. Беренче мәртәбә «ясак» дигән сүзне китереп ишеттерделәр дә һәр колач җир өчен акчалата түләү

билгеләнде. Түләү зур түгел, но акча юк. ... Ашлыкны сатып түләгәч, язда ашарга калмый». Бабаның сөйләгәнен рәсми документлар да раслый. Сембер губернасы гыйльми архив комиссиясе басмасында 1665-1667 елларда Мунчәлидә йомышлы морзалар һәм татарларның 23 йортыннан ясак алынуы күрсәтелгән [1].

Гәрәйнең улы, Тәкәшнең оныгы Сыбай (Субай) 1662 елда Мунчәлидә туган. XVII гасырда Русиядә йомышлы татарларның кайбер иркенлекләре әле сакланган. Ләкин XVIII гасырның беренче чирегендә аларның статусы үзгәргән. Пётр I аларны лашманчылыкка, ягъни кораблар төзү өчен агач хәзерләү, урман эшләрен башкаруга тарту өчен казна (дәүләт) крестьяннары категориясенә күчергән. Мунчәли халкы да ясак түләү өстенә лашманчылык белән шөгыльләнергә мәҗбүр булган.

Субаев Мостафа (дүртенче буын) 1700 елда дөньяга килгән һәм, 1785 елда вафат булып, Мунчәлидә җирләнгән. Нәсел риваятьләренә мөрәҗәгать итеп, Мостафа бабага «сүз бирик». «Мин тугыз-ун яшемдәге вакытларны хәтерлим. Ул вакытта безнең әтиләр мәчет салырга йөриләр, ләкин аны ничек башкарып чыгарга?.. Әзрәк эзләнеп карасалар, нindидер бер авылда мәчет бар икән. Анда биш вакыт намаз укыйлар икән, дигән хәбәр алып кайталар... Инде мин семьялы булганда, безнең авылның уртасында бер өй куелды. Бохарадан укып кайткан бер кеше шунда намаз укырга өйрәтә. Аны «дамелла» дип йөртәләр... Мин дә карт көнемдә, балалар олыгаеп, эшләр-мәшәкатьләр алар кулына күчкәч, бик тырышып, «күңел сабаклары» өйрәндем, хак мөселман булдым... Безнең нәсел бик зур. Минем братым — Мортаза, аның да малайлары бик күп. Мунчәлидә 48 йорт». Мостафа баба үзе өйрәнгән «күңел сабаклары» белән балаларын-оныкларын, күрше-күләнне таныштыра башлаган. Шулай нәселебездә беренче «укытучы» булып киткән.

Субаев фамилиясен нәсел фамилиясе итеп җибәрү исә Мостафаның улы Гомәр (1745-1835) өлешенә тигән булып чыга. Гомәр бабаның өлгереп җитүе Екатерина II заманына (1762-1796) туры килүгә игътибар итик. Мөселманнарга карата алып барылган хакимият сәясәтенә Әби-патша шактый үзгәрешләр керткән чор була бу. Ислам эзәрлекләнә торган диннән рөхсәт ителгән диннәр рәтенә кертелгән. Мөселман диненә тугры калган аз санлы морзалар һәм төрле чиннарда булган йомышлы татарларга кайбер ташламалар кайтарылган (шул исәптән, нәсел фамилиясен саклау да). Күрәсең, Гомәр баба ничектер шушы мөмкинлекләрдән файдалангандыр. Ничек кенә булмасын, нәсел фамилиясенең нигезе булып китү Тәкәш бабага түгел, Субай бабаның исеменә насыйп булган.

Шаһвәли абый Гомәр бабаны да «сөйләткән»: «Безнең заманда бик зур үзгәрешләр булды. Халык артты. Мин яшьрәк чакта авыл илле-алтмыш йорттан торса, хәзер (миңа 70 яшь тулганда) йөздән артты... Мин өйләнгән елларда яхшы манаралы яңа мәчет салынды. Чүти ягыннан бер мулла китерделәр. Муллага эш күп. Җитешә алмагач, мине аңарга ярдәмче итеп куйдылар — бу азанчы дип атала. Ярый инде — үлек юам, күмешәм, бала туса да калдырмыйлар. Мәчетне тазартам, ягып ятам. Иртә-кич азан әйтәм. Ул азан дигәнен өйрәнүе бик кыен булды. Ул бит безнең телдә түгел. Үз телеңдә булса — бер хәл. Мулла да минем белән бик интекте. Ә хәзер безнең балалар укый башладылар».

Гомәр бабаның 1800 елда туган углы Мөхәммәдәмингә (вафаты 1893 елда), нәселдә беренче булып мәдрәсәдә гыйлем алып, мулла-мөдәррис булу язган. Аны, мулла кушкан озын исемен кыскартып, гаиләдә дә, авылда да Дәмин

дип йөрткәннәр. «Минем Дәминемне бик мактыйлар, зиһенле диләр, — дип сөйләвен дәвам иткән Гомәр баба. — Бервакыт, мулла чирләгәч, олылар җыелып килгәннәр мәчеткә минем янга: «Үмәр, малаеңны укыт». — «Ничек укытыйм, ул укый бит», — дисәм, — «Юк, Үмәр, ул алай түгел. Без сиңа хәер-садаканы җәлләмәбез, җирдән дә өлеш чыгарырбыз. Син аны, Сембергәме, Казангамы алып барып, олы муллага, «муллалыкка укыт», дип әйтеп биреп кайт. Укып кайткач, мулла итәрбез». — Шулай итеп мин олы углым Мөхәммәдәминне, Казанга алып барып, укырга тапшырып кайттым».

Шулай 10-15 яшьлек Дәмин Казан шәкерте булып киткән. «Казан бездән 180 чакрым ераклыкта, ат белән дүрт сутка барасы. Кием — шул өйдә теккән тун, киез-ката, тире бүрек, бер-ике кием агач башмак, эчтән өйдә сугылган киндердән күлмәк-ыштан; бер-ике капчык сохари, бер-ике каз түшкәсе, ит-май (аның яртысы хәлфәләргә). Менә шулай итеп һәр елны төяп, Идел туңгач, илтеп куям, язда үзе кайта, җәяү». Дәмин, күпме генә авырлыкларга юлыкса да, түзгән, укырга тырышкан, Казанда да сынатмаган. Һәфтияктән башлап, бөтен кирәкле дини белемнәрне үзләштергән, язарга да өйрәнгән, гарәп, фарсы телләрен дә аңлый башлаган. Бу гыйлемнәрне үзләштерү өчен, гадәти буларак, шәкертләргә мәдрәсәдә 15-20 ел вакыт кирәк булган. Гыйлемле, тырыш шәкерт саналган Дәмин мөдәрриснең ярдәмчесе дә булган — хәлфәлек итеп, үз шәкертләрен дә булдырган. Ләкин, Казанда укуын тәмамлап, авылына имам булып кайтырга җыенганда, ул урынсыз калуы хакында хәбәр алган: Мунчәлинең карт мулласы вафат булып, Сембер ягыннан яңа мулла килеп утырган. Бу вакыйга 1830-1835 елларга туры киләдер дип фаразларга була.

Яхшы шәкерт һәм хәлфә булган Дәмингә мөдәррисе ярдәмгә килгән. «Гадәт буларак, мөдәррис, яхшы укыган, бөтен йомышын кышын-җәен берсүзсез үтәгән шәкертен берәр авылга муллалыкка җибәрә икән». Ул аны Казан артына — Җөлби исемле авылга имамлыкка тәкъдим иткән (хәзер Иске Җөлби — Арча районына, Яңа Җөлби Әтнә районына карый. Дәмин бабаның кайсы Җөлбидә мулла булуы билгеле түгел). Җөлби халкы Казан мәдрәсәсендә гыйлем эстәп килгән белемле яшь мулланы хөрмәтләп каршы алган. Дәмин дә сынатмаган, тырышып, имамлык-мөдәррислек хезмәтен башкара башлаган. Алты-җиде ел эчендә өйләнеп тә куйган, йортлы-күзле булган. Ерак әбиебезнең исеме сакланмаса да, ул күрше Төрекләр авылы (хәзер Әтнә районы) мулласының кызы булган дип фаразларга була. Җөлбидә аларның өч балалары — Сәгъдетдин, Шәрәфетдин, Гайшә — дөньяга килгән.

Мөхәммәдәмин хәзрәт инде урнаштым, төпләнеп җиттем, мул тормыш белән яши башладым дигәндә, туган авылыннан хәбәр салганнар. Карт әтисе туксан яшендә вафат булган, ә Мунчәли халкы авылның яңа өлешендә икенче мәчет сала икән. Үзләре укыткан Дәмин мулланы шул мәчеткә имам итеп чакырганнар. Яңа оешкан мәхәллә халкы бу хакта приговор да җыйган, Дәминнең мөдәррисеннән илчеләр рөхсәт язуы да алып килгән. Җөлби халкы үз иткән муллаларын җибәрмәскә тырышкан. Аларга ярдәмгә абыстайның әтисе һәм туганнары да килгән. Дәмин хәзрәт үзе дә рәткә салынган тормышны билгесезлеккә алмаштырырга бик җилкенеп тормагандыр (туган яклары сагындырса да). Шулай да Мунчәлигә кайтырга ризалыгын бирергә мәҗбүр булган. Илчеләр аңа: «Мир укыткан — миргә хезмәт итәргә тиеш», — дип, чигенергә юл калдырмаганнар.

Бу вакыйга 1840 елларга туры килгән. Имамлык һәм хәлфәлек тәҗрибәсе булган Мөхәммәдәмин хәзрәт яңа

мәхәлләдәге эшләрне дә җайга салган, кечкенә генә мәдрәсәсен дә булдырган, 1851 елдан авылда метрика дәфтәрен алып бара башлаган. Олы улы Сәгъдетдинне (1837-1919), ун яше тулар-тулмас, Казанга, мәдрәсәгә илтеп тапшырган. Әтисе күргән авырлыкларны Сәгъдетдингә дә тулысы белән татырга туры килгән.

Уку барышында Сәгъдетдин ачлыгын-ялангачлыгын җитәрлек күргән, ләкин белемгә омтылу барысын да җиңгән, әтисенә караганда кыскарак вакытта кирәкле белемнәрне үзләштергән. 25-30 яшьләрендә указлы мулла булып авылга кайткан, картайган әтисен алмаштырган. Яшь хәзрәт тирә-юньдә абруе зур булган Иске Задур авылы мулласы Фәтхулла ишан Бикколовның кызы Хөсниҗәмалны никахлап алган. Яхшы гына яшәп китеп, авыл халкына бергәләп хезмәт итә башлаган хәзрәт гаиләсенә тиздән зур кайгы килгән. Чибәр, укымышлы, уңган Хөсниҗәмал абыстай, 40 яшьлек Сәгъдетдин хәзрәтне һәм берсеннән-берсе яшь алты бала — Мәфтуха, Шаһвәли, Галимә, Вәлиәхмәт, Хәдичә һәм Бибисараны калдырып вафат булган.

Бу вакытта Шаһвәли — Казанда мәдрәсә шәкерте. Җиде яшьлек Вәлиәхмәтне хәзрәт Задурга, әбисе карамагына илтеп куйган. Анда Сәгъдетдин бабаның дусты, адашы, «тома сукыр булуына карамастан, бик үткен, зирәк адәм» балалар укыта икән. «Вәлиәхмәт шунда укый, әбисендә тәрбияләнә. Ә тугыз яшь тулуга, мин аны Сембер мәдрәсәсенә укырга җибәрдем», — дип сөйләгән оныгына Сәгъдетдин баба.

Ә авылда кайгы өстенә кайгы өстәлгән — мәдрәсәдә укуын тәмамлап Казаннан кайткан Шаһвәли вафат булган. Озакламый 80 яшьлек картын калдырып, Сәгъдетдиннең әнисе дә фани дөньядан бакыйга күчкән. Шулай аталы-уллы хәзрәтләр абыстайларсыз калганнар. Нишләмәк кирәк? Сәгъдетдин хәзрәт үзе дә өйләнгән, әтисен дә өйләндергән. «Менә өч-дүрт елдан аталы-уллы икебез дә ике өйдә яшь бала тәрбиялибез. Әтидә бер угыл, бер кыз бала, миндә дә. Әтигә — 84, миңа 47 яшь ул вакытта. Менә санап карыйк: минем өстә күпме халык — барлыгы унике баш!.. Ник кенә аларның берсе урманга барып утын китererлек я тегермәнгә барып он тартырлык, сука сукаларлык булсын икән! Менә бу минем тормышта иң караңгы, иң авыр көннәр булып истә калган», — дип сөйләгән ул оныкларына.

Сәгъдетдин бабаның барлыгы тугыз баласы булган. Икенче хатыныннан туган Әминә һәм Каюмга Ибраһим исемле төпчеге дә өстәлгән. Менә кызлар да үсеп җиткән. Кыз баланың язмышы ата кулында. Чибәр, уңган кызларны сорап килүчеләр дә җитәрлек булган. Дөнья мәшәкатьләре басып киткән Сәгъдетдин баба кызларын ерак җибәрмәскә тырышкан: Мәфтуханы — Ишлегә, Хәдичәне — Буага һәм Бибисараны Чүпрәлегә кияүгә биргән. Ә Галимәне әбисенең туган ягыннан — Төрекләрдән хатыны вафат булган бер кешегә сорап килгәннәр. Туган ягыннан аерылырга теләмәгән Галимә бик еласа да, Сәгъдетдин баба үзе дә башта каршы торса да, ризалашырга туры килгән. «Заманында Дәмин хәзрәт безнең кызыбызны монда алып китте, аңа да җиңел булмагандыр, хәзер бурычыгызны кайтарыгыз», — дип, Галимәне Төрекләргә алып киткәннәр.

Сәгъдетдин баба улларының язмышы XX гасыр давылларын кичергән буыннарның язмышы белән уртак. Чит җирләрдә ачлы-туклы хәлдә мәдрәсәләрдә гыйлем эстәү, белемгә омтылу һәм, мең төрле бәлаләрне җиңеп, кайда гына булса да халкына хезмәт итү!.. Бу фикер минем бабам Вәлиәхмәт өчен дә тормышында маяк, юлкүрсәткеч булган. Олы улы Шаһвәлинең вакытсыз үлеменнән соң,

Субаев Вәлиәхмәт онықлары (сулдан уңга): Алиса (Рөкыя кызы), Нәфисә Шаһвәли кызы, Гөлшат (Камәрия кызы), Альта (Рөкыя кызы), Рауза Мәхмүт кызы. Казан, 2007 ел

Сәгъдетдин баба бар өметен икенче улы Вәлиәхмәткә юнәлткән. Җиде яшендә әнисез калган кечкенә Вәлиәхмәт тугыз яшендә яраткан әбисе һәм туганнарыннан да аерыла. Әтисе аны 1872 елда атаклы Сембер бае Тимербулат Акчурин — Тимай бай тырышлыгы белән оештырылган һәм аның карамагында булган мәдрәсәгә, Сембергә илтеп тапшырган.

Вәлиәхмәт бабайның мәдрәсәдә уку еллары — татар-мөселман тормышында үзгәрешләр башланган чор. Вәлиәхмәт, «җиде-сигез ел укыгач, үзе балалар укыта башлаган». Ә бу 80 нче елларның икенче яртысы — Сембергә дә яңа (җәдид) ысул килеп җиткән вакыт. Яшь хәлфә яңа ысулның уңай якларын тиз абайлап алган һәм аны, беренчеләрдән булып, куллана да башлаган. «Ул вакытларда мәдрәсә шәкертләре-хәлфәләре арасында укыту методы турында көрәш бара. Ысулы кадим, ысулы җәдид дигән ике агым пәйда була. Картлар яңа метод белән укуны «диннән чыгу» дип күрсәтергә тырышалар... Ысулы җәдид дигән метод — башта хәреф, аннан сүз, аннан җөмлә укырга өйрәтү. Кешеләр тиз арада наданлыктан котылалар. Бу хәлфәләр өчен дә бик җайлы, ата-аналар да моңа бик шатлана. Әти, шушы прогрессив ысул ягында булып, соңрак мәгърифәтчеләр агымына катышып китеп, үзенең күбрәк вакытын, авылга кайткач та, авыл халкын укыту-агарту эшенә тота», — дип язган истәлекләрендә аның улы.

Егерме биш яшендә мәдрәсәне тәмамлаган, шәһәр тормышына ияләшкән Вәлиәхмәт, авылга кайтып, имам булырга теләмәгән, Сембердә калырга уйлаган. Шул елларда тормышка ашырыла башлаган «Рухани хезмәттә булырга теләгән кешеләр, указ алырга имтихан тапшырганда, русча укый-яза

белүләрен дә күрсәтергә тиеш», дигән патша хакимияте карарына таянып, ул: «Мин русча белмим, имтихан да бирмим», — дип белдергән. Ләкин Сәгъдетдин бабайның улын авылга, үзенә ярдәмгә кайтарасы килгән. «Русча укырга куша. Уку түләүле булганга, ул этигә утыз сум акча бирә. Инде имтиханга барса-бармаса, русча укырга кирәк икәнен төшенгән хәлдә, эти кирәкле кешесен табып укый башлый. Гимназиядә укучы яшь егеттән көн саен барып дәрес ала. Өч ай эчендә алтмыш дәрес ала. Алтмыш сум акча түли», — дип язган Шаһвәли абый этисе сөйләгәннәреннән. Унбиш ел буена үз тормышын үзе җайлап Сембердә яшәргә өйрәнгән бабамның русча гади сөйләм теле инде шактый шома булган. Бу дәресләрдә ул тырышып рус телендә укырга-язарга өйрәнгән, рус әдәбияты, бигрәк тә Лев Толстой әсәрләре белән мавыга башлаган.

Имтиханнарын да уңышлы тапшырган бабам, имам-хатыйп һәм мөдәррислеккә указ алып, 1895 елда Мунчәлигә кайткан. Сәгъдетдин баба белән бергә мәхәллә эшләрен дә алып барган, әтисенең мәдрәсәсен дә, үз кулларына алып, үзгәртә башлаган. Җәдидчелек тарафдары булган Вәлиәхмәт мәхдүм туган авылында мәгърифәтчелек идеалларын тормышка ашырырга — халыкны агарту — мәгърифәтле итү эшенә керешкән. Беренче чиратта, ул җәдид мәктәбе булдырган. Баштарак яшь мулланың бу адымы мәхәллә халкын сагайтса да, сабый балаларның ярты ел дигәндә «шартлатып» укый башлаулары атааналарны гаҗәпләндергән, сөендергән. Үзләре, өчәр-дүртәр ел мәдрәсәгә сабакка йөреп тә, кирәкле догаларны ятлаудан һәм көч-хәл белән хәреф танудан ерак китә алмаган мәхәллә халкы сабыйларының яза башлауларын, гомумән, могҗиза буларак кабул иткән. Бу яшь муллага абруй өстәгән, аңа халыкның ышанычын арттырган.

Җиденче дистәсен ваклаган Сәгъдетдин баба, яңа гасырга кергәндә, барлык мәхәллә-мәчет эшләрен улына тапшырган. Вәлиәхмәт хәзрәт үзенә аерым йорт салган, өйләнгән. Аңа да зур югалту кичерергә туры килгән. Икенче баласын тапканда, өч яшьлек Мөхәммәтне һәм ирен калдырып, хатыны вафат булган. Вәлиәхмәт хәзрәт икенче тапкыр өйләнгән — Иске Задурдан, Бикколовлар нәселеннән Бибисара Айзәтулла кызын (1882-1975) алган. 1904 елда — Мәхмүт, 1906 елда — Шаһвәли, 1909 елда Рөкыя дөньяга килгән.

Бу заман — Россиядә беренче революция, татарларда милли хәрәкәт җәелеп киткән чор. Вәлиәхмәт мулла да милли хәрәкәттән читтә калмаган. Ул 1906 елның августында Нижгарда (Түбән Новгородның татарча атамасы) узган Өченче Бөтенрусия мөселманнары съездында катнашкан, авылына кайткач, аның карарларын тормышка ашырырга тырышкан. Мәдрәсәсендә яңа дөньяви фәннәр укыту белән бергә, ул Мунчәлидә рустатар мәктәбе булдыру артыннан йөри башлаган. 1910 елда Мунчәлидә рустатар мәктәбе ачтыруга ирешкән.

«Вакытына-чорына күрә бу мәктәпнең, ачылып, түләүсез укыту алып бару тарихы бик зур урын алырга тиеш. Бердән, иске фикерле руханилар русча укытуны руска чыгару — балаларны чукындыру дип карап, бу эшкә катнашмау гына түгел, бу мәктәпкә каршы халыкны агитацияләү алып барсалар, икенчедән, кара халык үзе дә курка. Бу эшне башлап җибәрү шуның белән дә бик авыр була. Алабуга өязе Земская управа каршындагы укыту эшләре буенча инспекторга барып, гариза бирүчеләр Исмак-галава һәм Вәлиәхмәт Субаев 1910-1911 уку елына Мунчәлигә дипломлы укытучы Галләм Яфүнәевне җибәрәләр. Шул ук вакытта уку әсбаблары да төяп кайталар. Бина юк. Вакытлы рәвештә түләү

шарты белән Пешкән Хәйретдиннең алдагы ак өенә урнаштырып, шунда укыту башлана, — дип искә алган Шаһвәли абый. — Мин 1913 елда бу мәктәптә укый башладым. Галләм-учитель kиткәч, аның бертуган энесе Ярулла Яфүнәев [2] безне укытты. Рус теленнән Ярулла керсә, татар телен шул ук школада без әтидән укыдык. Һәр көн дүрт сәгать рус теле, ике сәгать татар теле укытыла иде. Русско-татарская школага йөрмәгән балаларны әти татар мәктәбендә укыта иде. Ләкин анда русча укыту юк. Анда татар теле һәм дин сабаклары өйрәтелде. Халык русча укудан шикләнә иде. «Урыска әйләнәсез», — дип, безне башка малайлар хурлыйлар. Кайчакта мәктәпкә барганда, туктатып, «муеныңдагы тәреңне күрсәт», дип бәйләнә иделәр малайлар».

Вәлиәхмәт Сәгъдетдин углы һәм Бибисара Айзәтулла кызының (1882-1975) тугыз баладан алтысына үсеп җитү насыйп булган: Мөхәммәт (1896-1927), Мәхмүт (1904-1949), Шаһвәли (1906-1987), Рөкыя (1909-1982), Камәрия (1916-1992), Вәлимөхәммәт (1919-1962). Алар барысы да тәрбияле, тырыш, эшчән булып үскәннәр. Крестьян хуҗалыгында тиеш булган бар хезмәтне дә гаилә әгъзалары үзләре башкарган, җирен дә сукалаган, ашлыгын да чәчкән, уңышын да җыйган, утынын-печәнен дә хәзерләгән.

«Авыл зур түгел — 200-220 йорттан тора. Авылда өч мәчет, алар янында кечкенә-кечкенә өч мәктәп. Волостное правление бинасы. Аны патша — Романовларның 300 еллыгына яңадан төзеделәр (1912 елда). Шуңа каршы кооператив лавка бар. Ул лавкада утызлап пайщик. Аны әтиләр оештырганнар. Моннан башка частный лавкалар бар. Биш кеше сату итә. Алар арасында иң бай сатучы — Ибрай (Галиәкбәр Ибрае). Бу кеше бакалей товарлар белән дә, калач пешереп тә сата, мануфактура белән дә сату итә, — дип тасвирлаган Мунчәлинең 1913-1916 еллардагы халәтен Шаһвәли абый. — ...Яхшы өйне 280 сумга төшереп була. Ат — эш аты — 30 сумнан 60 сумга хәтле, рысак — 80-120, нәсел айгырлары 250гә хәтле. Он — арыш оны — 30 тиен поты, ачлык елда 1 сумга җитә, бодай оны 2-2,5 сум. Сарык ите — кадагы 10 тиен (25 тиен килограммы). 400 граммлы калач 5 тиен тора (авылда биш җирдә калач пешереп саталар...»

Вәлиәхмәт бабайның бу еллардагы мал-мөлкәтен дә сурәтләгән ул: «Бер ягы — 8,5, икенче ягы 12,5 аршин бурап, обшивать итеп ясалган бер өй, тактадан өйалды, алар тес белән ябылган. Шушы өйдә 13 тәрәзә, 2 ишек, крыльцо, өй алды, капка. Өй алдында палисадник, рәшәткә белән тоткан. 2 келәт — берсе бәрәңге бакчасында, бер ат абзары (аран), мунча, коймалар, кое. Бер ат, бер сыер, бозау, сарыклар (7-10), тавык, күркә, каз, биш баш умарта. Өй урыны — йорт белән бергә алганда — 0,36 дисәтинә. Берничә алма агачы, декоратив куаклар, бәрәңге бакчасы...»

Халыкка зур авырлыклар алып килгән Беренче Бөтендөнья сугышы, күп кенә ир-егетләрне авылыннан, гаиләләреннән аерса да, авыл тормышы әле, нигездә, бер кергән эзеннән баруын дәвам иткән. Чын афәт 1917 елгы революцияләр белән килгән. Дөрес, Февраль революциясен халык әле зур өметләр белән каршылаган. Ләкин бу өметләр бик тиз югала. Октябрь революциясе, гражданнар сугышы, 1921-1922 ел ачлыгы, НЭП... — болар барысы да Субаевлар тормышында үз эзен калдырган. Балалар үскән. Яшьләргә авыл тормышы тар була башлаган. 1925 елда Мәхмүт, бәхет эзләп, авылдан чыгып киткән. Зәйнәп исемле кызга өйләнеп, үз тормышы белән яши башлаган Мөхәммәт, хатынын һәм кечкенә улы Камилне калдырып, 1927 елда кинәт кенә вафат

булган. Яшүсмер чагында ук рәсемдә күреп «машина җене кагылган» Шаһвәли 1929 елда Бакуга китеп барган. 1928 елда минем әнием Рөкыяны Мәхмүт абыйсы канаты астына алган. 1929-1931 елларда әнием, укытучылар хәзерләү курсларын тәмамлап, Бәзәкәгә урнашкан. Совет хакимияте ныгып, тоталитар режим башланган чорда Мунчәлидә Вәлиәхмәт бабай Сара әби һәм өч сабые белән генә калган (өченчесе — Мөнирә (1927-1931)). Дин әһелләрен эзәрлекләү башлануга карамастан, бабам бу елларда да муллалык хезмәтен башкаруын дәвам иткән.

Авылларны колхозлаштыру чорында, 1920 еллар азагы — 1930 еллар башында сыйнфый дошман дип игълан ителгән муллалар катламын юкка чыгару процессы башланган. Бу афәт бабабызны да читләтеп узмаган. 1931 елның 28 апрелендә ул кулга алынган, Казанга китертелгән, йорт-җире, мал-мөлкәте конфискацияләнгән. 1931 елның 22 июлендә ТАССРның ГПУ «өчлеге», «кулак төркеме составында колхозларга каршы һәм дини агитация алып баруда» гаепләп, җинаять кодексының 58-11 нче маддәсе нигезендә Мунчәли мулласы Вәлиәхмәт Сәгъдетдин углы Субаевны биш елга Себергә концлагерьга җибәрергә хөкем кылган. Ул анда Красноярск краендагы Мариинск лагеренда булган. Бабай кулга алынгач, Сара әби дә, яшүсмерләр Камәрия, Вәлимөхәммәт һәм кечкенә Мөнирә белән йортыннан куылган.

Бу вакытта Мәхмүт абый гаиләсе белән Татарстанда китап сәүдә челтәрендә эшли торган була. Бабай кулга алынгач, Мәхмүт абый Бакудан энесен чакырып кайтарган. Алар гаиләне яңадан җыю эшен башлаганнар. Алабугага эшкә урнашып (шофёр, механик белгечлекләре булган кешегә эш җитәрлек), Шаһвәли абый башта әнисен һәм балаларны алып килгән. Шулай итеп өч гасырдан артык Мунчәлидә яшәгән Субаевлар нәселенең бу тармагы 1931 елда авылны мәңгегә калдырырга мәҗбүр булган. Шаһвәли абый әтисенең хәлен белергә Мариинскига да барып җиткән. Анда аңа яхшы хәбәр җиткергәннәр: эшкә ярамый башлаган алтмыш яшьтән узган тоткыннарны азат итәргә тиешләр икән, Мәскәүдән приказ килүен генә көтәләр, имеш. Шул приказны көтеп алып, 1934 елда ул әтисен Татарстанга алып кайткан. Шаһвәли абыйга да бу чорда Татарстанның төрле районнарында эшләргә туры килгән. Бабай белән әби исә, ярымподвал фатир алып, Ульяновскида төпләнгәннәр, ә 1939 елда Алабугага күчеп килгәннәр. Анда алар Московский урамында ике-катлы йортның яртысын сатып алганнар. Бабамның гомеренең соңгы ун елы шунда үтте.

Язманы тәмамлап, йөзләгән-меңләгән авыл муллалары бабам язмышын кабатлаган, дип әйтергә була. Буыннан-буынга имам-мөдәррис хезмәтен үтәгән, халыкның җитәкчесе, киңәшчесе, кирәк вакытта табибы да булган абруйлы муллалар авыл халкына хас тормыш белән яшәгән — җирен дә сөргән, игенен дә иккән, печәнен дә чапкан, урманын да кискән... Халкы, милләте, иле алдында гаепләре булмаса да, аларның күпчелеге тоталитаризм корбанына әйләнгән. Бу процессны авылларда рухи-мәдәни үзәкләрнең юкка чыгу фаҗигасе дип билгеләү дөрес булыр.

Искәрмәләр

1. Зерцалов А.Н. Материалы для истории Симбирска и его уезда. (Приходо-расходная книга Симбирской Приказной избы). 1665-1667 гг. — Симбирск: 1896. — С.85.

2. Яфүнәев Ярулла 1908 елда Казан татар укытучылар мәктәбен тәмамлаган.

ТАТАРСТАННЫҢ ХАЛЫК ШАГЫЙРЕ,
ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЫ

ИЛДАР ЮЗЕЕВ

(03.01.1933 — 21.12.2004)

САГЫШЛЫ МИРАС

Булганбыз без эре халык, тере халык.
Гасырларны кичә-кичә вакланганбыз.
Ваклансак та, без һаман да рухи Алып:
Тукай булып, Сәйдәш булып сакланганбыз.
Ни әйтсәң дә, Алыплардан яралганбыз.
Шул нигездә торасыбыз, корасыбыз.
Чәчелгәнбез, сибелгәнбез, таралганбыз.
Бабайларның бик сагышлы мирасы без.
Алып бабай тубалыннан чәчелгәнбез.
Үсмәсен дип чирү булып килгән ятлар.
Өзелмәслек тамырдан без, нәселдән без,
Җанга сеңгән моңсу җырлар, риваятьләр.
Ак син, җырым, Әтил сыман дулкынланып,
Тыңла, бала, шул дулкынны уйга талып.
Бабаң менгән рухи үрдән төшә күрмә,
Төшә күрмә, Алыплардан калган халык!

*Шагыйрь Илдар Юзеевнең кайбер сүз энҗеләрен журнал битләреннән чүпли аласыз.

СӘНГАТЬ

Рәссамнар, көйчеләр туар,
сәнгать зур вә яшь булыр...

Илдар Юзеев

РИНАТ ТАҖЕТДИНОВКА 75 ЯШЬ

НИНДИ ИДЕ БЕЗНЕҢ ЯШЬЛЕК!

ӘЗҺӘР ШАКИРОВ,
Татарстанның һәм Россиянең халык артисты,
Татарстанның Г.Тукай исемендәге
Дәүләт премиясе лауреаты

РИНАТ ТАҖЕТДИНОВ. БУ ИСЕМНЕ ИШЕТҮГӘ, ТАМАШАЧЫ КҮЗ АЛДЫННАН БЕРСЕННӘН-БЕРСЕ ГҮЗӘЛ, КАТЛАУЛЫ, ФАҖИГАЛЕ ОБРАЗЛАР УЗА... ТАБИГАТЬ АҢА СӘХНӘ ӨЧЕН КИРӘК БУЛГАН БӨТЕН МӨМКИНЛЕКЛӘРНЕ ШУЛКАДӘР МУЛ БИРГӘН, МЕНӘ БУ ЕГЕТ ЧЫННАН ДА ТЕАТР ӨЧЕН ТУГАН ДИП УЙЛЫЙСЫҢ.

Мин Ринатны беренче мәртәбә 1956 елда укырга кергәндә күреп шаккаттым, нинди матур чын татар егете, аның белән чагыштырганда, мин бер чеби генә идем. Заманында театрның иң матур егетләреннән берсе иде ул, һәрвакыт миңа Италия артистларын, Марчелло Мастрояннины хәтерләтә иде. Шулай бервакыт, укыган чакта, диңгездә 49 көн буе адашып, ач йөргән татар егете Әсгать Җиһаншин роленә кино-пробага чакырдылар. Ринатны күргәч, мондый татар егете буламыни, син бит татар түгел, итальяннарга, испаннарга охшагансың, дип татар егете роленә рус артистын сайладылар. Игътибар иткәнегез бардыр, русларның күбесенең йөзе, кыяфәте нәкъ үзебез — татар йөзе, теле генә русча. Мин әйтмим: Ринат гел «5»кә генә укыды дип, кайбер фәннәрдән «4»леләре дә бар иде. Әмма эшли башлагач, ул безнең арада беренчеләрдән булып үз урынын тапты. Уку — бер нәрсә, ә театрда эшләү — бөтенләй икенче хезмәт. Минем белән укыган иптәшләрем арасында гел «5»легә генә укыганнары да бар иде, ләкин театрда эшли алмадылар. Минем күңелемдә Ринат Таҗетдиновның онытылмаслык тәэсир калдырган рольләренең берсе — М.Кәримнең «Ай тотылган төндә» трагедиясендә Дивана роле. Әсәрне сәхнәгә Ширияздан Сарымсаков куйган иде. Ни өчен мин бу турыда язам, чөнки ул спектакльдә үзем дә катнаштым, шуңа күрә барысы да минем күз алдымда булды. Сезгә аңлашылсын өчен, «Ай тотылган төндә» трагедиясенең аз гына эчтәлеген искә төшереп узам. Вакыйга борынгы заманда башкорт җәйләүләренең берсендә бара. Баш-

корт хатыны Тәңкәбикә уйнаштан бала таба, менә шул бала Дивана булып туа да инде. М.Кәрим Дивана образы аша Тәңкәбикәнең бөтен фаҗигасен ачып бирә. Заманында бу трагедия Советлар Союзында иң күп куелган әсәр иде, хәтта фильм да төшерделәр.

Сәхнәдә Дивана образын ничек уйнарга соң? Без яшь чакта һәр авылда бер җүләр була торган иде, шуңа күрә җүләрләрне күп күрдек, гомумән, гади җүләрне уйнау артисттан әллә ни зур сәләт сорамый. Бу әсәрдә без күргән җүләр өстенә, чын мәгънәсендә, трагедияләрдә генә куела торган сорауларга җавап бирерлек Дивана образын тудырырга кирәк иде. «Юк, мондый тормышта яшәп булмый! Сезнең үзегезнең җаныгызда коллар утыра! Сез үзегез коллар», — дип әйтерлек Дивана образын тудыру гаять катлаулы эш. Юк, ул гади бер җүләр кешене уйнап шаккатырмады, ә бәлки, шундый бөек фикерләрне әйтерлек Дивана образын тудырды. Бу шундый уен — ул сине үзенә җәлеп итә, әчке бер драматик көч, зур күтәренкелек, тетрәндергеч темперамент белән спектакльгә нокта куя иде. Мондый тормышта адәм балаларын бәхет көтмәс дип, бөтен җаны, күңеле белән тамашачыга җиткерергә тырышты. Әйткәнемчә, сәхнәдә гади җүләрләрне генә уйнау җитми, аның аркылы бөек фикерләрне тамашачыга җиткерә белергә кирәк. Моның өчен Ходай Тәгалә сиңа чын сәләт бирергә тиеш! Күп очракта артист бик килештереп уйнады, диләр, ә мәгънәсен, ягъни ни өчен ул рольне уйнаганын аңламыйлар. Һаман да: «Сезнең эчегездә коллар утыра!» — дигән тетрәндергеч тавыш минем күңелемдә яңгырый! Бу катлаулы рольне уйнаган Ринат үзенең нинди сәләтле артист икәнен бөтен коллектив каршында раслады. Әлбәттә, М.Кәримнең «Ай тотылган төндә» трагедиясе кебек әсәрләр театрда бик сирәк куела шул. Артистка бәхет бик кирәк, мин рольләр турында әйтәм. Шушы спектакльдән соң Празат абый Исәнбәт Нәкый Исәнбәтнең «Муса Җәлил» трагедиясендә Муса ролен Ринатка бирде. Муса роле белән Ринат Таҗетдинов халык күңеленә онытылмаслык булып кереп калды. Ничәмә-ничә еллар ул шушы рольне уйнады, әгәр дә без Шәүкәт абый Биктимеровны Әлмәндәр итеп кабул итәбез икән, һичшиксез, Ринатны да тамашачы Муса Җәлил итеп кабул итте. Әлбәттә, артист өчен моннан да зур бәхет юк! Әле менә исемә төште: Ринат Таҗетдинов, Илдар Хәйруллин, Марсель Сәлимҗанов, тагын кемдер бар иде, истә калмаган, «Моабит дәфтәре» дигән фильмга кино-пробага Ленинградка чакырылды. Без килеп төшкәч тә кунакханә номерларына урнаштык. Мин — Ринат белән, Марсель — Илдар белән. Берзаман телефоннан шалтыраталар, трубканы алдым: «Слушаю, я артист Шакиров, что вам нужно?» «Вы нам не нужны, нам нужен артист Ринат Тазетдинов, который снимается в главной — роли Мусы Джалиля». Мин әйтәм: «Ринат, сине телефонга чакыралар», — дим. Ринат телефоннан сөйләшкәч, кинәт үзгәреп китте, тиз-тиз чишенеп атты, кырына, юына башлады. «Кая ашыгасың?» — дим. «Редакциядән килгәннәр, миннән интервью алырга. Бик тиз аска төш, көтәбез, диделәр». Мин, көнләшеп, кара инде, килмәс борын каян телефоныңны, номерыңны белгәннәр, ну малай, болай булгач, синең даның дөньяга шаулаячак, дим. Күрәсең, киностудиядә хәзердән үк синең төшәсеңне белгәннәр, Муса ролендә синнән башка беркем дә төшмәячәк, дим. Ринат, ак күлмәген киеп, чәчен Муса роленә килештереп тарап чыгып китте. Мин, көнләшеп, мине дә чакырсалар була иде, чакырмадылар шул, сволочьлар, дип эчтән сүгенеп калдым. Көтәм-көтәм, Ринат юк, нәрсә булды икән, дип чыксам, Ринат әрле-бирле йөри. Күтәрелеп карасам, Илдар белән

Марсель көлеп карап торалар. Телефоннан Марсель шалтыраткан булган икән, кызык итеп, нишләрләр икән дип, бигрәк тә миннән көләргә уйлаган, көнләшеп йөрәге әрнесен, дип. Шунда барыбыз да рәхәтләнеп көлештек. Мин Марсельгә: «Ну утырттың, малай, үзеңне дә бер кызык итәм әле», — дидем. Ринатны «Моабит дәфтәре» фильмында төшермәделәр, әллә кайчан Муса Җәлил роленә русның талантлы артисты Пётр Григорьевичны әзерләгәннәр. Әгәр ул рольдә Ринат төшкән булса, фильм бөтенләй икенче төрле мәгънә алыр иде. Мин моны үзем шул фильмда катнашканга күрә әйтәм, Пётр Григорьевич белән төшкән сәхнәләремдә ул аермачык күренә. Ул — рус кешесе, ә мин — татар, бу экранда шулхәтле сизелә, моны аңлау, күрү өчен зур тәнкыйтьче булырга кирәкми. Шуңа күрә Пётр Григорьевич белән бергә төшкән сәхнәләремнең күбесен



Муса Җәлил ролендә

Идегәй ролендә

төшереп калдырганнар иде. Мин шуны гына әйтергә телим: татар артистына үз гомерендә бер тапкыр бәхет елмая, анда да аны башка милләт кешесенә уйнарга бирәләр, нишлисең, татар артистларының язмышы шул. Әмма Ринат артист буларак бу күңелсезлекне җиңеп чыкты. Аңа бик зур уңыш китергән Ч.Айтматовның «Гүзәлем Әсәл» әсәре буенча куелган спектакльдә Ильяс роле өчен Г.Тукай бүләге бирелде. Режиссёры — Ташхуҗа Ходжаев. Шуның артыннан ук Г.Фигерийдоның «Эзоп» комедиясендә Эзоп роле, (режиссёры — П.Исәнбәт), саный китсәң, алар дистәләрчә, барысы да баш рольләр. Тарихи шәхесләрне дә аңа ышанып тапшырдылар. Н.Фәттахның «Кол Гали» трагедиясендә — Кол Гали, Юныс Сафиуллинның «Идегәй» трагедиясендә — Идегәй. Әлеге спектакльләрнең режиссёры Марсель Сәлимҗанов. Әлбәттә, бу әсәрләр, Академия театрының тарихи трагедия жанрына алынуы үзенә күрә бик зур батырлык иде, чөнки безнең борынгы тарихыбызны сәхнәгә менгерергә бик ашкынып тормадылар. Марсельнең татар сәхнәсендә татар трагедиясен күрсәтергә теләге шулхәтле көчле булды, хәтта «Идегәй» трагедиясен Юныс Сафиуллиннан яңадан яздырды. Марсель Сәлимҗановның Кол Галине дә, Идегәйне дә Ринат Таҗетдиновка бирүе очраклы хәл түгел, ул аңа артист буларак чын күңелдән ышанды. Тамашачының да Ринатны актёр буларак чын күңелдән яратып кабул итүен ул режиссёр буларак аңлый иде.

Ринатның театрдагы эшләре турында тәнкыйтьчеләр күп яздылар, кабатлап тормыйм. Әлбәттә, театрда талантлы артистлар була, ләкин аларга һәр спектакльдә баш рольләрне уйнарга насыйп булмый. Монда әле талантлы булу гына җитми, моның өчен режиссёр, директор белән якын дусларча мөнәсәбәттә булырга тиешсең, гади генә итеп әйткәндә, кешеләр белән уртак тел табарга, мөмкин кадәр үзеңнең талантлы икәнеңне күрсәтмәскә тырышырга, эшләгән эшеңне яратып эшләргә, хуҗаларга хөрмәт белән карарга өйрәнергә, үз-үзеңне тәрбияләргә кирәк. Бу инде кешенең маңгаена язылган була. Ринат шулай тәрбияләнгән: тәртипле, күп сөйләшмәс, юкка-барга бик тиз кызып китүчән түгел, үзенең кем икәнен яхшы белә, андый кешегә карата руслар: «Он в своём уме», — ди.

Әле иң кызыгын язарга онытканмын. Мәскәүдән укуны тәмамлап кайткач, Ринат белән бергә 6 квадрат метрлы бер бүлмәдә яшәдек, шуның өстенә Мәскәүдән Ринатның хатыны Рәйсә килеп төште. Күз алдыгызга китерегез: яңа өйләнгән яшь егет белән яшь кенә Мәскәү кызы һәм мин! Миңа хәзер нишләргә? Түзмәдем: балкон кебегрәк җиргә чыгып йоклый башладым. Менә Ринатның хәлен күз алдына китерегез: Мәскәү тикле Мәскәүдән алып кайткан яшь-яшь кыз бала алдында ул нишләргә тиеш? Бергә торырга урыннары да юк бит! Ахырда минем хәлне аңлап, кыш көне Ринатка ниндидер бер бәләкәй бүлмә бирделәр, Аллага шөкер, котылдым бу җәфадан. Шулай өчәү бергә башлаган идек тормышны, менә тагын, 50 ел узгач, күршеләр булып урнаштык. Нинди иде безнең яшьлек дип, хәзер инде көлеп кенә искә алабыз! Әлбәттә, мин бергә укыган иптәшләремнең чын талантлы шәхесләр булуы белән чиксез горурланам, күңелемдә аларга һәрвакыт рәхмәт хисләре ташып тора. Ринат Таҗетдинов кебек артистлар Академия театрының данын татар милләтенә, халкыбызга бөтен зурлыгы, бөеклеге белән китереп җиткерделәр. Ходай Тәгалә аңа хатыны Рәйсә белән якты, озын, тигез тормышлар бирсен! ■

АЛЬТЕРНАТИВ... ЯКИ КИНӘСЕЗ КИНО

ӘХТӘМ ЗАРИПОВ,
режиссёр, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе

«СӘНГАТЬ КЕМНЕКЕ?» – ДИГӘН СОРАУГА: «ХАЛЫКНЫКЫ», – ДИЛӘР. БЕЗ ШУҢА ӨЙРӘТЕЛГӘН, ШУҢА КҮНЕККӘН. Ә МЕНӘ «СӘНГАТЬ КЕМГӘ ХЕЗМӘТЧЕ?» – ДИГӘНДӘ, ҖАВАП УРЫНЫНА СОРАУ АРТЫ СОРАУЛАР ГЫНА ТУА: НИНДИ СӘНГАТЬ? НИНДИ ХЕЗМӘТ? КАЙЧАН? КАЙДА?

Чиркәү тәкъдиме буенча бөек рәссам Рафаэль Ватикан сараендагы фрескаларын һәм «Секстин мадоннасы»н ясый. Даһи сәнгать әсәрләре тудыра. Кемгә хезмәт итте ул? Динчеләргәме? Чиркәве дә, дине дә халыкныкы дип карасак, бер мәгънә, ә инде халык үзе дин өчен дип караганда, икенче мәгънә.

Классик опера сәнгате үрнәкләрен алып карыйк: йә чиркәү кушып, йә хакимнәр заказын үтәп язылганнар.

Сәнгатьне һәр кавем үзе өчен дип тудыра, шул кавемнең гореф-гадәтенә, йолаларына таянып.

Афәтле революцияләре белән шаулап узган XX гасыр алпавытларны һәм мәгърифәтче руханиларны тамырлары белән йолкып ташласа да, алардан калган әдәбият һәм сәнгатьне ташлый да, яшәештән туктата да алмады. Киресенчә, инкыйлабның башлангыч елларындагы яңа хакимият халыкка мәҗбүри гыйлем-белем бирү белән әдәбият һәм сәнгатьне күпчелеккә

якынайтуга, рухи азыкка ихтыяҗны арттыруга иреште.

Наданнар белән идарә итү җиңелрәк булганда, яңа хакимияткә халыкны белемле итүнең нигә кирәге булды икән дигәндә, күрәсең, алар, тәхет-властьны яулаганчы ук, әдәбият-сәнгатьне идеология хезмәтчесе итүгә ныклы исәп тоталар һәм ялгышмыйлар.

XX гасыр башларында хакимиятне кулга алган большевиклар «кавеменә» үз әдәбиятларын, үз сәнгатьләрен булдырырга кирәк дип табыла. Аның өчен өлге уйлап чыгарырга кирәк була. Чыгаралар: фәннилек өчен аны «социалистик реализм методы» дип атыйлар. Аның нәрсә икәнен аңлатып, меңәрләпмеңәрләп диссертацияләр язылса да, шул аңлашылмаган килеш юкка да чыга ул. Хәзер аны хурлык тамгасы буларак кына кулланалар.

Без — соцреализм җимешләрен ашап, ялган белән тулган чынбарлыкка күчәргә омтылып картайганнар — тагын бер җимерүле революция нәтиҗәсендә элек күргәннәрдән дә яманрак мохиткә күчерелгәч: «Чын сәнгать беркайчан да хезмәтче булмаган, булмас та! — дибез. — Чын сәнгать ул — үрнәк, ул — илаһи! Ул үзенә табыну көтми. Чын сәнгать тыйнак була. Аңа табынучылар үзләре аны табып табына башлый».

Үтә каршылыклы һәм иҗат өчен гаять куркыныч шартларда да матурлык матурлык булып калган, аның үз урыны булган. Гүзәллеккә тормыш теләсә нинди шартларда да мохтаҗ.

Бүген сәнгатькә ихтыяҗ, мохтаҗлык кайда, ничек чагыла?

Үзләрен халык вәкилләре дип атап, гавамны корал итеп файдаланучыларга кирәкме сәнгать? Алар хакимлек итүләрен мәңгеләштерү хәстәрендә. Хакимлек кулларына килеп кергәч, булдыра алганнарын эшләделәр инде. Элек сүгенүдә генә кулланылган сүзләр «тоткынлыктан» чыгарылды, тәүфыйксызлык кыюлык дип атала башлады; әрсезлек — ачык күңеллелек; шамакайлык — шаянлык.

Яшәү максатлары, хәләлдән хәрәмне аермыйча, күбрәк байлык туплау, акча җыю гына булган «яңа байлар»ның сәнгатькә ихтыяҗлары туугa өметләнү беркатлылык булыр иде.

Чын сәнгать һәрчак теләсә нинди хакимияткә һәм аның үрчетергә теләгән «денем өчен түгел — көнем өчен» суррогатына оппозициядә туып, яшәп кала алган. Шулай була алгач, бәлки, борчылырга сәбәпләр юктыр? Бәлки, кайдадыр «идән асларында» яңа Исхакыйлар иҗатта кайныйлардыр? Олыны күрер өчен ераккарак китеп карау кирәк, диләр ич. Без ниятләр буенча түгел, кылган гамәлләр буенча фикер йөртергә тиешбез. Үзгәртеп корулар дигән фетнә, яшәп килгән каршылыклар бердәмлеген җимереп, әдәбият һәм сәнгатьне идеологиядән аерды да заказ бирүчедән дә, кулланучылардан да мәхрүм итте. Иҗатчы «соцреализм» чорындагыннан да читенрәк хәлдә калды. «Кулга ияләштерсәләр дә», заказы килеп торгач, базардан буш кайтмаска күнеккән иҗатчы кинәт үзенең җәмгыятьтә кирәксез калуын күрде. Нишләргә?

...Әдәбият, сәнгать әһелләре урындык, тәрәзә ватуны инкыйлабка тиңләп, «ура» кычкырып, мәйданнар саклаганда, элекке идеологлар архивларны ачып, андагы серләрнең «тозлыракларын» урамнарга ташладылар да бушап калган биналарга тимер ишекләр куйдырдылар, офислар төзеделәр; аннары, берләшеп, кануннар чыгардылар, үзләрен дәүләт хезмәткәрләре дип игълан иттеләр һәм шау-шусыз гына хакимиятне дә «прихватизацияләп» куйдылар.

Мәйдандагылар тәрәзәдән ыргытылган архивларны ерткаланып беткәнче укып, бөтен дөнья күптән белгәнне ачып, үзләрен җиңүчегә санап, биналарга керик, дисәләр, ишек бикле.

Кемгә барырга? Шикаять бирер

оешма юк. Әдәбият та, сәнгать тә дәүләттән аерылган.

...Шулай ирекле илнең ирекле иҗатчылары һәрнәрсәдән ирекле булып калдылар.

...70 ел буе «иң күп укучы», «иң актив тамашачы» дигән ялганга күнектерелгән рухи ач публика инде ничә еллар буена үзләре өстендә нинди тәҗрибәләр уздырылуы турында белгәч, башка илләрдәге хәлләр белән кызыксынырга тотына. Ирекле булса да, барыр урыны һәм мөмкинлеге булмагач, телевизордан күрсәтелгән «чын дөнья» фильмнарына каплана. Хәйран замана башлана. Алай гынамы! Эш урыннарында эш ташлап чит ил сериалларын карау мәртәбәле гадәткә әверелә. Аннары шулар турында җыелышып соклану, табыну китә, уйнаган чит ил артистларының үзләрен дә гаҗәпкә калдырып, монда китереп, хөкүмәт, ил исеменнән кыйммәтле бүләкләр тапшыру оештырыла. Китап-журналларда һәм эфирдагы алдау, талау, көчләү, үтереш күренешләренең безнең тормышыбызда еш очрый башлавына гаҗәпләнү үзе гаҗәпкә әверелә.

Һәр җәһәттән сиздерми генә тәгълиматка әверелә барган «...тормыш ул — яшәү рәхәтлекләре өчен көрәш», дигән фикер уздырылуын күзе булган күреп, колагы булган ишетеп белсә дә, гади кеше берни эшли алмый. «Ил белән килгәнгә — исәр кеше көйгән», дип кенә карый. Шәхесне бетерүдә ташланган көчләрдән сакланырга ялгыз кешенең көче дә, чаралары да юк. Ул бирелә, җиңелә...

...Рекламаларда: «Тормыштан алып булырдайны алып калырга ашык!» — ди кока-кола шешәсе тоткан ялангач ханым; «Яшәмәс җиреңнән яшәрсең!» — ди икенче бер сыра шешәсе тотканы; «Оҗмах рәхәтлекләреннән баш тартма!» — ди су буенда сусап яткан кәнтәй.

«Реклама — сәнгатьнең бер төре», — дип исбатлыйлар «белгечләр»е.

Сорау туа: кемгә хезмәт итүче сәнгать соң бу? Шулай шома, җайлы гына итеп, әдәпсезлеккә, зинага, үтерешкә омтылучы «демократия» көчтәнәчләре.

Хәзерге фильмнардагы кеше үтерү эпизодлары ничектер тетрәндерми; ә менә үтерүченең полициядән качып йөргән маҗаралы сәяхәтләре дулкынландыра. Аны тотылмасын, котылсын дип көтәсең.

Тамашачы мәрхүмнәр язмышы белән түгел, үтерүчеләр язмышы белән мавыга. Әйтерсең, үлем кабатлана торган физиологик бер процедура гына.

Болар барысы да сүз ирекен, матбугат ирекен, кеше ирекен яклаган кануннарга ышыкланып эшләнелә. «Үзегез шушылар өчен көрәштегез, шулай теләдегез!» дигәндәй, теләүчеләре күп. Алар бүгенге белән яшәүчеләр. Үзләренә булса, башкаларны күрми, ишетми торганнар. Малның нинди юл белән табылуына карамаучылар.

«Разве мы этого не достойны?!» — ди, шуларны яклап, реклама әрсезе. «Бери от жизни всё», — ди, күзен кысып, авызын ачкан кәнтәй.

Һәм алалар тормыштан мөмкин булганның барысын да алучылар. Чөнки кануннар аларныкы, аларча.

Аерма кемнең нәрсә һәм ничек алуында.

Кемдер порнографик фильмнар карауны чын хөррияткә санаса, кемнәрдер казиноларда акча оттыруны егетлек, ди. Уртаклыклары да бар. Табылган мал берсенеке дә эшләп, көч түгеп тапкан хәләл мал түгел. Йә алдап, йә талап, йә урлап.

Элек «синеке», «минеке» дигән төшенчәләр изге саналган. Намус, оят дәрәҗәдә йөргән, ә бүген? Бүген тегермән мөшкәсендә комсызныкы, кансызныкы, әрсезнеке.

Эшләп табылмаган хәрәм малны криминал байлык дип йөртәләр. Криминал малның хуҗалары — теләсәң-теләмәсәң — җинаятьчеләр.

Җинаятьченең бар тырышканы, омтылышы — җинаятьнең ачылмавы. Шуңа күрә аларга кешеләрдәге хайвани хисләрне өскә чыгару, шул хисләрнең колы ясау мөһим.

«Кеше үз теләкләрен «канәгатьләндерергә тиеш!» — ди алар көч кулланганда, золым, җәбер кылганда, «икеләнү, шикләнүләр — шайтан фигыле!» Алар өчен экраннардагы көчләү, кеше үтерү күренешләре — гадәти тормыш эпизодлары.

Кызганыч ки, бу өлкәдә яңа байларның һәм хакимиятнең (хакимият, шиксез, яңа байларныкы) «уңышларын» төзәтү өчен алар хакимлек иткән кадәрле вакыт кына җитмәячәк. Бик тирәнгә китте эшләр. Кешене диванага әверелдерү җиңел булса да, дивананы кеше итү өчен акча гына түгел, башка байлыклар да күп кирәк. Ул байлыклар, иң беренче чиратта, әлбәттә, рухи байлык чыганаклары.

Тасвирлап узган гомум ил мохитеннән бераз аермалы буларак, безнең Татарстан мохитенә бу галәмәтләрнең вируслары үтеп керсәләр дә, күләмле эпидемик авыру хасил итә алмадылар.

Беренчедән, милләттә әхлаксызлыкка, әдәпсезлеккә каршы иммунитет сакланган. Икенчедән, иҗат әһелләребез дә, гадәттән тыш халәттә калган саен, кыйбла алыштыручылардан түгел.

Иманнарыбыз тотрыклы, иҗатчыларыбызның түземлекләре җитәрлек. Тик бүген иман ныклыгы белән генә сакланып булмый. Дошман үзен дус дип тәкъдим итә, агуын дару дип бирә, караңгылыкны яктылык өчен кирәкле шарт дип исбатлый һәм иң хәтәре — күпләр ышанып иярә шуңа.

Әллә инде хөррият башлангандагы кинәт яктылыкта, чагылудан, күзләр кысылып калды, әллә әкрен-әкрен генә дөньяны гомумкараңгылык баса — һавада сөрем исе, шартлау, җимерелү авазлары.

Караңгылыкны «караңгы, караңгы!» дип әйтү белән генә җиңеп булмый, «һич булмаса яндырырга, яисә шырпы сызарга кирәк!» — дигән бер акыл иясе. Шырпысын да сызалар, чыра да яндыралар, шәм дә кабызалар сәнгатькәрләребез. Тик төрлесе төрле вакытта, төрле урында. Шуңадыр, җемелдәү бар, яктыру юк. Достоевский: «Матурлык барысын да җиңәчәк!» — дигән. Матурлык, ягъни сәнгать.

Югарыда сурәтләнгән шартларда матурлык ничек яши соң? Үсәме ул? Тоткын хәлендәме, ирекleме ул?

Бүгенге фильмнар гамьсезлеккә күндерелгән тамашачыны битарафлык коллыгыннан коткаруда, гүзәллекне фальштан аерырлык эстетик зәвык тәрбияләүдә ярдәм итәме?

Гомумән, тәкъдим ителгән фильмнар тормыш-чынбарлык куйган проблемалардан качу мөмкинлеге генә түгелме? Әллә рентген аппараты кебек җәмгыятьнең күзгә күренмәгән каршылыкларын ачу коралымы?

...Шәһәр халкының күбесе җәйге көннәрен дача-бакчаларда үткәрергә омтыла. Күршебез — балыкчы. Бакча өе аңа телевизор карау урыны гына. Кар бетүгә күченеп килә дә, ялсыз узган елларының «әҗерен чыгарып», көн-төн телевизор карый. «Татарлыгымны бетерәм, миллилегемнән котылам», — ди.

Күп укыган белемле кеше скрипкада уйный, рәссам балет ярата, тарихыбызны белә, орденнары бар, фән-техника белән кызыксына. Әдәбият-театр дөньясыннан да хәбәрдар.

Ошаттым мин бу күршемне. Еш кына телевизордан күргәннәренә анализ ясый ул. Дөресрәге, ишеттереп уйлана.

— Ну малай, барып җиттек! Благовещение соборы белән Кол Шәриф мәчетен ачу тантанасыннан репортаж күрсәттеләр. Гел урысча, гаеп итмәс идең — күрешүләре дә гел христианнарча. Өч тапкыр яңакны яңакка терәп.

— Сәясәт!

— Сыек сәясәт. ...Кол Шәриф

мәчете ачылганда, мөнбәрдән русча сөйләүләр күп булса да, Благовещение чиркәвен ачканда, татарча сүз ишетелмәде.

— Татарлар булмагандыр.

— Керәшеннәр татар түгелмени? Алар өчен генә булса да туган телләрендә китап сүзе яңгыратканга мәскәүләр шелтәләмәс иде.

— Син җитешсезлекләр генә эзлисең.

— Аларны эзлисе юк.

— «Булды!» диярлек эшләр дә бар бит.

— Паспортка кыстырган татарлык талонын әйтәсеңме?

— Ул да җиңел бирелмәде.

— Милләтне талон белән генә саклап булса икән...

— Бу — бер чара гына.

— Бичаралык! Безнең ил халкы, милләтебез тарихта тиңе булмаган сынау һәм алдануларга дучар.

— Бик зур тема бу. Башламыйк.

— Судан чыгарылган балык нидән үлә?

— Кислород җитмәүдәндер.

— Кислород күплектән! Милли сәнгать тема күплектән үлеп бара. Сәнгатькәрләр кискен темаларга «чумарга» курка. Чумса да, сайлыкларда гына. Корсаклары комга бәрелү белән өскә күтәреләләр.

— Сәясәт мәдәниятне җитәкли.

— Киресенчә булырга тиеш бит!

...Шушы типтагы әңгәмәләр артыккарак киткәч, мин аның белән очрашудан кача башладым: җай чыккан саен, авылга кайтам, анда яшим.

Озак вакыт очрашмаган идек. Беренче җиләкне авыз итәргә дип бакчага барсам, кергән бу. Кулында атналык программа басылган газета.

— Сиңа бирәм, мә — укы. Котлыйм үзеңне!

— Ни белән?

— Бәйрәм белән тәбрикләргә кердем. Олуг бәйрәм мөбарәк булсын! — ди бу.

— Нинди бәйрәм?

— Россиянең бәйсезлек кабул иткән көне ич бүген!

— Кемнән бәйсез?

— Синнән-миннән... Казан карый алган 12 каналның программаларында Татарча яңа фильмнар, яңа спектакльләр бармы? Руслардан кала сан буенча икенче урындагы татар халкының шундый зур бәйрәм көнендә үз телендә премьера карарга хакы бардыр бит?!

— Хакы бар. Тик... премьерасы юк.

Башка каналлардан төрле милләтләргә багышланган тапшырулар эзлибез. Исем өчен булса да, кайсыдыр берәр милләтнең бүгенге хәле, язмышы, киләчәге турында тапшыру булса икән! Юк!

— Чынлап та тигезләнгәнбез икән. Йөздән артык милләт яшәгән федерациядә, хокуклар тигез, дип Конституциядә язылган илдә! Шул Конституция көнендә?! Аның урынына һәр каналда чит илдән сатып алган сериаллар! Фантастика, маҗаралар, секс, үтереш — телеменюда иң фарыз «ризыклар».

— Бу бит... басып алуның яңа формасы, интервенция бит бу! Кемгә мөрәҗәгать итәргә, кайдан ярдәм көтәргә?

— Сине беркем дә көчләми. Ошамый икән — карама.

— Мәҗбүрбез. Шартлар шуңа этәрә. Карыйбыз.

— Читтән кергән фильмнарның барысы да начар яки зыянлы димәгән. Аларның күбесе эшләнеше ягыннан үрнәк булырлык, сыйфатлы...

— Иделдә балык бетте, дибез. Беркем дә балыкны бетерәм дип суга агу сипми. Аның табигый яшәү шартлары үзгәртелә. Агымсулар акмый башлый, салкыннары җылына. Кеше, әгәр теләсә, балыкны кабат үрчетә алыр, ә менә милләтләр бетә икән, аның инде терелү, үрчү ихтималы юк. Читтән кергән фильмнарда милләтләр юк.

— Синнән-миннән генә тормаган объектив процесс. Тарихтан «Фәлән милләтне бетерергә кирәк!» дигән бернинди әмер дә, указ да табалмаячаксың. Шулай булган, булачак.

— Милләтне бетерергә указ кирәкми. Ваемсыз замандашларның читтән кергән нәрсәләрдән үрнәк алырлыклары да бар, дип караулары җиткән.

...Әйе, милләтне милләт иткән аның теле генә түгел. Гореф-гадәтләре, йолалары, ашаган ашы, кигән киеме, кәсебе, һөнәрләре — барысы да милләт куласасын әйләндерә... Ә бездә... түбәтәйдән башка нәрсә милли?

Диннәрнең универсальләшүен түгел, милләт үзенчәлекләренең җуелуын күрсәтүче фактлар күп һәм төрле-төрле.

— Ә сез — чаң сугарга тиешле сәнгать әһелләре «объектив процесс», «шулай булган, шулай булачак» дип, һаман нидер көтәсез. Тегеләр көтми. Аларның исәп төгәл. Элекке кеше үзен үзе яклый алган. Хәзер кеше үзен бозарга, моңсыз калдыруга ирек куя.

— Проблеманы чишә алмаганда, алар белән яшәүгә яраклашырга кирәктер, бәлки.

— Яраклаша-яраклаша милләт бетеп бара түгелме? Милләт, нигездә, шул фильмнардан зыян күрә. Һичьюгы фильмнар башланыр алдыннан аның зарары турында фикер әйтелсен иде. Абруйлы шәхес фикере.

— Сәнгать ул — рухи азык. Һәркем аны үзенчә кабул итә. Тәэсир итүнең стандарт юллары юк, — дидем дә туктап калдым. Чөнки тәкъдим итүнең стандартлары булырга тиеш бит! Әгәр дәүләт «телевидение» дигән коралэсбап белән халыкка тәэсир итәргә теге яки бу каналга лицензия — рөхсәт биргән икән, аның ни күрсәтүенә битараф булмаска тиеш. Цензурасызлык — битарафлык түгел.

— Безнең хакимият структуралары телеменюга битараф. Ни генә күрсәтмиләр?! Миллионлаган акча тотып, үзебезнекеләр төшереп күрсәткәннәре дә Рәсәй Конституциясе декларацияләренә ят. Мисалга «9 нчы рота»ны гына алыйк. Монда сугыш күренешләре үзенә җәлеп итә торган дизайн буларак кулланыла. Эшләнеше ягыннан «ах» итәрлек эпизодлары бар. Ә эчтәлеге... Фильмның бер персонажы сугыш турында «чынга ашкан идеал-гармония» дигән фикердә. Имеш, «сугышка эстетик камиллекнең иң югары ноктасын эзләп килгән ул». Дуслык хакына башка милләт, дин кешеләрен үтерү аларның изге бурычы икән! Сугышка өндәүчеләр өере түгелме бу? Конституция бозылмыймы?

Теге яки бу сәнгать әсәрен хакимиятнең Олы хакиме караган икән — бу инде мәдхияләрнең иң кәттәсенә тиң. Ул караган! Аңа ияреп вәзирләре: ох, ух! Бүләк көтәсе генә кала. Хәер анысы озак көттерми.

Чын тәнкыйтьче бүген иң кирәкле профессиядер, мөгаен. Тамашалар күплектән күзләр генә түгел, күңел камаша, өметсезлек уяна...

...Иҗатчыларга лоцманнар кирәкми, әмма тамашачыларга кирәк. Чөнки тамашачы гел кызык кына эзли, мәзәк кенә көтә. Сәнгатьтәге кызык-мәзәк ризыктагы шикәр кебек. Зыянлы икәнен белсәң дә, һаман шуңа омтыласың, шуны көтәсең. Сәнгать корабы җилкәненең бавы намусын сатмаган, ачык аңлаешлы бәһаләү системасын дуслык хакына да, өстән кушканнарны тыңлап та, кесәдә кыштырдаячак һәдия бәрабәренә дә фикерен алмаштырмаган, ягъни принципларына хыянәт итмәгән фидакарь сәнгатьчеләр кулында булырга тиеш.

Республикадагы югары уку йортлары ел саен күпләп-күпләп артистлар, режиссёрлар, юристлар, инженерлар әзерли. Ә менә бүген бик тә дефицит булган киноведлар чыгармый. Алар өчен штат каралмаган. Ләкин алар тамашачы өчен бик тә кирәкле.

Гуманитар уку йортлары укыту программаларына «киноведение» предметларын кертсә, заманча рухлы бик тәвәккәл адым булыр иде. Чөнки чын киновед — кинода нинди идеяләрнең әйдәүче юнәлеш булырга тиешлеген тәгаен сиземләүче, кайсы проектларны гамәлгә ашыруны канунлаштырып, нинди проектларга күпме акча бүленергә тиешлеген хәл итүдә катнашырга тиеш иҗатчы ул.

Безне төрле яклап рухи агулыйлар. Максатчан агулау эше бара. ...Моннан ничек котылырга була? Агулануын тамашачының үзенә белдереп, аның үз-үзен саклау инстинктын уятып. Тәнкыйтьчеләр — замана физиологиясенә диагноз куеп, сәнгать әсәрләренең «рентген» сурәтен бирергә тиеш затлар.

Бу эшнең башында әйдәп баручылар, әлбәттә, милли белгечләребез булырга тиештер. Гамьсезлегебезне, бетә баруыбызны Мәскәүгә генә сылтап яшәсәк, билгеле, бетәчәкбез.

Киләчәктә, Конституция көнендә генә булса да, татар милли фильмнарының премьераларын күрергә язсын дисәк, шушы юнәлештә эш тукталмаска тиеш. Шулай булмаганда, ул Татарстанда эшләнгән эш кенә була, ә татар милләтенеке булмый. Безгә төрле яклап һөҗүм итәләр, каян атулары да, нидән атулары да, нәрсәгә төбәп атулары да сер түгел. Син оборона тәкъдим итәсең. Тик иң яхшы оборона — һөҗүм. Һөҗүм коралы — альтернатив сәнгать.

— ???

— Мин милләтемә икенче сорт итеп карауга каршы. Хәлебез мөшкел. Мөшкеллегебез — мескенлектән, мескенлегебез — күндәмлегебездән.

— Татарлыгыннан курыкмаган һәркем сөйли торган зарлану сүзләрен кабатладың да, тәкъдим итмәдең... Иң мөһиме тәкъдим!

— Альтернатив сәнгать кирәклекне әйтү тәкъдим түгелмени?

— Нәрсә соң альтернатив сәнгать?

— Үзебезнең кино, мәсәлән, кинәсез кино.

— Моны милли җыелышларда чыгыш ясаучы һәркем әйтә. «Үзебезнең кино кирәк!» йола сүзенә әверелеп бара. Ә нәрсә соң ул «үзебезнең кино»? Ник кирәк ул? Кем карый аны? Кайда карый? Җавап юк. «Үзебезнең» сүзе «үзебездә, татарча төшерелгән», дигәнне генә аңлатса, безнең татар тамашачысы үзенең башкалардан ким түгеллеген киносыз да белә. Ә проблемаларга килгәндә... Алар уртак: бүген безнең Ил корабы тишек. Ә җилкәне ертык.

«Чыкты җилләр,
Купты тулкын —
Ил корабын җил сөрә!..
Кайсы юллар,
Нинди упкын
Тарта безне җан сорап?!»

...Кораб тишегеннән трюмнарга су тула... Ә лоцманнар, кораб тишелүгә тычканнарны гаепләп, тәбә кора. Тәбә белән булышканчы, корабны ямасыннар иде алар.

Без — татарлар, күп очракта кирәклерәк урында эшнең җайлырагын, күнегелгәнен эшлибез.

— Корабльгә тычкан да зур зыян китерә бит.

— Трюмнарга су тулып, палубада янгын чыкса, элек утны сүндереп, аннары тишек ямаргамы, синеңчә?

Синең «үзебезнең кино» дигәнең башта тишекне ямап, аннары янгын сүндерергә өндәү ул. «Ил корабын җил сөрә!»

Сүз җан саклау турында гына түгел. Ил җанын, милләт җанын саклау турында.

— Мин дә шул нияттән...

Дәвамы киләсе саннарда

«ТУРАН» ФОНДЫНА 20 ЕЛ

ҮТКӘННЕ САГЫНУ ҺӘМ КИЛӘЧӘККӘ ӨМЕТЛӘР

РОЗАЛИНА ШАҺИЕВА,
Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе

«ТУРАН» СҮЗЕ НИ ДИГӘННЕ АҢЛАТА? БУ – ҖИЛ СЫМАН ҖИТЕЗ, ТӨРКИЛӘРНЕҢ ЙОРТ УЧАГЫН ҮЗЕНЕҢ ИГЕЛЕКЛЕ КАНАТЛАРЫ АСТЫНА АЛГАН ӨЙ ИЯСЕ ТУРАНМЫ, ӘЛЛӘ РИВАЯТЬЛӘРГӘ КЕРЕП КАЛГАН, ИРАННЫҢ БРОНЗА ГӘҮДӘЛЕ ҖИҢЕЛМӘС ПӘҺЛЕВАННАРЫНА КАРШЫ ТОРЫРЛЫК БАҺАДИРЛАР ВАТАНЫ – ТӨРЕКЛӘРНЕҢ (ТӨРКИЛӘРНЕҢ) БОРЫНГЫ МИФОЛОГИК ТУМЫШ ИЛЕНЕҢ АТАМАСЫМЫ? ӘЛЛӘ БУ ИДЕЛ ИДАРӘНЕҢ ХАТЫНЫ ТУРАН БИКӘНЕҢ ӘКИЯТИ СИХЕРЛЕ ИСЕМЕ ТУРАНДОТМЫ?

Беренчедән, Туран — тарихи чыганаклар буенча, төркиләрнең бетмәс-төкәнмәс җирләренең атамасы. Ә мәдәни яктан бу — төрки сәнгатенең иң бөек баскычларын тәшкил иткән Пазырык хәзинәләре һәм Күлтәгин белән Тоньюкук рун язмалары төшерелгән таш билгеләр, Идел буе сәнгате һәм Истамбул мәчетләренең кабатланмас архитектурасы, казах юртасының бизәлеше һәм игътибарны җәлеп иткән чуваш чигеше, Дагыстанның алтын эшкәртүчеләре һәм азәрбайҗан келәм сугу сәнгате, Урта Азия миниатюра сәнгате һәм Тува скульптурасы, башкортларның агачка төшерелгән нәфис нәкышләре һәм татарларның алтын җепкыр сәнгатен берләштергән Хәтер — олуг сәнгать ул Туран.

Туран — хәтер гәүдәләнеше генә түгел, ә бәлки XX гасыр культурасын үзгәртеп, камилләштереп, аны дөньяга тәкъдим итәрлек яңа мәдәни гүзәл миф та.

Дөресен әйткәндә, «Туран» — кискен үзгәрешләр чорында формалашкан яңа узаңның сәнгатьчә гәүдәләнеше, плюралистик заманда киң итеп ачып куелган «идән аслары» — андеграундтан (яшерен остаханәләр) чыккан эзләнүләр, формаль яктан гаҗәеп сәнгать алымнары гына түгел. Массакүләм мәгълүмат чаралары белдергәнчә, милли романтизмның гәүдәләнеше генә дә түгел. 1990 елларда Татарстанның сәясәтендә, икътисадында, фән, укыту эшендә шактый зур үзгәрешләр булып үтте. Мәдәният өлкәсендә кискен концепция һәм яңа сәнгатьне аңлаткан тат-арт күренеше туды. Бу реализм күренеше белән Көнбатыштан элеккеге СССР чикләре аша ургылып кергән яңа сәнгатьнең синтезыннан гыйбарәт иде. «Туран» эгидасы астында шактый чуар һәм матур күргәзмәләр үтте. Алар арасында иң гүзәле «Чыңгызхан» төркеме иде.

Суфия Хәйбрахманова

Икенче күргәзмә — тарихны яңача аңларга этәргән, Милли-мәдәни үзәк залларын элеккеге Урда киңлекләрендә «яшәгән» рәссамнарны җыйган Казан, Уфа, Оренбург, Әстерхан, Казахстан, Урта Азия, Себер рәссамнарын берләштерде. Төсләр ташкынын буйсындырып, мифологиясе, гаҗәеп фантазия климаты белән шаккатырган бу авангард, чын мәгънәсендә, Казанда сәнгать империясе тудырды, беркемне дә битараф калдырмады.

Суфия Хәйбрахманова XX гасыр ахыры реалистик татар сәнгатенең хәвефле психологизмын беренчеләрдән аңлап, инстинктив рәвештә «яңалар»ның «җимерү»ләрен яңа билгеләр — дала тамгалары һәм бизәкләре аша раслаган, «тат-арт»ны

беренче булып тәкъдим итүчеләрдән булды.

Суфия ханым бу адымны уйлап ясады.

...Менә ул атаклы арт-критик һәм коллекционер, дөнья арт-бизнесы вәкиле англияле Брайан Монтгомери белән сөйләшеп тора. Әңгәмәдәшенең типик Диккенс сурәтләгән йөзе озын бакенбардлар белән әйләндереп алынган, авызында — трубка, йөзендә акыллылык сыйфаты чагыла. Менә Суфия ханым Һиндстанның Россиядәге илчесе — күпне күргән хатынының күз алдында татар келәмнәрен ачып җибәрә: XVI гасыр Казан ханлыгы мәдәниятен XV йөздә Һиндстанда тәрәккыят иткән Бабурилар культурасы белән чагыштыра. Шулай ук «Туран» фонды президенты Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең

Читек осталары. XX гасыр башы (сулда), **хәзерге заман** (унда)

Абу-Даби шәһәрендә ачылган кул эшләре күргәзмәсендә катнаша, хатын-кызлар өчен чыга торган «Баян» журналына интервью бирә. Суфия ханымны Исламабадта узган халыкара мөселман мәдәнияте фестивалендә татар зәркәнчесе Илгиз Фазылҗанов үзе ясаган «Коръән» савытын тәкъдим итеп, беренче урынны яулаган вакытта да күрергә була иде. Каһирә, Бәхрәйн, Мисыр — менә аның иҗат траекториясе. Әйтергә кирәк, Суфия ханымның иганәчелеге ярдәмендә дөнья халыклары борынгы татар кул эшләре әсәрләрен, бүгенге осталар иҗат иткән җәүһәрләрне күреп соклана. Шул ук елларда «Туран» оешмасы, Истамбул һәм Казан арасында булган килешү нәтиҗәсендә, хәзерге заман декоратив-гамәли сәнгать үрнәкләрен Төркиядә тәкъдим итте. 2002-2003 елларда исә «Идел буе ислам мәдәнияте» дип аталган күргәзмә Пизада (Италия) узды.

«Туран» уздырган күргәзмәләр каллиграфия, шамаил, графика, эстампо, тарихи картина, миниатюра осталарының иҗат үрнәкләрен берләштерә. Биредә элекке осталарның эшләре белән хәзерге заман иҗатчыларының эшләнмәләре үрелеп бирелә. Татар сәнгатен дөньякүләм аренага күтәрүдә тәкъдири чаралар әһәмияте зур иде. Төрле-төрле авырлыклар (оештыру, таможня, транспорт һ.б.) аша үтәргә туры килсә дә, Суфия ханым җиңүләргә иреште. Будапешт (1993), Истамбул (1994), Мәскәү (1995, 2010), Белоруссия (1997) һ.б.

«Туран» фонды тарафыннан җитештерелгән әйберләр

төбәкләрдә бүләкләр, медальләр, дипломнар яуланды.

Әйе, дөнья мәдәнияте даирәсендә үз йөзеңне күрсәтү җиңел түгел. Нәрсә ул — татар сәнгате? Аның үткәне һәм бүгенгесе нинди? Асылын ни тәшкил итә? Дөнья халыклары каршында әлеге сорауларга җавап бирергә кирәк иде. Моның өчен үз карашың булу, үткәнне яхшы белү зарур. Ә татар сәнгатенең үткәне турында башлыча музей витриналары, XVI гасырда яндырылган Казан ханлыгының көл-күмергә күмелгән кайбер һәйкәлләре һәм һөнәрче-осталар иҗаты аша гына белеп булыр иде.

Нечкә интуицияне, үзеңнең миссияңә ышануны һәм чорлар аша килгән тарихи дөреслекне останың карашы белән кушарга, һимаячеләрдән дә яклау табарга, шул рәвешле иҗади бөтенлек хасил итәргә мөмкин. Импульсларга интеграция (структура) характерын бирергә кирәк. Бу процесс башта Казан һәм Яр Чаллы шәһәрләренең даими эшли торган сәнгать галереяләре кысаларында барды. Суфия ханым оештырган күргәзмә-очрашулар халыкта зур кызыксыну, соклану һәм уңай тойгылар уятты. Бу уңышларына сөенгән Суфия ханым, Г.Ибраһимовның 1915 елда «Аң» журналында басылган мәкаләсенең исемен куеп, бүгенге сынлы сәнгать проблемаларын яктырткан «Сәнаиг Нәфисә» журналының берничә номерын чыгару бәхетенә ирешә.

«Туран»ның 1990 еллардагы эшчәнлеге «бүгенге милли сәнгать» төшенчәсе барлыкка килүдә бик зур роль уйный. Татарстандагы осталар гына түгел, Россия, хәтта чит илләрдәге сәнгать әһелләре бер божрага туплана. «Туран» уздырган күргәзмәләр булмаса, Мәскәүдә яшәгән И.Фазылҗанов шундый зур профессиональ дәрәҗәгә үсеп җитәр иде микән?! Дөнья Расих Әхмәтвәлиевнең матур иҗат үрнәкләрен, Равил Заһидуллинның иң гүзәл «алтын бүрәнәле Казан» сурәтләнгән «Сабантуй», «Болгарлар»ын күрә алмас, үзенең әкияти «төшләре» — җәннәт картиналарын тудырган Әлфия Ильясова дөньяны шаккатырмас иде. Элекке феерик ан-

деграунд вәкиле, хәзер неоромантик һәм әкияти иҗатчы Илгиз Гыймранов та, бәлки, бу дәрәҗәдә ачылмас иде... Хәтта «бөекләрдән» Илдар Зарипов, Әхсән Фәтхетдинов та аның тәэсирен тоеп яшәделәр һәм иҗат иттеләр. Шул рәвешле, Суфия ханым рәссамнарга ярдәм итте, аларны яңа темаларны ачарга этәреп, шактый тупланма булдырды.

Болар барысы да Суфия ханымның шәхси тырышлыгына, тирән интуициясенә, тарихка, сәнгать психологиясенә игътибарлы булуына бәйле. Суфия электән халкыбызның борынгы кул эшләре әсәрләрен бөртекләп җыя, ясау технологияләрен терки. 90нчы еллар уртасыннан ул, җәмәгатьчелек ихтыяҗын тоеп, Татарстанның яңа сувенирларын җитештерү эшенә чума. Шул ук вакытта Казанның тынычлык шәһәре, рухи учагыбыз, югары культуралы башкала булуын яклап, төрле акцияләрдә катнаша. «Туран» Казанда «Борынгы Казан» (1999), «Ислам мәдәнияте» (2001), Мәскәүдә — «Ислам һәм татар халкының рухи мәдәнияте» (2001) Парижда ЮНЕСКО штаб-квартирасында Казанның 1000 еллыгына багышланган презентацияләр оештыра (2001), Хельсинкида «Казанга — 1000 ел» (2002), Италиядә «Идел буенда ислам мәдәнияте» (2002) дип аталган чыгыш ясый.

Казанның 1000 еллыгына багышланган чараларда Суфия ханым һәм аның иҗатташлары актив катнаша: татар милли костюмнары, халкыбызның үзенчәлекләрен чагылдырган сувенирлар традицион гамәли сәнгать үрнәкләре җитештерәләр.

Күп тә үтми, «Туран» бүгенге көннең югары таләпләренә җавап бирә торган элитар милли сувенир хәзерләүче бердәнбер иҗат берләшмәсенә әверелә. Традицион төсләр гаммасын һәм самими милли формаларны саклап, татарга хас үзәнчәлекле ыссуларны яңартып, «Туран» Татарстан һәм Казанның җаваплы дипломатиясе өчен репрезентатив сувенирлар эшли.

Шулай итеп, коллекция туплау һәм галерея эше инде икенче планга күчә. Милли мирасны яңартуга юнәлгән музей хезмәткәрләре, этнографлар, сәнгать белгечләре, элеккеге халык һөнәрчелеген саклаган осталар белән берлектә Суфия ханым гомуммилли мәсьәлә — халык традицияләрен торгызу, яңарту, аларны яңа бөеклекләргә күтәрү мәсьәләсен чишәргә омтыла. Милли сувенирларның төрләре арта. Казан сөлгеләре, укалы читекләр, укалы калфаклар, түбәтәйләр, каюлы күн һәм сырлап тегелгән күн әйберләр, агачтан эшләнгән тартма, савыт, сандык, уенчыклар һәм шул ук вакытта бөек мирас — шамаил, тамга, тугралар, көмеш чулпы, алкалар һәм төрле бизәнү әйберләре әнә шундыйлардан. Шулай итеп, элекке мирас бүгенге дөнья базарында яңа форма һәм жанрларда үз урынын таба.

Суфия ханым һәм аның фикердәшләре күзаллавынча, милли сувенир — дәүләт эмблемасына төренгән кулай уенчык кына түгел, ә миллилекне үзендә туплаган, жанры белән зур булмаган уникаль кул эше әсәре. Ул чор, цивилизация, милләт хакында тулы мәгълүмат бирергә тиеш. «Казан» сувенирлары үзенең үсешен дәвам итә. Мәйданга атка атланган бронза җайдаклар, чикләвек кадәр генә филигрань Коръән савытлары, «алтын таҗ», күн калканнар чыга. Аларда табигатькә җайлашу нәтиҗәсе дә, чын мәгънәсендә, нәфис әйбер ясау — конструктив тәҗрибәне саклау да чагыла. Шул рәвешле, «Туран» фонды үзенең эшләү, эш ысулларын, гасырлар буена сакланып килгән халык традицияләре белән бергә үреп алып бара, аларны өйрәнә, документаль рәвештә системалаштыра.

Урта Азиядә — Хивада халкыбызның «ак юлын» гамәлгә ашыручы татар Рерихы — Хәсән Галиәкбәров: «Орнамент — ул геометрик схема, чәчәкле бизәк кенә түгел, ул — җан! Халык җаны!» — дигән иде. Бөек акыл иясе, акрын гына калфак-читекләрне сыйпап: «Менә бу «сөю орнаменты» була, бусы — «хәрби орнамент», «медицина орнаменты», бусы — «галәм», — дип өсти ул. Чыннан да, һәр орнамент — кыйсса ул, аның барлыкка килүе конкрет вакыйгага, тарихка бәйле. Мәсәлән, Сөембикә ханбикә сандыгының орнаментында — аның бөеклеге һәм фаҗигасе, сагынусагышы; Казан тәрәзәләренең бизәгендә шәһәрнең матурлыгы һәм нурлылыгы; Шаһгали калканындагы бизәкләр аның көчсезлеген, түбәнлеген гәүдәләндерә.

Фәйләсуф үзенең фикерләре белән орнамент сәнгатенең фигуратив сәнгатькә караганда бөегрәк икәнен исбатлап: «Төрки-мөселман халыклары Европа халыкларыннан рәссамчылык өлкәсендә 100-150 елга алга киттеләр!» — дип белдерә.

Чынлап та, татар орнаменты — гаҗәеп күренеш. Яшеренгән күбәләк-бөҗәкләр, кошлар, хәтта хатын-кызларның күренер-күренмәс силуэтлары (алкалар, күкрәк бизәкләре, тукылган формалар)... Җентекләбрәк карасаң, татар читекләренең кунычларындагы «түгәрәк» һәм «йөрәк» сурәте дә — яңа тормыш (җан) туу сюжеты, ә инде читекнең җирлегенә игътибар итсәк, безгә бизәк тулы келәмнән «Тәңре» — Күк алласы карап тора...

«Туран» мифологиягә нигезләнеп эш итә. Орнаменталь пластларның яшерен хикмәтен тоеп, аларның серен күз алдында тотса да, ул берсен дә механик рәвештә күчереп утыртмый. Орнаменталь формаларның халык йөрәгенә якын булганын сайлап, мифларны нечкәртеп, бүгенге көнгә якынайтып, яңа якты төсләр, сызымнар аша сурәтли.

«Орнаменталь экспериментларның мәйданчыгы итеп, без түбәтәйләрне сайладык», — ди Суфия ханым. Бүгенге түбәтәйләр — дини кием элементы гына түгел, ә милли йөзебез. Шуңа күрә алар үзгә: алтын белән чигелгән астраль (йолдыз-күк сурәте) космопланетар сурәтләр белән беррәттән, чор-заман таләпләренә җавап биргән геометрик образлар, чәчәк, йолдызлар кебек образлар алга чыга. «Туран» күп технологияләрне берләштерүдән, модернизациядән курыкмый.

«Туран»ның икенче кызыксыну өлкәсе — милли нәфис мохит һәм милли костюм (кием). Бу өлкәләрдә борынгы генетик тамырлар, табигатькә адаптация ысуллары ачыла. Шул ук вакытта бу ике өлкә халык зәвыгының чагылышы да. Кием — ул халыкның тарих төбеннән алып чыккан автопортреты, сурәте... «Милли кием дигәндә, без югары рухи мирас белән эш итүебезне аңлыйбыз. Ул — әдәби эпоска тиң, стихияле рәвештә туган архитектур ансамбль, театраль классика», — дип искәртә Суфия ханым.

XIX гасыр ахырында хатын-кыз киеме үзенең иң бөек үсеш ноктасына

Франциядә Россия көннәре. «Туран» фонды тупланмасыннан күргәзмә. Канны. 2009 ел

җитә. Атлас, тафта, парча, ефәк, төрле бөрмә элементлар, бәби итәкләр (воланнар), чуклар (бахрома), спиральләр, төймә, прәшкәләр, буй-сынга килешеп торган матур камзол, хәситә һәм яка чылбыры, бу конструкцияне «күкләргә күтәргән» гаҗәеп калфак — барчасы гөл куагы яисә тормыш агачы образы кыяфәтен бирә. Киемнең мифологик архетипы — сихерле кош (бәлкем, Хумайдыр), шуңа күрә күлмәк җиңнәре киң эшләнә — кош канатларын хәтерләтә. «Туран» калфак һәм аерым детальләрне катлаулы техника һәм ефәк җепләргә асылташлар тагып ясалган композицияләрне дә кулланып эшли.

Кием белән мохит бер-береннән аерыла алмый. Кием яңару, тирә-юньдәге әйберләрдән дә яңалык, сафлык таләп итә. Шамаилләрне генә алыйк. Алар бәрхеткә төрле асылташлар эретеп эшләнгән. Текстлар илаһи... Сандыкларда — сырлы-сырлы нечкә бизәк. «Казанның каюлы көне» техникасын файдаланып башкарылган келәмнәрдә — сихри тамгалар, галактика билгеләре. Ә менә ак сөлгеләрдә көмеш лаләләр, үзләреннән нур бөркеп, тормышны шәхес үзе генә тоемлаган фантастик балкышка әйләндерәләр...

Күргәнебезчә, «Туран»ның төп максаты — милли кул эшләре төрләрендә ритмиканы, үзгәлекне яңа буыннарга кайтару, орнаментлар гөлбакчасын торгызу, гүзәллек хисе тәрбияләү.

Сихерле, әле ачылып бетмәгән татар орнаментының мифологиясе, аның гүзәллеге, борынгылыгы вә тормышчанлыгы, нәкыш формаларының матурлыгы — милли мәдәниятнең үзенчәлекле өстенлеге. «Бу борынгы формалар ташкынын бүгенге тормышта кулланышка кертеп җибәрергә кирәк, — ди Суфия ханым. — Әгәр безнең яшәешебез шулар ярдәмендә илһамландырылса, һәр көнебез бәйрәм булыр иде», — ди остаханә хуҗасы Суфия Хәйбрахманова. Бу сүзләрдә хаклык бар. ■

ӘДӘБИЯТ

Минем дәүләтемдә — бар да шагыйрь,
Тукай — патша, Такташ — премьер...

Илдар Юзеев

«ТӨРКИ ХАЛЫКЛАРДАН МИН БЕРҮЗЕМ...»

РЕНАТ МӘГЪСҮМ УЛЫ ХАРИСОВ (РЕНАТ ХАРИС) — шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе. ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1980), Каракалпак АССРның, Чувашстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре (1980, 2002). Татар, рус, башкорт, чуваш телләрендә 30дан артык шигырь китаплары авторы. Шагыйрь Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты (1997).

1973-1982 елларда ТАССР мәдәният министры урынбасары, 1982-1989 елларда «Казан утлары» журналының, 1991-1995 елларда «Татарстан хәбәрләре» газетасының баш мөхәррире. 1990 елдан Татарстан Республикасы Югары Советы депутаты, 1995 елдан Татарстан Республикасы халык депутаты. 1995-2000 елларда ТР Дәүләт Советы рәисе урынбасары, 1991-1993 елларда ТР Конституция комиссиясенең дәүләт символларын булдыру төркеме җитәкчесе.

Ренат Харис берничә ай элек Россия Федерациясе Президенты каршындагы Мәдәният һәм сәнгать комиссиясенә вәкил итеп билгеләнде. Шул уңайдан аңа берничә сорау белән мөрәҗәгать иттек.

–Ренат әфәнде, Сезне Россия Федерациясе Президенты каршындагы Мәдәният һәм сәнгать комиссиясенә билгеләнүегез белән чын күңелдән котлыйбыз.

Әлеге консультатив оешмага зур миссия – Президентка Мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә дәүләт сәясәтен алып бару өчен тәкъдимнәр эшләү, бу өлкәдә эшләр барышы белән ил башлыгын таныштырып тору, хакимият белән иҗат коллективларының,

мәдәният һәм сәнгать оешмаларының элемтәләрен ныгыту йөкләнә. Сез – Россия Федерациясе Президенты каршындагы Мәдәният һәм сәнгать комиссиясенә билгеләнгән бердәнбер татар милләте вәкиле, киңрәк карасак, илдәге күпсанлы төрки халыклар вәкиле дә.

— Котлавыгыз өчен рәхмәт. Әйе, Россия Президенты каршындагы Мәдәният һәм сәнгать советының төп вазифасы — шушы өлкәдәге проблемаларны өйрәнү, мөһимлек дәрәҗәсен билгеләү һәм аларны хәл итәрдәй тәкъдимнәрне ил җитәкчелегенә җиткерү. Шуның өчен дә әлеге оешмага илебезнең бу өлкәдәге проблемаларны тирәнтен белгән Ю.Башмет, В.Гергиев, С.Говорухин, А.Калягин, М.Пиотровский, В.Спиваков, О.Табаков, В.Толстой, К.Шахназаров кебек абруйлы сәнгатькәрләре кертелгән. Алар арасында өч язучы да бар: А.Варламов, «Литературная газета»ның баш мөхәррире Ю.Поляков һәм сезнең әңгәмәдәшегез. Мин Советның дүрт утырышында катнаштым һәм шуны әйтә алам: чыннан да, бу киңәшмәләрдә сәнгатебездә, мәдәниятебездә булган казанышлар һәм җитешсезлекләр турында төпле, җитди сүз алып барыла, эшлекле тәкъдимнәр әйтелә. Кайбер тәкъдимнәр Россия Президентының йөкләмәләренә әверелә һәм ил Хөкүмәтенә китә, ә кайберләре, законнар камил булмау аркасында, йә бөтенләй булмаганлыктан, тоткарланып та тора. Андыйлары хакында Президент илебезнең Федераль Собраниесе алдында бурычлар куя. Әйтик, 2012 елның 25 сентябрендә В.В.Путин җитәкчелегендә узган пленар утырыштан соң Россия Хөкүмәтенә җитди йөкләмәләр китте. Алар арасында тиз үтәлә торганнары да, әйтик, Советның интернет-порталын булдыру кебекләре дә, күренекле сәнгать коллективларына, театрларыбыз гастрольләренә дәүләт ярдәме күрсәтү, авылларда, кечкенә шәһәрләрдә күп функцияле ял итү үзәкләре булдыру, аз хезмәт хакы алып эшләүче мәдәният хезмәткәрләренең, шул исәптән китапханәчеләрнең дә, 2013 елда хезмәт хакларын арттыру кебек даими рәвештә күз уңында тотылырга тиешлеләре дә бар. Президентның йөкләмәләре үтәләчәк, дип ышанасы килә.

Соравыгызның икенче өлешенә җавап бирер алдыннан, мин Мостай ага Кәримнең 2004 елның 11 сентябрендә язган көндәлегенең бер бите белән таныштырырга телим: «Рус булмаган халыклар мәдәниятенә олы куркыныч яный. Ельцин вакытларыннан бирле (ә хәзер бигрәк тә) Россиядә руслыкы булмаган мәдәниятләр барлыгы хакында эндәшмиләр, әлегә эндәшмиләр генә. Тиздән сепаратизмга каршы көрәш байрагы астында турыдын-туры һөҗүм башланачак. Алдымда Президент каршындагы Мәдәният һәм сәнгать советы әгъзалары исемлеге бирелгән Указ (30.08.2004) басылган газета. Бу Советта бер генә милли мәдәният вәкиле дә юк, әйтерсең лә алар, милли республикалар, бөтенләй юк... Заманасында рус интеллигенциясе аз санлы халыкларны яклый торган иде. Хәзергеләре, үзләрен рус интеллигенты дип йөрткәннәре, хакимиятне безгә — рус түгелләргә — өстерәләр. Советтагы бу 28 кешенең кайсысы башка халыклар мәдәниятләрен якларга сәләтле?..» Әлбәттә, Мостай аганың әле күптән түгел генә «Уфа» журналында басылып чыккан көндәлеге Мәскәү Кремленә барып ирешмәгән. Ләкин аның фикерләренә охшаш фикерләр, күрәсең, булгандыр, күергандыр. Нәтиҗәдә, Совет исемлеге бик нык үзгәргән — сан ягыннан 59 га җиткән, кемнәрдер чыгарылган, яңа әгъзалар өстәлгән.

Ә инде минем кем урынына килүем мөһим түгел. Бәлки, Макаревич урынына түгел, ә Лариса Долина урынына килгәнмендер?.. Советтагы һәр әгъзаның урыны — кабатланмас, һәр сәнгать эшлеклесенең шәхси абру-

ена бәйле урын. Әгәр дә Макаревич Дәүләт премияләрен карауга гына игътибар иткән икән, бу аның шәхси күзәтүчәнлеге генә. Ә Россия Федерациясенең Дәүләт премияләрен хәл итү — илкүләм мөһим эш. Асылда ул — мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге казанышларны билгеләү генә түгел, ә бөтен культура үсешенә юнәлеш бирү. Менә хәзерге вакытта сәнгатьнең авангард юнәлеше белән реалистик чын сәнгать арасында бәхәс көчәеп килә. Илебезнең культурасы кайсы позициягә басарга тиеш? РФ Дәүләт премияләрен билгеләү бу сорауга ачык җавап бирә. Элек, совет заманасында, фәкать Ленин һәм Дәүләт премияләрен билгеләү өчен генә махсус комитет эшли иде. Анда Нәҗип Җиһанов та бар иде. Ә премияләр билгеләү Президент каршындагы Советның күптән бер вазифасы гына. Ләкин бик тә мөһим вазифасы.

– Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгы каршында да мәдәният буенча иҗтимагый совет бар. Бу ике оешманың эш башкару ягыннан аермасы нәрсәдә? Алар хезмәттәшлек итәләрме? 1996 елдан, оештырылганнан бирле, Россия Федерациясе Президенты каршындагы Мәдәният һәм сәнгать комиссиясе нинди мәсьәләләрне хәл итте? Аның еллык эш планы бармы? Үзегез катнашкан беренче утырышлардан алган тәэсирләрегез нинди?

— Россия Мәдәният министрлыгы каршында иҗтимагый совет барлыгын беләм. Хәтта аның бер утырышына да чакырылган идем, бара гына алмадым. Ул утырышның көн тәртибендә нәкъ Президент каршындагы Советның узган елның 25 сентябре утырышында барлыкка килгән, туризмга кагылышлы йөкләмәсен карау иде. Совет утырышларына Дәүләт Думасыннан да, Федераль министрлыклардан да, төрле департаментлардан да җитәкчеләр, җаваплы хезмәткәрләр чакырыла. Утырышлар пленар рәвештә һәм ведомствоара комиссияләр форматында уздырыла. Әйтик, «Гуманитар алгарыш, сәнгати мәгариф һәм яшь буынга иҗади тәрбия бирү» комиссиясенең 2012 елның 18 декабрендә үткәрелгән утырышына Казан консерваториясе ректоры Рубин Абдуллин да чакырылган иде һәм ул анда әтрафлы чыгыш ясады. Гомумән, утырышлар гаять әзерлекле, җитди булалар. Һәр чыгыш теркәлеп бара, фикерләрне белгеч экспертлар тикшерә, сөземтә чыгара һәм Президент йөкләмәләрен рәсмиләштерәләр.

Ә Советның 1996 елдан алып бүгенге көнгәчә ниләр башкарганын мин тәфсилләп сөйли алмыйм, чөнки мәгълүматым әлегә җитәрлек түгел. Эш планнарына килгәндә, шунысын гына әйтә алам: В.В.Путин катнашында пленар утырышлар елына 1-2 тапкыр булырга мөмкин, ә ведомствоара комиссияләр — 3-4 мәртәбә. Аларның көн тәртипләре вазгыятькә карап билгеләнәчәк. Ләкин РФнең Дәүләт премияләренә кагылышлы мәсьәлә, һичшиксез, һәр елның май аенда каралачак, чөнки традиция буенча 12 июньдә — Россия көнендә — ул премияләр тапшырыла.

– Әле генә Бөтендөнья татар конгрессының V корылтае тәмамланды. Анда татар мәдәниятенең бүгенге хәле һәм киләчәге турында борчулы чыгышлар булды. Сезне милли мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә нинди мәсьәләләр аеруча борчый? Аларның кайсыларын тормышка ашырырга алынып идегез?

— Татар әдәбияты, сәнгате, мәдәнияте өлкәсендә мине борчыган мәсьәләләр бик күп. Аларны санап торырга да кирәкми, чөнки һәр милли җанлы кеше моны бик яхшы белә. Россия Президенты каршындагы Совет утырышларында туган телләрне, милли мәктәпләрне, авылларны саклау турында да, китап язмышы турында да, театр, эстрада проблемалары хакында,

профессиональ сәнгать өчен кадрлар әзерләү, аларның хезмәт хаклары турында да сөйләшәбез, мәдәният турындагы законга һәм башка законнарга карата фикерләребезне әйтәбез, төрле-төрле тәкъдимнәр кертәбез.

Мин соңгы утырышларның берсендә Россия халыкларының рухи бердәмлеген тәэмин итә торган йә булмаса бу бердәмлекне какшата торган хәлләр турында сөйләдем. Сүз уңаеннан күптән түгел кинотеатр экраннарына чыккан «Орда» дигән фильмның әлеге мәсьәләгә деструктив тәэсире турында сөйләдем. Каршы чыгучы булмады.

Милли мәдәниятне һәм сәнгатьне дөнья мәдәнияте йә булмаса бөтенроссия мәдәнияте һәм сәнгатенең бер өлеше итеп карап фикер йөртү — бер нәрсә. Аларны башка мәдәниятләр белән чагыштыру — икенче нәрсә. Бу очракта татар әдәбияты һәм сәнгатенең казанышлары да, җитешмәгән яклары да ачыграк күренә. Ул проблемаларны бер кеше генә хәл итә алмый, ләкин һәр язучы, композитор, режиссёр, артист, җырчы, рәссам моңа омтылырга һәм һәр әсәре белән шуңа ирешер өчен тырышырга тиештер дип уйлыйм мин. Шул очракта гына татар культурасы, мәдәнияте, әдәбияты, сәнгате заман таләпләренә җавап бирерлек булачак. Мин дә мәдәниятебез алдында торган мәсьәләләрне хәл итүдә конкрет әсәрләр язып катнашам. Аларның сәнгати сыйфаты, колачы, тирәнлеге, актуальлеге турында бернәрсә дә әйтә алмыйм. Бу — минем эш түгел.

– Ренат әфәнде, Россия Федерациясе Президенты каршындагы Мәдәният һәм сәнгать комиссиясендә татар яки төрки халыклар мәдәниятенә, сәнгатенә караган кайсы мәсьәләләргә ил башлыгының һәм җәмәгатьчелекнең игътибарын юнәлтергә уйлыйсыз? Ялгышмасам, комиссия Президиумына күренекле җырчы, «Машина времени» төркеме әйдәманы Андрей Макаревич урынына билгеләндегез. Ул Россия Федерациясе Президенты каршындагы Мәдәният һәм сәнгать комиссиясе бернинди мәсьәлә дә хәл итмәде, фәкать дәүләт премияләренә кандидатлар билгеләү мәсьәләсе буенча гына җыелды, дигән иде.

— Әйе, анда төрки халыклардан мин берүзем. Бу Совет милли, территориаль, конфессиональ, партиялелек принципларына таянып төзелмәгән. Шулай да мин үземне, беренче нәүбәттә, татар халкы вәкиле буларак, аннары, мондый вәкаләтне миңа беркем бирмәсә дә, милли республикалар вәкиле буларак хис итәм. Узган утырышларның берсендә Россия мәдәниятенең чит илләрдәге урынын киңәйтү, ныгыту турында фикер алыштык һәм тәкъдимнәребезне әйттек. Чыгыш ясаучыларның барысы да башлыча рус мәдәниятен генә кайгырттылар. Үземнең чыгышымда мин алтай, башкорт, мари, мордва, татар, удмурт, чуваш һәм башка халыкларыбызның мәдәниятләре дә Россия мәдәнияте икәнлеген, безне дә онытырга ярамаганлыгы хакында сөйләдем, бу мәсьәләдә ел саен бик күп илләрдә гөрләп уза торган татар Сабан туен, мариларның Семык, удмуртларның Гырон-быдтон һәм башка халык бәйрәмнәрен файдаланырга кирәклеген әйттем. Федераль телевидение каналларында милләтләр сәнгатенә, әдәбиятына урын бирелмәве, зур вакыйгаларга багышланган концертларда милли республикалардан сәнгать коллективлары, артистлар, язучылар катнашмавы турында да сөйләргә туры килде.

Ил башлыгының игътибарын җәлеп иттерәсе килгән мәсьәләләр, әлбәттә, бик күп. Алар әйтелә торалар... Тамчы тама-тама ташны тишә, диләр бит...

– Әңгәмәгез өчен Сезгә зур рәхмәт! Әлеге катлаулы эштә уңышлар телибез.

Әңгәмәдәш —
Илдус Заһидуллин

БӘКЕР САЗЫ

(Риваять-поэма)

РЕНАТ ХАРИС,
Татарстанның халык шагыйре

Ханның атлары картайды…
Ләкин бар һәрбер атның
үз иркендә бу дөньядан
китеп барырга хакы…

Һәркайсының Хан алдында
казанышы олыдан —
таш йөрәкле кеше генә
яхшылыкны оныта.

Әнә, җирән айгыр аны
яу кырында коткарды.
Әле һаман ук эзләрен
саклый атның ботлары.

Күк кашкада лачын кебек
җилләрне коча-коча,
Чатыртауга очып менде
чаптырып, туктамыйча…

Алмачуар иярендә
килде аңа зур хәбәр:
бортас ханы үлеп киткән —
димәк, кимегән хәтәр!..

Ханбикәсе, олан табып,
түшәгендә җан бирде…
Кара айгырда җилдереп,
ул кайгысын сүндерде…

Бу озын, тәбәнәк атта,
тырпаеп өзәңгедә,
кистән белән бүре сукты
Шушма-су үзәнендә…

Теге өердәгеләре —
ничә яу үткән атлар,
Чулманнан сулар эчкән һәм
Җаекка җиткән атлар…

Кайсы атка караса да,
хатирәләр яңара:
әнә туры айгырда ул
кәләш алырга бара;

әнә ул атасы ханны,
җиңүе белән котлап,
чуклы байрак җилфердәтә,
кыя өстендә туктап...

Кайсы атка караса да,
Ханны хатирә баса:
атлар — гомер мизгелләре,
тормыш юллары ласа...

Кайсысына караса да,
күрә: ат үшәнләнгән...
Белә: берсенең дә юлы
такырдан түшәлмәгән.

Кайсы атка караса да,
күрә алар күзендә
ниндидер моңлы ялвару...
Әйтеп булмый сүз белән...

Берсе хәтта елый әнә,
яман язмышын сизеп...
Башкалары да чак-чактан
торалар кебек түзеп...

Хан түзмәде... Чакырттырды
киңәшкә җылкычысын...
— Атлар сине борчымасын,
сине гыйшкың борчысын!

И олуг хан, — диде Бәкер, —
картайган, хәле беткән
атларны ата-бабайлар
сугым иткән электән...

Күтелгән җавап ишеткәч,
Ханның ярсуы купты —
тотты да бөгеп сындырды
унлап бәйләгән укны.

— Бу атлар — минем гомерем,
Ил-йортның тарих юлы!
Тарихны сугым итәргә
күтәрелер кем кулы?!

Кемдер майлы калҗаларны,
кадап сөңге очына,
утта тотып кыздырганда,
кем торыр тыныч кына?!

Кырын ятып, кымыз эчеп
чәйнәгәндә шуларны,
намусыбызның калканы
ватылмасмы, чыдармы?

Һәр атның кушаматы бар!
Кешегә дә, малга да
кушамат тиккә тагылмый —
исем иңә Аллаһтан...

Бурлы бия — Очлыколак,
ярканат кебек сизгер —
тау-ташлар аша ишетеп,
дошман хәйләсен өзде.

Авыр башын чак күтәреп
басып тора Кушйөрәк,
күкрәк белән калкан ваткан
мондый айгырлар сирәк.

Теге бия — Канатбәкәл,
күпме сабантуйда ул,
ал килеп, сөлгеләр алды,
ул — өермә, ул — давыл!

Ак кар төсле бу биянең
кушаматы Аккоштыр.
Аңа лаек бу исемне
мәрхүм ханбикәм кушты.

Дистәләгән дошман башын
бәреп ватты Таштояк...
Шуларны сугым итәргә
Аллаһ алдында оят...

— Оят шул! — диде Бәкер дә, —
тик белмим башка чара...
Үзең боер! Ни боерсаң,
шуны төгәл башкарам.

Озак уйланып торды Хан,
маңгаен салып учка,
ләкин һич ялгый алмады
уйларның очын очка...

Суйсаң — гөнаһ! Ә суймасаң?
Алай итсәң дә язык —
яраксыз ат көтүендә
исраф була бар азык…

— Боерам! — диде шунда Хан, —
карарым гадел, каты:
Аллаһ иркенә җибәрәм
көтүнең барча атын;

үзләренчә гомер сөрсен
минем данлы атларым —
азат тормышта яшәргә
атларның бар хаклары.

Ә син, Бәкер, бар, эзләп тап
болынлы-сулы төбәк…
Ат көтүен шунда калдыр,
хәерле үлем теләп…

Һәм җылкычы боерыкны
нәкъ Хан кушканча үти —
ниндидер сазлык буенда
ялгызы кала көтү…

***
Ай үттеме, ел үттеме —
әрәмтамак атларны
беркем дә искә алмады,
хакламады хакларын…

Әллә алар җирдә булган,
әллә булмаганнар да…
Безне кайсы гасырда да
авыр бугай аңларга:

никтер яңалар янында
искене онытабыз —
янәсе, начардан китеп,
яхшыга юл тотабыз;

гәрчә эчтән сагынабыз
үткән данлы чакларны…
Ярар… Җитте… Кайда икән
теге Ханның атлары?..

***
Берзаман Хан ауга чыкты
Шушма-су үзәненә.
Лачын-кошы сул беләктә,
аягы өзәңгедә,

Әдрәс айгыр ияреннән
күренә күлләр, болын…
Кинәт камыш арасыннан
килеп чыкты бер колын.

Колын артыннан — ак бия!
Таныш та ул, түгел дә —
җилкәсе елкылдап тора,
күзеннән нур түгелә,

күкрәкләре әйтерсең лә
ике түгәрәк мендәр —
Ханның яңа көтүендә
бар микән моңа тиңнәр?

Танаулары тустагандай,
колаклары сөңгедәй;
агып торган озын ялы
аграк ефәк сөлгедән.

Арт саннары уйнап тора
кәнизәк янбашыдай…
Тешен ыржайтып кешнәде…
Теше — яшен ташыдай…

Хан астында әдрәс айгыр,
күргәч бия-сылуны,
беркайчан да булмаганча
шаулатты да сулуын,

арт аякларына басты…
Хан чак калды иярдә…
Ак бия каядыр чапты…
Айгыр аңа иярде…

Һәм Хан бияне таныды —
бу бит Аккош… Шул!.. Үзе!
Аның ялына ябышып,
чыккан иде ул йөзеп

көзге Чулман суы аша,
үләргә житеп, өшеп…
Шуннан соң гүзәл биянең
тубыгына су төште…

Аккош-бия тернәкләнгән,
ничек шулай савыккан —
ак җилкән күк килеп чыкты
шушы сасы сазлыктан?!

Кара, кара! Әнә алда
нинди атлар өере?
Айгырлары пошкырыша,
башны күккә чөереп…

Теге, әвен зурлык атта
Таштоякның буй-сыны…
Ул үлергә тиеш иде —
аның бит биле сынык.

Ә ул һәйкәл булып баскан…
Иярен беркет кенә,
әзер ул әверелергә
Урал-тау бөркетенә…

Ничек булган бу могҗиза —
ничек савыккан атлар?!
Савыгып кына калмаган —
баш саннары да арткан!

Гаҗәп, хәтта карт бияләр
монда колын имезә!
Ә колыннары искиткеч —
уйнаклар һәм симезләр!

Хан онытты лачын-кошын,
ау аулыйсын онытты…
«Бу могҗиза нидән?» — дигән
уй-сорау Ханны йотты…

***

Узды айлар… Бәлки, елдыр…
Шушы сазлык ярында
теге җылкычы Бәкернең
сугып башын ярдылар,

сындырдылар аякларын,
ташладылар сазлыкка —
еланнарга, бүреләргә,
козгыннарга азыкка.

Юлбасарлар китеп барды,
мәет шунда черер дип…
Тәне ләмгә баткан Бәкер
черемәде! Терелде!

Кайтты ул ханы янына,
аягын бераз сөйрәп,
һәм терелү могҗизасын
халыкка бирде сөйләп:

— Атларны да шул саз ләме
савыктыргандыр, — диде, —
Аллаһ үзе ләмгә сихәт
салып торгандыр, — диде. —

Шул тирәдә мыжгып тора
җәнлекләрнең төрлесе —
ләмдә бергәләп ауныйлар
куян, поши, бүресе —

берсе берсенә ташлану,
курку юк уйларында,
берсе берсенә юл бирә
теге сазлык ярында;

чирлеләрнең кайгысы бер —
сихәтләнү, тазару…
Тазалар гына чәйнәшә,
һәм сугыша үзара;

тазаларга дөнья җитми…
— Җитте! Телеңне тешлә, —
диде Хан, — бар саз буена,
атларга аран эшлә…

Бәкер китте саз буена,
шунда алачык корды…
Ханның яралы атларын
ләм сылап савыктырды…

Дәвалады батырларны…
Килделәр бәкләр, биләр…
Алачык янәшәсенә
өстәлә торды өйләр…

Тезелеп китте урамнар…
Барлыкка килде авыл…
Гасырлар тасырдап үтте…
Авыл бүген дә сау ул…

Күпме исемнәр үзгәрде!..
Бәкер исеме исә,
хәтта гасырлар үтсә дә,
тере ләм кебек исән!

14-16 октябрь, 2012 ел.
«Бәкер» санаториясе,
«Сандугач» корпусы, 209 палата

ШӘРЕКЪ РЕНЕССАНСЫ*

РЕЗЕДА ГАНИЕВА,
филология фәннәре докторы

Ислам Ренессансының идеологик нигезе — Аллаһның барлыгын һәм Берлеген таныган Коръән тәгълиматы, аның үзәген тәшкил иткән әт-Тәүхид фәлсәфәсе. Ул — «лә иләһә илләл-лаһ» аяте — формуласы белән белдерелә һәм «Бер Аллаһтан башка Тәңре юк» дигән мәгънәне аңлата. Әт-Тәүхидкә, ягъни монотеистик карашларга таянып, гарәп, фарсы, төрки Яңарыш әдәбиятларында өч юнәлеш: дини-әхлакый, суфичылык һәм дөньяви эчтәлекле Ренессанс әдәбиятлары мәйданга чыга.

Шуны да истә тотарга кирәк: илаһият фәлсәфәсенә нигезләнгән бу юнәлешләр арасына «кытай дивары» корып кую мөмкин түгел. Чөнки еш кына бер үк әсәр кысаларында дини-әхлакый, суфичылык, дөньяви Яңарыш юнәлешләре өчен хас сәнгатьчә фикерләү үзенчәлекләре бергә килеп очрашты, үзара керешеп, укмашып яшәде. Аларның өчесе дә Аллаһы Тәгаләне олылады, Ренессанс дәвере мәдәнияте таләп иткәнчә, кешегә кешелекле мөнәсәбәт булырга тиешлеген яклап чыкты. Моңа классик мисал итеп урта гасыр реализмының үрнәге булган Мәхмүд Болгариның «Нәһҗелфәрадис» әсәрен (XIV гасыр) атап булыр иде. Шундый ук үзенчәлек XVII-XIX йөз татар әдәбиятының беренче яртысында иҗат иткән Мәүла Колый [1] һәм Утыз Имәни [2] иҗатларында күзәтелә. Шул ук вакытта бу юнәлешләр Аллаһ белән Кеше арасындагы мөнәсәбәтләрне дини, фәлсәфи-әхлакый күзлектән аңлатуда, образ-символлар белән эш итүдә берберсеннән аерылып та тордылар. Мәсәлән, Коръән өйрәтмәләренә таянган дини әдәбиятта гөнаһлы җир кешеләренең, Кыямәт көнендә куптарылып, Бөек Кодрәт иясе җәзасыннан — дәһшәтле, газаплы үлемгә дучар ителүдән куркулары, тәүбәгә килеп, Аллаһка сәҗдә кылулары, үз ихтыярлары белән Аңа коллык юлына басулары бик тә әһәмиятле вазифа булып исәпләнде. Шул сәбәпле Изге Китапта кыямәт, тәмуг, оҗмах кебек эсхатологик темаларга зур урын бирелде, ахырзаман турындагы сюжетлар аның үзәген тәшкил итте. Ни өчен соң Коръәндә һәм дини-әхлакый әдәбиятта явыз гамәлләр кылудан саклану, Аллаһтан курку кирәклеккә басым ясала, дигән сорау да туарга мөмкин. Моның сәбәбен Ибн Хәлдун болай дип аңлата: «Әгәр дә мәгәр Аллаһ кешеләрне тыеп вә куркытып тормаса, җир шары җимерелер иде» [3]. Мондый афәтләрне булдырмый калу өчен, дини-әхлакый әдәбиятның күренекле вәкилләре мөтәкәллимнәр мантыйкый дәлилләр, куркыныч һәм фаҗигалелек белән сугарылган, үгет-нәсихәт белән өртелгән әдәб әдәбиятының бер тарма-

*Дәвамы. Башы журналның 2012 елгы 10-11, 12 нче саннарында.

гы булган гыйбрәтле хикәят жанрына мөрәҗәгать иттеләр. Шул рәвешчә, алар, әхлакый кыйммәтләргә басым ясап, мөселманнарны явызлык кылудан, гөнаһ юлына басудан, мәгънәсез фетнәләр чыгарудан саклап калу, рухларын сафландыру мөмкинлегенә ихлас ышандылар.

Ортодоксаль дини юнәлеш вәкилләреннән аермалы буларак, суфичылык әдәбиятында Аллаһ белән Кеше арасындагы мөнәсәбәтләр икенче төрлерәк шәрехләнде. «Аллаһ — хакыйкать» турында сөйләгәндә, Аның Затын, асылын һәм атрибутларын (сыйфатларын) билгеләгәндә, тәсаувыфның атаклы теоретигы Ибн Гарәби кебек, «Хак», «Хак Тәгалә», «хакыйкать» төшенчәләрен куллану өстен күрелде. Коръән тәгълиматы белән тәсаувыф өйрәтмәләре арасындагы аерманы тәмуг белән оҗмах мәсьәләсен ничек күзаллау мисалында да күреп була. Тайпылышсыз үрнәк һәм үтәү мәҗбүри дип кабул ителгән Коръән, дини-әхлакый кануннар, шәригать күрсәтмәләре буенча Аллаһы Тәгалә каршына җавап бирергә барганда, мөселманнар бик тә хәвефле сынау аша үтәләр, кылдан нечкә, кылычтан үткен сират күперен кичәләр, фани дөньяда изгелек кылучылар яшен тизлегедәй аны үтеп, оҗмахка юл алалар, ә гөнаһлылар исә җәһәннәмгә ыргытылалар. Суфичылык тарикатьләренең байтагында «оҗмах-тәмуг» антиномиясе бөтенләй диярлек чагылыш тапмый, чөнки суфилар (тәсаувыфчылыкның беренче адымнарын искә алмаганда) Аллаһ җәзасы белән куркытылмыйлар. Алар үзләренең олы максатларына — Аллаһның барлыгын һәм Берлеген тануга, Аның белән рухи берләшүгә шашкын, экстатик гыйшык тоту ысулы белән якынаялар. Аллаһы Тәгаләгә экстатик мәхәббәт тоту фәлсәфәсенә нигезләнгән, хакыйкатькә ирешү юлында үзләренең аңнарына карусыз коллык, сабырлык, зөһедлек аңын сеңдергән суфи-дәрвишләр шәригать-тарикать-мәгърифәт-хакыйкать [4] дип аталган мәкамнәр — рухи яңарыш баскычлары — аша үтәләр, камил инсан булып җитешәләр. Суфи шагыйрьләр иҗатындагы Аллаһ образы куркытучы да, өркетүче дә, җәза бирүче дә түгел, Ул — «дус», «сөйгән яр», «дилбәр» (күңелләрне хушландыручы) сөекле, бөек мәрхәмәт иясе.

Галимнәр фикеренчә, мөселманнарның тәсаувыф тәгълиматына, суфичылык шигъриятенә Илаһиятне мәхәббәт ярдәмендә танып була дигән карашлар борынгы һиндлеләрнең «Бхакти», грекларның Эрос, яһүд һәм нәсариләрнең «якыныңны ярат» («возлюби ближнего») дигән дини-фәлсәфи, этик өйрәтмәләре аша үтеп кергән дип фаразлана.

Илаһият нурларына күмелгән гашыйклык юлын изге кыйбла дип тану суфичылык әдәбиятының, аеруча аның пантеистик канатының эстетик һәм этик асылын, образ-сурәтләр дөньясын бик тә үзенчәлекле итте. Суфи шагыйрьләр Аллаһы Тәгалә белән очрашу-кавышуны, аның эчендә эреп юкка чыгуны, ягъни үлемне дә шатлык, бәхет, туй куанычы итеп күзалладылар. Мондый эчтәлектә шәрехләнгән үлем фәлсәфәсе «суфи шагыйрьләрнең даһиларыннан» (Г.Рәхим) саналган Җәләледдин Руми (1207-1273) иҗатында аеруча калку чагылыш тапты. Аның өчен үлем — «яңадан туу», «туй», «кәләш белән очрашу», ягъни Аллаһ белән кавышу («Готовился ко дню смерти, как к свадьбе и называл его «Ночь невесты») [5]. Мәүлана (Руминың тәхәллүсе) үлемне бөтенләй юкка чыгу дип санамаган, бары тик яшәешнең икенче бер рәвешенә күчү дип кенә кабул иткән, «минем җеназа мәрасимендә беркем дә еламасын», — дип, васыятен әйтеп калдырган. Мәүлананың рухи җитәкчесе Сәлахеддин дә үзен соңгы юлга озатканда, күз яшьләре түкмичә, музыка белән күңел ача-ача баруларын, кабергә дә җырлый-

җырлый төшерүләрен үтенгән. Руми шәехенең теләгеен үти. Аны зиратка шөлдерләр (бубен) чылдыратып, барабаннар дөпелдәтеп, флейталарда уйнап, шигырьләр көйләп, җырлар җырлап озаталар. Рәсми дин әһелләрен ярсыткан бу «шайтан туе»ның башында яланбаш, газәлләр җырлап, биеп, «дәһри» Мәүлана-Руми үзе бара [6].

Бүген дә суфичылык тарикате белән бәйле Индонезия мөселманнары җыр-музыка белән фани җир тормышыннан бакыйлыкка күчүне дәрәҗә итеп саныйлар һәм зур чыгымнар сораган мондый йоланы үтәүгә гомер буе әзерләнәләр.

Җыр-музыка культы ярдәмендә мәңгелеккә күчү халәтен тасвирлаган әсәрләр мөселман әдәбиятларының дөньяви юнәлешендә дә еш күзгә ташлана. Мәсәлән, азәрбайҗан-фарсы Ренессанс әдәбиятлары даһие Низами Ганҗәвинең (1141-1209) «Искәндәрнамә» поэмасының төп каһарманы Александр Македонский һәм дә Сократ, Платон, Аристотель, Хормус (Гермес), Валис (Фалес), Булинос (Аполлоний Тианский) кебек атаклы философлар, ахыр чиктә әсәр авторы Низами үзе дә, үлемнәрен җыр-музыка белән каршылый. Шул ук вакытта бу образларның күбесе бәхетле елмаю белән җаннарын Аллаһы Тәгалә хозурына кайтара.

Низаминың «Хөсрәү вә Ширин» поэмасының гүзәл һәм акыллы каһарманы Ширин дә, улы Шируйә тарафыннан үтерелгән яраткан ире шаһ Хөсрәүне соңгы юлга озатканда, мәхәббәтенә тугрылык саклап, якты дөнья белән алыш-бирешен өзү турында катгый карар кабул иткәч, үлемгә туй мәҗлесенә барган кебек бизәнеп, матур күлмәкләрен киеп, күз явын алырлык колаксаларын, энҗе-мәрҗәннәрен асып, бөҗра-бөҗра итеп ясалган көдрә чәчләр дулкынын җилкәләренә таратып, сәер һәм исерек дәрвиш сыман, җырлый-җырлый биеп бара: *«Насурьмленных бровей растянутые луки, / Хной, как перед свадьбою, окрашенные руки. / Как опьянённая, сопровождала прах, / Идя с приплясхою, как будто на пирах»* [7].

Котбның нәзыйрә-поэмасында да Шириннең үлем туена чибәр килен кебек баруына, аркадан салынып төшкән «бизәкле чәчләр», кына яккан кашлар, сөрмә тарткан күзләр белән уттай янып торган кызыл якут колаксалар, яңакларга энҗе чигәчәләр асып, алтын чәчәкле ал күлмәк киеп, сары яулык бәйләп, бизәнеп-ясанып баруына басым ясала. Әмма төрки-татар шагыйренең Ширине Низами героинясыннан беркадәр аерыла да: үлемгә ул җырлап-биеп түгел, ә тәсаувыф поэзиясендә еш очраган икенче бер халәттә — «бер авып», «бер торып», күзенә сәер нурлар чыгарып, исергәндәй бара. Рухи-әхлакый кыйммәтләр күзлегеннән дә Ширин мәхәббәте югары бәяләнә. Аныңча, «бу хатынга лаек ядкәр тиеш»: *«Хатын-кыз гыйффәтендә, туй ямендә / Вә тугрылыкта үрнәк бар Ширindә»* [8].

Низаминың «Ләйлә вә Мәҗнүн» поэмасы каһарманы Ләйлә дә, сөйгәне Мәҗнүн-Кайс белән кавыша алмау хәсрәтенә түзә алмыйча, агу эчә. Кан тамчылары тамган кәфенен бизәкле туй күлмәге дип күзаллап, әнисеннән үзен җир куенына шатланып тапшыруын үтенә: *«Пусть капли крови саван окропят, / Он для меня как свадебный наряд, / Венчальную на дочь надень фату, / Невесткою под землю я сойду»* [9]. (Татьяна Стрешнева тәрҗемәсе).

Үлем — ул туй, җир тормышыннан аерылу Мәҗнүннең дә кәләше Ләйлә белән күптәннән өзелеп көтелгән шатлыклы көрешү, суфичылыкның пантеистик юнәлешләрендәгечә, җаннарның кавышу мизгеле: *«Яшь килендәй бизә дә шул туемда, / Сал мине сер яшергән җир куенына»* [10]. (Әхмәт Исхак тәрҗемәсе).

Үлемне туй образ-сурәте белән янәшә кую традициясе татар реалистик һәм романтик әдәбиятында XX гасырда да дәвам итә. Дәрдмәнднең фәлсәфи романтизмында, мәсәлән, аның «Куанды ил» шигырендә Россия җирлегендә купкан иҗтимагый-сәяси, инкыйлаби түнтәрелешләр ислам мифологиясеннән алынган образ-символлар ярдәмендә галәм киңлекләренә чыгарыла, мәләкләр шатланып кабул иткән, шайтаннар шашып, аң-таң калып төкергән «җиһан туена» әйләнә. Кияү вазифасын башкаручы лирик герой исә бу турыда икенче төрлерәк фикер йөртә. Аныңча, бу туй фаҗига белән очланачак, кияү булырга хыялланган бик күпләрне тарихи барыштан алып ташлаячак, матәм туе ясап, каберстанга озатачак *(«Житәр, җилкенмә, йолкынма, күңел син, / Кияү булсаң да, ул туйга түгел син! // Җиһан тормыш туен иткән чагында, / Синең урының үлекләр аймагында)*. Киләчәккә өметләрен өзгән авторга да бу җиһан туена ачыктан-ачык үз мөнәсәбәтен белдерү җиңел түгел, шуңа күрә ул бик тә сак: акылы (диле) аның тозаклы, авызы йозаклы.

Гаяз Исхакыйның «Дулкын эчендә» (1920) реалистик драмасындагы төп каһарман, сәүдәгәр, тол хатын Разыя үлеме дә Октябрь инкыйлабы көннәрендәге канлы вакыйгаларга бәйле рәвештә яктыртыла. Мал-мөлкәте кызыл солдатлар тарафыннан таланган Разыя, кияве атып үтерелгәч, күкрәк баласын кочып, көч-хәл белән Кырымнан Казанга кайтып егылган кызы Бануны күргәч, рухи тетрәнүләр кичерә, каты авырый башлый. Беркадәр соңрак кызының төрек әсире Фәрит белән никахлашуга ризалык бирүен белгәч тә, үлем түшәгендә яткан Разыя, экстаз халәтенә кергән суфилар кебек, кинәт сикереп торып, «зур туй» игълан итә; әйтеп бетергесез саташу катыш шатлыклы мизгелләр кичерә; үзенә киенергә ука чәчәкле күлмәген, алтын-көмеш җепләр белән үрелгән чатма камзулын, ефәк шәлен, ал хәтфә калфагын, энҗе-мәрҗәннәрен, ислемайларын китерергә, йортын яктыртырга һәм дә уенчылар чакыртып, кардәшләренә, дус-ишләренә җырлар җырлап, уйнапкөлеп күңел ачарга әмер бирә. Әмма шул мизгелдә урамдагы каты атышлар, шартлаулар гөрелтесен ишеткән, тәсаувыф әдәбиятындагыча, үлем исереклеге халәтендә булган Разыя лап итеп егыла, «үтерәләр, үтерәләр, большевиклар үтерәләр!» — дип кычкырып җан тәслим кыла.

Яңа тарихи заманда яшәгән Дәрдмәнд тә, Гаяз Исхакый да тәсаувыф фәлсәфәсенең иррациональ катламын алып ташлый, бары тик кайбер калыплашкан әдәби алымчараларны саклаган хәлдә, «үлемтуй» антитезисына инкыйлаби-сәяси, иҗтимагый-социаль эчтәлек сала, тарих сәхнәсенә аяк баскан совет тоталитар режимының үлем орлыклары чәчүен кире кага.

Урта гасыр Ренессанс һәм Яңа заман Шәрекъ, шул исәптән, татар әдәбиятында үлем фәлсәфәсен үзгәрәк этик карашлар, сәнгати чаралар ярдәмендә гәүдәләндерү дә күзәтелә. Мәсәлән, Фирдәүси, Низами, Нәвои каһарманнарының күбесе җирдәге яшәешләрен көлеп-елмаеп тәмамлыйлар. Шул ук вакытта алар суфи-дәрвишләр кебек җыр-музыка тыңлап дөнья куюдан да баш тартмыйлар. Үлемне елмаеп каршы алу — мөселман Яңарыш әдәбиятларында аеруча киң кулланылышта булган, гасырлар дәвамында заман идеологиясенә бәйле рәвештә төрле төсмерләрдә яңарып һәм кабатланып килгән мотивларның берсе. Моның сәбәбе һәм архетип вазифасын үтәгән тамырлары бик еракка — пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам биографиясенә, ул кылган гамәлләр белән бәйле хәдисләргә һәм риваятьләргә барып тоташа. Гомеренең азагы якынайган-

ны сизгән, хәлсезләнгән пәйгамбәр, авырлык белән ятагыннан торып, хатыны Гайшә яшәгән алачык өйнең ишеген ачып, якындагы мәчеткә намазга килгән мөселманнар — дуслары, фикердәшләре белән йөзенә көлемсерәү галәмәте чыгарып саубуллаша. Язучы В.В.Панова һәм аның улы Ю.Б.Вахтин бу хакта болай дип язалар: «От дверей Айши до мечети было всего метров сорок, верующие хорошо видели пророка, некоторые утверждали, что он улыбался. Постояв минуту, Мухаммед слегка помахал им рукой, дверь захлопнулась» [11].

Хәдисләрдә әйтелгәнчә, елмаеп, күз алдына нур чәчеп фәрештәләр килгәнне күреп, сөенеп мәңгелеккә күчүне мөселманнар изгелек символы итеп кабул итәләр. Җир тормышы белән елмаеп саубуллашучы каһарманнар Низаминың биш поэманы берләштергән «Хәмсә»сендә адым саен диярлек очрый.

Урта гасыр татар-болгар әдәбиятында үлемне шатланып, көлеп каршы алу мотивы Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» дастанындагы Йосыф образыннан башлана. Үтерәм дип ярсып, өстенә пычак белән ыргылган пәһлеван абыйсы Шәмгунны күргәч тә, Йосыф, борынгы грек аллалары кебек шаркылдап сардоник көлү, ягъни каһкаһә белән көлеп җибәрә. Шәмгун югалып кала, кулыннан пычагы да төшеп китә, аңа болай көлүнең яшерен бер сере бар кебек тоела: *«Шәмгун әйтте: Әй, Йосыф, син нидән көлдең, / Үткен пычак күргәме син шат булдың?»* [12].

Абыйсы Шәмгунның явыз ниятгамәленә зәһәр сардоник көлү белән «җәза бирүнең» сәбәбе — Йосыфның Яңарыш дәвере каһарманы булуда, аның кешеләр бер-берсенә карата кешелекле булырга тиеш, дигән гуманистик карашларны яклавында. Шәхсән ул үзе туганнары өчен җанын корбан итүдән һичкайчан баш тартмаячак: *«Бу тәнемдә әгәр йөз мең җаным булса, / Җөмләсен дә сезгә фида кылдым имди!»* [13].

Җиде гасыр узгач та, Кол Гали Йосыфы кебек, усал саркастик көлү аркылы явызлык белән тартышучы чын кеше — большевик Хөсен Ямашев образын шагыйрь Габдулла Тукай иҗат итә: *«Ул көрәште һәм явыз эшкә җәза бирде көлеп, / Үткен акылы шул көрәшкә пакь көмештән юл булып»* [14] («Хөрмәтле Хөсәен ядкяре», 1912).

Шигырьнең эчтәлеге, андагы байтак сурәтләр, аеруча явыз эшкә көлеп җәза бирүче Хөсәен Ямашев образы Кол Галинең гүзәллек, акыл даһие пәйгамбәр Йосыфка интертекст — аллюзия — ишарә булып тора. Кол Гали белән Тукай каһарманы арасындагы аерма тик шунда: каһкаһәле көлүе белән Йосыф туганнарына әхлакый җәза бирсә, Тукайның Ямашевы иҗтимагый явызлыкка каршы чыга, урта гасырлардагы мөселман мәгърифәтчеләре һәм яңа заманның «ислам социализмы» тарафдарлары кебек, социаль гаделлек идеалларын яклый (*«Көчле, көчсез, ярлы, бай булды һаман да бер аңар»*).

XX гасыр башындагы икенче Яңарышыбыз һәм совет хакимияте елларында елмаеп-көлеп үлүнең әдәби-эстетик һәм этик вазифасы тагы да киңәя, татар кешесенең рухи батырлыгын гәүдәләндергән символ дәрәҗәсенә күтәрелә. Милли горурлыгыбыз булган Гаяз Исхакый һәм Муса Җәлил иҗатлары моңа ачык мисал. Бу могҗиз шәхесләребезнең әсәрләрендә елмаеп, җырлап үлү мотивы патша һәм совет режимының рус булмаган милләтләрне колониаль изүен, тоталитар режимнарның ерткычлыгын, вәхшилеген фаш иткән иҗтимагыйсәяси гаепләүгә, кешелексезлеген фаш иткән сүз сәнгатенә әверелә.

Габдулла Тукайның *«Җырлыйҗырлый үләрмен мин үлгәндә дә, /…/ Җәсәдемне туфрак белән күмгәндә*

дә» шигаре («Шагыйрь») һәм дә Сибгат Хәкимнең немец рухание Георгий Юрытко белән италияле әсир Рениеро Ланфрединиләр җиткергән хәбәргә таянып, Сибгат Хәкимнең *«Без шаһит, без күрдек аларны, / Татарлар елмаеп үлделәр!»* дигән аксиологик бәяләмәсе дә Татар шагыйрьләренең рухи бөеклегенә һәм үлемсезлегенә һәйкәл булып тора [15].

Әдәбият һәм искәрмәләр

1. Ганиева Р. Ренессансные и религиозно-мистические мотивы в поэзии Мэвла Колый / Татарская литература: традиции, взаимосвязи. — Казань: Изд-во КГУ, 2002. — С.24-29.
2. Ганиева Р. Антиклерикализм и этико-эстетические идеалы Утыз Имяни / Татарская литература: традиции, взаимосвязи. — Казань: Изд-во КГУ, 2002. — С.30-53.
3. Хәбибуллин М. Түрә-бүреләр, диннәр һәм халык // Мәдәни җомга. — 2010. — 16 июль. — Б.12.
4. Суфичылык тарикатьләренең кайберләрендә рухи яңару мәкамнәре өчәү генә итеп күрсәтелә.
5. Мевляна // Заман. — 2002. — 25 октября.
6. Фиш Р.Г. Джалеледдин Руми. — М.: Наука, 1987. — С.235, 240.
7. Низами Гянджеви. Собр.соч. в пяти томах. — Т.2. — М.: Худ.лит., 1985. — С.385.
8. Котб. Хөсрәү вә Ширин. — Казан: Мәгариф, 2003. — 342 б. (Котб поэмасыннан без күзәтү ясаган бәйтләр бүгенге телебезгә профессор Рифкат Әхмәтьянов тарафыннан шактый ирекле тәрҗемә ителгәннәр).
9. Низами Гянджеви. Собр. соч. в пяти томах. — Т.3. — М.: Худ.лит., 1985. — С.282.
10. Низами Ганҗәви. Ләйлә белән Мәҗнүн. Мәхмүд Максуд тәрҗемәсе. — Казан: Татгосиздат, 1950. — 171 б.
11. Панова В.В., Вахтин Ю.Г. Жизнь Мухамеда: В двух кн. — Кн.2. — М.: ТЕРРА, 1997. — С.285.
12. Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Казан, 1983. — Б.67.
13. Шунда ук. — Б.69. (Текстны әзерләүче, бүгенге әдәби телгә уңышлы тәрҗемә итүче — Фазыл Фасеев).
14. Тукай Г. Әсәрләр. Академик басма: 6 томда. — Т.2. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2011. — 219 б.
15. Бу хакта Резеда Ганиеваның «Татарлар елмаеп үлделәр» исемле мәкаләсеннән тулырак мәгълүмат алырга мөмкин (Шәһри Казан. — 1994. — 29 сентябрь).

Ахыры алдагы санда

ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕНӘ

«Килер заман, һәр язучының үзен, сүзен вә шәхси тормышын инәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыгарлар әле».

Габдулла Тукай,
«Уянгач беренче эшем»,
1913 ел, 14 март

АРБА, ЧАНА, АТ (1909), шигырь. «Балалар күңеле» исемле җыентыкка (1909) кертелгән, кульязмасы сакланмаган. Антиномик фикерләргә корылган диалогларда арба, чана һәм ат башкара торган эшләренең авырлыгыннан зарлана. Ат фикеренчә, арба белән чана бик тә уңай һәм җайлы тормыш кичерә, ярты ел эшләсә, ярты ел ял итәләр. Крестьян хуҗалыгында бары тик ат кына рәнҗетүле, кимсетелүле тормыш кичерә. Ел дәвамында карусыз авыр хезмәт башкарган атның гына, чын мәгънәсендә, зарланырга хакы бар. Атның зары шигырьдә мәгънәви нәтиҗә — төп идея буларак түбәндәгечә яңгырый: *«Күпме зарлансам, урын бар, мин каты мәзлум менә; / Хәл җыймыйм ел тәүлегендә, ичмасам, бер көн генә!»*

Күренә ки, шигырь тәрбияви эчтәлекле. Шул ук вакытта ул яшь буынны дөньяны танып белүгә, ел фасылларына бәйле рәвештә, авыл кешесенең яшәү рәвеше (йөк аты, эш кораллары) белән таныштыруга да хезмәт итә. Арба, чана, ат образларының җанландырылып, кешеләштерелеп бирелүе шигырьне психологик башлангыч белән дә баета. Шигырьнең сюжетын Тукай рус әдәбияты аша кабул иткән, нәзыйрә рәвешендә иҗади эшкәрткән дип фаразларга мөмкин. Мондый ихтималның барлыгын күздә тоткан хәлдә, «Арба, Чана, Ат» шигыренең шәрекъ әдәбиятлары өчен хас әдәби традицияләр һәм алымнар белән берегеп бирелүен дә истән чыгармаска тиешбез. Беренчедән, шигырь Урта гасыр һәм Яңа заман шәрекъ

әдәбиятларында киң таралыш алган зарлар — шикаятьнамәләр жанрында иҗат ителгән, икенчедән, ул мәснәви жанрындагы бәйтләр кебек моноримга — парлы рифмага (аа бб вв...) корылган.

Чыганак
Тукай Г. Әсәрләр: 5 томда. — II том. — Б.85.

Әдәбият
Габдулла Тукай. Материалы научной конференции. — 1968. — С.110; Габдулла Тукай. Материалы научной конференции. — 1979. — С.182.

САТАШКАН (1908), шигырь. Әсәр — гыйсъянчылык романтизмы вәкиле С.Рәмиевнең «Алданган» һәм «Кайвакыт уйлыймын мин» шигырьләренә фарс-пародия. Реакция еллары башлангач та, Беренче рус революциясе дәверендәге шәхес азатлыгы, милли тәрәккыят турындагы идеалларның тормышка ашмавы С.Рәмиевне кара кайгыга батыра. Әле күптән түгел генә «шәп шылтырап аккан судай шат көннәренең» кабердәй караңгы төннәр белән алмашынуын иҗтимагый һәм рухи яшәештә алдану, тәмугка ыргытылу, утта яну кебек хис итүгә этәрә; замандашларының кешелексезлеге — еландай агулы тешләре белән күңелне тырнавы, тәмсез ачулы сүзләр, «ямьсез тутыккан күзләр белән кычкырулары» җир йөзендә бернинди хаклык та, хакыйкать тә юк икән, дигән нәтиҗәгә китерә. Шул сәбәпле, «Алданган» шигыренең лирик герое, борынгы грекларның акыл иясе Әфләтүнчә (Платон), атаклы немец философы Шопенгауэрча, галәмнең, җир-күкләрнең, кояш белән айның, табигатьнең, кешеләрнең юклыгына, аларның бары тик «күләгә», «идея», «шәүлә» булуына ышана башлый; «беттем, төштем, үлде рухым» дип, универсаль төшенкелек дәрьясына бата һәм ахыр чиктә, гыйсъянчыларча «каш җыерып», «әрни-әрни ләгънәт әйтәм тискәре бу дөньяга» дип, каргышлы сүзләр яудырырга тотына. Дөньяның барлыгын танымау, бары тик үз шәхесен, үз «минен» генә алга чыгару, ягъни солипсизм Тукайның исен китәрә, гаҗәпләндерә, дусты С.Рәмиевне логик фикерләү сәләтен югалткан «бүрке үлмеш теп-тере» «мәҗнүн» дип атарга мәҗбүр итә.

Тукай С.Рәмиевнең «Кайвакытта уйлыймын мин...» шигырендәге җир гүзәлләренә шашкын мәхәббәттән күкләргә ашкан, аларны Аллаһ (Алиһә) дәрәҗәсенә күтәргән лирик героен да көлке объекты итә. Шул рәвешчә, Тукай каләмдәшенең үтә дә субъективлыкка, индивидуализмга бирелеп, Әфләтүн белән Шопенгауэр фәлсәфәләре чытырманлыклары арасына кереп адашуын да, Шәрекъ Яңарыш шагыйрьләре кебек, сөйгән ярларны романтикларча илаһилаштыруын да, «Син генә рух биргән Аллам» дип гайре табигый күтәренкелек белән мәдех укуын да саташу дип кабул итә; хыял канатларына утырып, күкләрдә очып йөрүче шагыйрьне җиргә тартып төшерә һәм аны гап-гади көндәлек тормыш мәшәкатьләре белән шөгыльләнергә мәҗбүр итә (тишек капчыкларны ямата, сачтарашка йөрттерә, пилмән, токмач ашата...). Пародиядә Тукай көлке эстетик категориясенең барлык төрләренә — ирония, юмор, сатира һ.б. мөрәҗәгать итә. Көлкеле халәт тудыруда ул цитаталар, реминисценцияләр, аллюзияләр рәвешендә бирелгән интертекстуальлектән — әңгәмәдәшлектән уңышлы файдалана. Ахыр чиктә, Тукай белән Рәмиев әсәрләреннән алынган өзекләр, тәгъбирләр, ишарә сүзләр бергә буташтырылып, үзара керешеп, бәхәскә, абсурдка, парадокска корылган, фарс стиленә тартым

Сәхифәне филология фәннәре докторы **ЗӨФӘР РӘМИЕВ** алып бара.

көлке эчтәлекле пародия иҗат итеәлә. «Шүрәле», «Су анасы» поэмаларыннан алынган цитаталар ярдәмендә шигырьдәге комизм тагы да көчәйтелә («Ник аласың син аны, ул бит минем алтын тарак!», «Яп-ялангач, бик киенгән һәм кеше төсле үзе»). С.Рәмиевнең Шопенгауэр рухында галәмнең барлыгын танымыйча: *«Юктыр, әлбәттә, кояш та, / Ул дадыр хәйлә генә, / Юктыр ай да, галәм дә, / Барсы да шәүлә генә»*, дип раславын Тукай интертекстуаль алымнар ярдәмендә һәм үзеннән дә түбән стильгә караган образ-сурәтләр, детальләр өстәп, тузга язмаган саташу дип тамгалый: *«Юк бу дөнья, каплаган күк, юк бу җирләр берсе дә, / Юк чебиләр, юк песиләр, «пес-пес»е юк, «перс»е дә. / Юктыр, әлбәттә, боламык — ул дадыр әлбә генә; / Юк тарантас, юк карета — барсы да арба гына».* «Кайвакытта уйлыймын мин…» шигырен пародияләштергәндә дә Тукай Рәмиевнең дөньяга карашларын һәм сәнгатьчә фикерләвен абсурдлыкка нигезләнгән көлкеле бәйләнешкә кертә, пантеистик суфичылык шигъриятендәгечә, хатын-кызларны «рух бирүче Аллам» дип, илаһи символга әверелдереп, күкләргә күтәрүгә дә каршы чыга. Рәмиевтәге: *«Син» генә бар күккә патша, / Аш! — диген, күккә ашыйм! / «Син» генә рух биргән Аллам, / «Син яшә! Һәм «мин» яшим»*, дигән дүртьюллык строфа, «Таң вакыты» шигыреннән алынган «шашу» реминисценциясе ярдәмендә тагы да көчәйтелеп, мыскыллы ирония рәвешен ала: *«Син генә бар күккә патша; мин тагын токмач та ашыйм, / Син яшә, һәм мин яшим; әйт: шаш диген, тагын шашыйм!»* Шул рәвешчә, Тукай Рәмиевнең Әфләтүн һәм Шопенгауэр карашлары йогынтысында чынбарлык ул — томан пәрдәсе артына яшеренгән «күләгә», «шәүлә», «күзаллау», җир тормышында бернинди хакыйкать юк, яшәеш — кайгы-хәсрәт чыганагы дигән төшенкелек фәлсәфәсе белән дә килешеп бетми; Шәрекъ Ренессанс әдәбиятларындагыча, хатын-кызларны кирәгеннән артык идеаллаштырып, илаһият баскычларына күтәрүне дә мәгъкуль күрми. Рәмиевнең мондый карашларына җавап рәвешендә Тукай янә бер әсәр — Лермонтовның «К. (Я не унижусь пред тобою…)» шигыренә «Алдандым» нәзыйрәсен яза. Аның исеме үк һәм дә шигырь тукымасына «саташкан» сүзенең кертеп җибәрелүе шулай ук каләмдәшенең «Алданган» шигыренә аллюзия-ишарә икәнлеген расласа кирәк. Лермонтов шигыре белән С.Рәмиев тә таныш булган. Аның «Алдандым» нәзыйрәсе белән ул иң элек дусты С.Рәмиевкә шагыйрьнең вазифасы нидән гыйбарәт булырга тиеш дигән сорауга җавап бирә. Аныңча, шагыйрь сөйгән яр дип, мәхәббәт дип «мәгънәсез аһлар» белән күккә ашып йөргәнче, иң элек милләт хадиме булырга, шигърияте белән халкының рухын тәрбияләргә тиеш. Шул очракта гына милләт аны кыямәт көнгә кадәр телгә алачак һәм олылаячак *(«Җисменә җан өрсәм, үтермәс иде милләт мине; / Та кыямәт зикридәрди, бәлки, тәгъзимләп мине»)*.

Чыганак
Тукай Г. Әсәрләр. Академик басма: 6 томда. — Т.1. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2011. — Б.231, 238, 363, 366.

Әдәбият
Гали М. Сәгыйть Рәмиевнең иҗат һәм тормыш юлы // Совет әдәбияты. — 1940. — №4. — Б.79-80.

Резеда Ганиева,
филология фәннәре докторы

БАТЫРША

ФӘҮЗИЯ БӘЙРӘМОВА,
язучы, Г.Исхакый исемендәге премия лауреаты,
тарих фәннәре кандидаты

Татарларның йөрәк-бәгырьләренә төшкән рус патшабикәсе Анна Ивановна 1740 елның 17 октябрендә 47 яшендә кинәт кенә үлеп китә. Ул Россиянең тоташ христиан иле булуын күреп өлгерми, әмма үзенең соңгы сүзен, васыятен әйтеп калдыра — рус булмаган халыкларның барысын да чукындырырга, чукындырырга һәм чукындырырга, нәтиҗәдә, алардан рус ясарга. Бу патшабикә үлгәч тә, аның татарларны көчләп чукындыру турындагы указ-әмерләре бөтен көченә эшләвен дәвам итә, татарларның мәчетләрен җимерәләр, авылларын яндыралар, үзләрен төрмәләрдә черетәләр...

1741 елның 25 ноябрендә Россия тәхетенә Пётр патшаның сөекле кызы Елизавета Петровна утыра. 20 ел ил белән идарә итәчәк бу хатын Батыршаның язмышында да үзенең канлы эзен калдыра. Төрле интригалар белән хакимияткә килгән әлеге патшабикә дә мөселманнарга каршы ярсып көрәшүен дәвам итә. Үзенең беренче эше итеп 1742 елның 6 апрелендә ул гаскәргә алынган бөтен татарларны, калмык, чуваш, мордва һәм рус булмаган башка халыкларны православие диненә күчерү турында указ чыгара. 10-12 яшьтән рекрутка алынган татар малайлары да, рус армиясендә 25 ел хезмәт итәргә мәҗбүр булган татар ир-атлары да патшабикә әмере белән чукындырылырга һәм шунда мәңгегә калырга тиеш булалар.

Яңа патшабикә Елизавета Петровна хуплавы белән 1742 елның 19 ноябрендә Сенат ислам диненә каршы коточкыч указ чыгара. Ул «О недопущении в Казанской губернии строить мечети, и о разведывании губернаторам и воеводам об обращённых в магометанский закон» дип атала. Шушы вәхши фәрман нигезендә татарларның бөтен мәчетләре юк ителергә һәм яңалары төзелмәскә тиеш була. Россиягә яңа патша килү белән, татарларны көчләп чукындыруның яңа чоры башлана... Шушы указ нигезендә Казан губернасында 536 мәчетнең 418е юк ителә, Себердә 133 мәчетнең 98е яндырыла, Әстерхан губернасында 40 мәчетнең 25е җимертелә, Казан һәм Оренбург

*Дәвамы. Башы журналның 2012 елгы 10-11, 12 нче саннарында.

губерналарында гына да 270 мең кеше көчләп чукындырыла. Әле бу рәсми рус тарихында теркәлеп калганнары гына, ә теркәлмәгән вәхшилек күпме булган?!

Әлбәттә, Батырша хәзрәт боларның барысын да белгән, күргән, бу канлы вакыйгаларның тере шаһиты булган, чөнки бу фаҗигаләр барысы да ул яшәгән һәм эшләгән төбәкләрдә — Казан һәм Оренбург губерналарында, татар җирләрендә барган. Эчендә җаны булган, милләтенең язмышы өчен ут йоткан, үз балалары, нәселе өчен кайгырган, көрәшмәсәң, диннең бетәсен аңлаган кеше, дин әһеле бу очракта ни эшләргә тиеш? Әлбәттә, кул астында булган бөтен чаралар белән бу гаделсезлеккә каршы күтәрелергә тиеш. Һәм Батырша хәзрәт шулай эшли дә — мөселманнарны, Идел-Уралда яшәүче татар-башкортларны рус басып алучыларына каршы изге сугышка — җиһадка чакырып мөрәҗәгать ясый, халыкны дин, милләт, дәүләт өчен көрәшкә күтәрә.

Озак еллар буе халыктан яшерелгән, патша заманында да, совет чорында да телгә алынмаган яки тискәре яктан гына әйтеп үтелгән бер язма бар, ул — Батырша хәзрәтнең халыкка өндәмәсе. Казан алынып, бәйсез татар тормышы тар-мар ителгәннән соң, Батырша хәзрәт беренче тапкыр азатлык өчен көрәш программасы белән чыга, аны язма рәвештә халыкка тарату юлларын таба. Кайбер галимнәрнең (Г.Хөсәенов) әйтүе буенча, бу өндәмә («Тәхризнамә») 1755 елның март-май айларында язылган, кайберәүләр (М.Гайнетдин) аны май аенда язылган, дип бара. Өндәмә дүрт юл халкына — Себер, Нугай, Уса, Казан юлларында яшәүче мөселманнарга, татар-башкортларга адреслана, Батыршаның шәкертләре тарафыннан күпләп күчереп язылып, шунда таратыла. Соңыннан, инде кулга алынганнан соң, патшабикәгә язган хатыннан күренгәнчә, Батырша хәзрәт үзе дә бу чорда халык арасыннан кайтып керми, мөселманнарны рухи яктан бу изге көрәшкә әзерли. Бу чорда ул шәхес буларак шушы өндәмәне язарга җитлеккән һәм яу башына басарга әзер кеше була.

Бүгенге көндә бу өндәмә Мәскәүдә, Борынгы актлар дәүләт архивында (РГАДА) саклана, аны шул вакытта ук русчага тәрҗемә итеп, Петербургка җибәргән булалар. (РГАДА, ф.7, д.1781, ч.4, 367-374 л.) Батыршаны хөкем иткәндә шушы өндәмә аңа каршы төп дәлил булып тора, татар мулласы халыкны патшага каршы баш күтәрергә өндәүче дәүләт җинаятьчесе буларак хөкем ителә. Батырша мулланың халыкка өндәмәсе — чын мәгънәсендә, татарның югалган дәүләтен торгызу өчен, басып алучы русларга каршы бәйсезлек программасы, изге сугышка чакыру ул. Шушы дәһшәтле фикер өндәмәнең буеннан-буена утлы тамга булып сузылган, шуңа күрә ул элек тә, хәзер дә күп сәясәтче, галимнәрне куркыткан, аны әйләнеп үтәргә мәҗбүр иткән. Әмма шушы өндәмәне яхшылап өйрәнми торып, без Батырша явына, ул яшәгән чорга, ул күтәргән мәсьәләләргә тулы җавап бирә алмабыз. Чөнки Батырша явы шушы өндәмәдән башланган, ислам дине җитәкчесе шушы өндәмәсе белән мөселманнарны кяферләргә каршы изге сугышка чакырган һәм шушы өндәмәсе өчен Батырша хәзрәт мәңгелеккә империя төрмәсенә ябылган, шуннан үлемсезлеккә, мәңгелек җәннәткә юл алган...

«Әй, рус вилаятендә торгучы ислам әһелләре вә әй, кяфер вә залим русның хур вә җәфасыннан, вә мәкер вә хәйләсендин бичара һәм битакәт (тәкатьсез) булып, рузкар (тормыш) кичергүче иман әһелләре, белегез һәм әгъла (аң) булыгыз!» — дип башлап китә ул өндәмәнең беренче юлларыннан ук. Өндәмә башыннан алып ахырына кадәр русларның мәкерле басып

алу сәясәтен ачып бирүгә багышланган.

Батырша хәзрәт бу өндәмәсендә зур дин белгече һәм өлгергән милли сәясәтче буларак чыгыш ясый, ул шулай ук көчле психолог һәм хәрби оештыручы-яубашы буларак та ачыла. Әмма, иң беренче чиратта — ул ислам дине әһеле һәм ул халыкка сүзен шәригатькә таянып аңлата. Мөселманнарны дин һәм ирек өчен изге сугышка чакырганчы, ул иң беренче эш итеп аларның шушы авыр хәлдә калу сәбәпләрен аңлатып бирә. Ягъни русларның татарларга күрсәткән бу хәсрәтләрендә мөселманнарның үзләрендә дә гаеп булуын, җирле халыкның басып алучылар белән артык якынаеп китүен, аларча кылануларын, русларга теләсә нәрсә эшләп йөрергә ирек бирүләрен гаепләп чыга. Батырша бу урында үзләрен мөселман дип атаучы Идел-Урал халыклары тормышына, аларның яшәү рәвешенә җентекле бәя бирә, ялгышларын төртеп күрсәтә. «Кяфер рус тарафыннан моның кадәр хәсрәт һәм бәхетсезлекләр белән бәлаләндерелүебез — үзебезнең ислам кушканча яшәмичә, бозык һәм ялган, яман хәлләр кылуыбыз шомлыгыннандыр, — дип яза Батырша хәзрәт ачынып. — Ата-бабаларыбыз һәм дин кардәшләребез борын заманда гадәт иткән ислам кагыйдәләрен һәм расүлебез әйткәннәрне читкә куеп, бизарурәт кяфер һәм залим руска баш куеп, үзләребез бер-беребезне мәкер вә хәйлә илә вә үзара ызгыштырып-талаштырып, шул рәвешле кяфер руска итагать кылдырып, кяфернең кулын күтәреп, ул кяфернең динен котландырмакка (көчәйтергә) сәбәпче булып, ислам динен вә ислам әһелен хур вә зәгыйфь тотуга сәбәпче булды».

Батырша хәзрәт өндәмәсенең башында ук чын мөселманның мондый булмаска тиешлеген аңлата. Чөнки мондый халык белән коллыктан котылып булмаслыгын ул яхшы аңлый. Һәм аларга үрнәк итеп, ул болгари мөселманнарның, ягъни татарларның, кяфер русларга каршы киңәштә һәм берлектә булуларын, аларга каршы батырларча сугышуларын аңлата. «Алар Аллаһы Тәгаләдән истиганәт алып, пәйгамбәребез Мөхәммәт салаллаһу галәйһиссәламне шәфәгатьче китереп, яу кораллары белән ярагланып (коралланып), газилек атларына менеп, ул мордар кяферләрнең өсләренә сикереп, аларны дәфег кылалар (кыралар) иде. Вә күп кяферләрне кылыч вә сөңгедән кичереп, җаннарын җәһәннәмгә җибәрәләр иде», — дип яза ул, татарның узган бөек тарихын искә алып.

Халыкның шулай акрынлап рус кул астына керә баруында Батырша мулла милләтнең җитәкчеләрен, байларын һәм хакимият куйган старшиналарын гаепли. Бигрәк тә бу якларда Оренбург кәлгәсе салынганнан соң, мөселман дип аталган халыклар арасында күпме фетнәләр килеп чыкканлыгын фактлар белән ачып күрсәтә. «Мөселман дип аталган таифәләрнең бәгъзеләре, кяфер рус белән бер күңелле (бер уйда) булып, вә кяфернең гаскәрләрен үз өсләренә алып, пакь динле ислами халыкларны, ягъни, кяфер руска итагать итмәгән, борынгы ата-бабаларыбызның яхшы кагыйдә белән йорт тотмакта һиммәт иткән мөселманнарны чабып, малларын алып, угыл-кызларын бәндә вә әсир кылып, кяфергә саттылар», — дип яза Батырша хәзрәт, әрнеп.

Бу яман эштә ул бигрәк тә старшина дип аталган бәгъзе монафикъларны каты тәнкыйть уты астына ала, аларны руска сатылуда гаепли, «кяфер русларга аркаланып, мөселманнар белән киңәш итәр чакта, алар белән киңәшмиләр, ул мөселманарга тәкать һәм мөмкинлекләр бирмичә, кяферләрнең салымнарын һәм җәфаларын кабул итеп, мөселманнарның үзләренә йөклиләр», — ди. Ул гына да түгел, кяферләргә тиешле җавап бирергә җыенган

мөселманнарны бу старшиналар руслар кулына тотып биреп, «җәбер вә каһәр күрсәтеп, хур вә һәлакәтле кылдылар», — ди.

Батырша хәзрәт алга таба халык арасындагы бу сатлык җаннарның милләткә нинди зур зыян саласыларын яхшы аңлый һәм иң башта аларга каршы көрәш ачарга чакыра. Ул кяферләрчә эш йөрткән, кяферләргә ышанган монафикъларны старшина итеп куймаска өнди, алар каршына бармаска, аларга буйсынмаска чакыра. «Бәс, ни хәер вә ни бәрәкәт булыр шул кавемнәргә, кем, үз араларында бер күңелле (бер уйда-фикердә) булмыйча, бер-беренең һәлакәтенә сәбәпче булырлар? — дип дәвам итә Батырша хәзрәт үзенең өндәмәсен. — Вә ни истирахәт (тынычлык) вә ни иркенлек хасил булыр шул кавемнәргә, кем кяфер риялы вә кяфер игътикадлы монафикъларны баш вә старшина итеп, ислам шәригатен һәм хөкем иясе галимнәрне куеп, ул монафикъ надан старшиналарның алдына барып, алардан хөкем өстәрләр (күтәрләр)? Ул монафикълар батил (бозык) хөкемнәрне хак санап, хәрам мал җыярлар яки кешенең хәләл хакын бирмәс булырлар».

Һәм шушы аңлатулардан соң, Батырша мулла халыкны тәүбәгә килергә чакыра, мондый яман эшләрдән баш тартырга өнди. Чөнки рус белән бер фикердә торып, аларга каршы изге сугышка чыгып булмаячагын ул яхшы аңлый. Халыкны рус тормышыннан һәм тәэсиреннән аерып алу өчен, өндәмәсендә мөселманнар алдына конкрет таләп һәм бурычлар куя. Беренчедән, руслар белән бер уй-теләктә булмаска; икенчедән, алар белән берләшеп, мөселманнарның канын коймаска, малларын тартып алмаска, әсир итмәскә; өченчедән, русларга башлар һәм маллар белән хезмәт итмәскә, гаскәрендә катнашмаска; дүртенчедән, кяфернең кәлгәләрен һәм ныгытмаларын төземәскә; бишенчедән, ат-олаулар белән аларны илдән-илгә, кәлгәдән-кәлгәгә йөртмәскә; алтынчыдан, аларга ясак һәм фураж салымнары бирүне туктатырга. Ягъни, Идел-Урал арасына үтеп кергән русларга бөтен яктан да бойкот игълан итәргә, буйсынмаска, аларга каршы көрәш башларга дигән сүз.

Әмма бу әле Батырша хәзрәт куйган таләпләрнең башы гына, төп сүзне әйтергә, төп эшне эшләргә әзерлек кенә. Яубашы-имамның милләт алдына куйган иң зур бурычы — кяфер рус басып алган җир-суларны яңадан кире кайтару, югалган татар дәүләтен яңадан торгызу була. Моның өчен ул ата-бабалар җирендә кяферләргә юл куюны туктатырга кирәклеген әйтә, аларга монда кәлгәләр һәм крепостьлар, заводлар төзергә ирек бирмәскә, бер эштә дә кяферләргә ярдәмче булмаска кирәклеген аңлата.

«Үткән заманда кяфер руска итагать вә инкияд (ышанып) кылып, ислам әһеленә вә ислам диненә ни зарарлар вә ни фетнәләр ирештергән идек, — дип яза Батырша хәзрәт үзенең өндәмәсендә. — Шул эшләребезгә үкенеп, аларны башка кабатламыйк, Аллаһтан гафу үтеник һәм ярлыкавын сорыйк. Вә киләчәк заманда ул кяферগә итагать һәм буйсыну кылмыйк! Вә киләчәк заманда ул кяфергә буйсынмаска, ул кушканны эшләмәскә ант бирик! Ислам әһленә вә ислам диненә зарар итәрдәй эшләрдән тыелырга ант итик! Шулай үткән елларда башларыбыз вә малларыбыз белән, вә җирләребез вә йортларыбыз илә ул кяфергә күптөрле хезмәтләр итеп, күп-күп рәнҗүләр вә михнәтләр күреп, күп гәм һәм газаплар чиккән идек. Инде ошбу вакытта дин ислам хакында вә әһле ислам хезмәтендә җаннарыбызны һәм башларыбызны вә милекләребезне фида кылыйк».

Хак мөселман буларак, Батырша мулла үзенең әйткәннәрен Коръән

аятьләре һәм хәдисләр белән дәлилли бара, аның өндәмәсе милләт тормышыннан мисалларга да бай. Катлаулы нәрсәләр турында язса да, теле гади, халыкка аңлаешлы, ул чордагы сөйләм теленә якын. Шул ук вакытта өндәмәдә җирле мишәр сүзләре дә мул кулланылган, шигъри-чичәнлек алымнары да күренә. Өндәмәнең иң кискен өлешендә — халыкны русларга каршы изге сугышка чакырган урында Батырша мулла кискен һәм кыска җөмләләргә күчә, аның һәр сүзе кяферләрнең баш өстендә камчы булып уйный.

«Әй, дөрес игътикадлы, пакь динле мөэминнәр, катланыгыз (берләшегез)! Берләшегез! Берләшегез! — дип яза ул. — Газилык атларыгызны һәм коралларыгызны яраклагыз (әзерләгез)! Ук, кылыч, сөңге һәм ни кирәк — хәлегез кадәренчә хәзерләнегез! Аллаһы Тәгаләнең әмеренә итагать итеп һәм ияреп, пәйгамбәребез Мөхәммәт саллаллаһу галәйһиссәламне шәфиг китереп, ул кяфер русны чабаек һәм аларны җиребездән дәфег итик (куып чыгарыйк)! Ил-йортыбызда мәчетләр вә мәдрәсәләр бина кылыйк! Вә динебезне, ислам динен куәтләндермәккә һиммәт кылыйк!»

Батырша хәзрәтнең бу чакыруы Казан җимерелгәннән бирле рус коллыгында яшәргә мәҗбүр татарларның иң зур хыялы була. Бу хакта үзенең Батырша хәзрәт Казан губернасында, Казан, Сембер, Зөя өязләрендә көчләп чукындырылган мөселманнарның тилмереп үзләрен коткаруларын көтеп торулары турында яза:

«Шуларның бәгъзеләре, күңелләрендә иман булганнары, ни заман ислам әһелләре кяфергә каршы кул күтәрер икән дип зарыгып көтеп торалар, — дип яза ул. — Ислам хакына баш вә җан фида кылыр идек дип, хур вә зар булып торгучы мескеннәрнең иреге өчен дә тырышыйк! Әй, мөэминнәр вә әй, динне кайгыртучылар! Безләргә һичбер мөселманыбызны ялгыз ташлап, кяфердән хур иттермәк дөрес түгелдер! Әй, мөселманнар, фәһем кылыгыз шуны: кяферне ирек куеп, мөселманнарыбызны ялгыз ярдәмчесез ташлаганнан, күпме кеше хур булып яши һәм һәлак була?»

Батырша хәзрәт шулай кыю рәвештә басып алучыларның чын йөзен халыкка ачып бирә. Ул мөселманнарны аларга ышанмаска өнди, кяферләрдән яхшылык көтүнең мәгънәсезлек икәнлеген аңлата. Кяферләр кул астында калган халыкларның үткәндәге һәм бүгенге тормышларыннан аянычлы мисаллар китереп, киләчәктә алардан сак булырга чакыра: «Инде ул кяфердән көн элгәре (киләчәктә) яхшылыкмы көтәсез? — дип туп-туры сорый ул халыктан. — Динебезнең соруры пәйгамбәребез Мөхәммәт галәйһиссәламне дошман тоткан кяфер ахыр безгәме дуслык кылыр? Шәһәребез мәгъмур Болгарны харап кылып, мөселманнарны таркаткан кяфер вә мәчетләребезне харап кылган, үзенең батыл (бозык, ялган) динен әкраһ кылган (куралмау уяткан) кяфер ахыр авылларыбызны мәгъмур вә бәннад куяр, ягъни куәтләндерергәме ирек куяр? Вә ахыр мәчетләребезнең мәгъмуриятенә вә дин исламның тәкуйәтенәме, ягъни, ныгуынамы сәбәпче булыр?»

Юк, әлбәттә, Батырша хәзрәт дөрес яза, кяферләр татарның җәннәттәй җирләрен ислам динен ныгыту, үзләре җимергән Шәһри Болгарны яңадан торгызу өчен басып алмадылар... Ул гына да түгел, Идел-Урал аларга Урта Азия, казах далаларын басып алу өчен бер күпер, плацдарм ролен үтәргә тиеш була. Татарның акыл иясе Батырша хәзрәт моның шулай икәнлеген яхшы аңлый, халыкны бу хакта каткат кисәтә. Ул Россия империясенең мәкерле геополитик максатларын ачып бирә, рус тарафыннан кыргыз-казахка киләсе бәлаләр турында кисәтә. Россия империясенең төп максаты — кыргыз-

казахны кайда куркытып, кайда сатып алып, мәңгелеккә үзләренә буйсындыру икәнлеген Батырша хәзрәт үз өндәмәсендә бик яхшы аңлата. Мондый фаҗигале хәлләрнең Казан һәм Болгар тарихында инде булганлыгын тагы бер тапкыр искә төшерә. Ул гына да түгел, кяферләрнең төрки-мөселман дала халкын Идел-Уралдагы төрки-мөселман халыклары белән бәрелештерергә, дошманлаштырырга җыенуларын Батырша саллы дәлилләр белән исбатлап бирә.

«Вә дәхи мөэминнәр, вә әй, мәүхидләр, тагы аң булыгыз! — дип яза Батырша хәзрәт. — Ул кяфер руслар төрле хәйлә вә алдау белән вә күп-күп бүләк, мал биреп, кыргыз-казахны алдап, алардан Әбүлхәер ханның улын берничә хәдимәләре (хезмәтчеләре) белән вәсикә алды, ягъни, әманәт (тотык) итте Ырымбурх кәлгәсенә. Моның максаты шулдыр: аларны тәмам үзенә буйсындырып, көннән-көн аларның арасына кереп, җирләренә кәлгәләр вә крепостьлар төзеп, аларны мәкрүх вә мәгълүб кылмак телидер, ягъни, җиңеп, аста калдырырга телидер, Уфа өязе халкына шундый эш кылган кебек».

Батырша хәзрәт шундый ук фаҗиганең тиздән Урта Азия җирләренә — Ташкент һәм Бохарага да килеп җитү мөмкинлеген кисәтә, руслар аларны да баш идерергә һәм таркатырга телиләр, ди... Һәм бу нәкъ шулай булып чыга да — Казан артыннан Урал китә, Себер китә, Россия империясе татарларның үле гәүдәләре аша Урта Азиягә юл сала, аларны басып ала... «Ул кяфер русның максаты улдыр — әгәр хәле җитсә, бер заманның эчендә үк рус вилаятендә торгучы мөселманнарның өстенә тәкатьсез авыр салымнар салып, аларны гаҗиз итеп, үзенең батил диненә җәбер һәм каһәр белән көчләп кертер иде, — дип кисәтә бу хакта Батырша хәзрәт. — Бәлки бер көн эчендә үк. Ләкин ул кяфернең хәле җитмәйдер, берьюлы ук тизлек белән аны кылырга».

Һәм бу урында Батырша хәзрәт русларның йомшак якларын, аларның нидән куркуларын халыкка ачып сала. Руслар мөселманнарның, берләшеп, үз хокукларын яклый башлауларыннан куркалар икән, Идел-Урал халкының казах-кыргыз белән берләшеп, русларны биредән куа башлауларыннан, рус йортын харап итүләреннән куркалар икән... Аларны тирә-яктагы мөселман илләреннән, кала һәм салаларыннан гаскәр һәм ярдәм сорарлар дип хәвефләнәләр икән... «Узган елда ул кяфергә шул хәвеф төште, — дип яза Батырша хәзрәт. — Ягъни дүрт юл халкы мөселманнарының яшерен вә яшереп үз араларында кяфер русның өстенә атланып чапмакка киңәш итәчәкләрен вә һәм кыргыз-казахы белән хәбәрләшеп, берекмәккә киңәш итәчәкләрен ул кяфер рус аңлады». Шуңа күрә, өндәмәдән күренгәнчә, җирле халыкларга ясакларны киметкән булып уйныйлар, аерым кешеләрне, старшиналарны сатып алалар икән... Батырша хәзрәтнең хаклы рәвештә кисәтүенчә, болар барысы да мөселманнарны патшаның яхшылыгына ышандыру һәм аларны яу белән кузгалмасыннар өчен эшләнә икән.

«Күп аңсызлар, ягъни кыска фәһемле кемсәләр (кешеләр) кяфернең бу хәйләсенә алданалар, — дип дәвам итә Батырша хәзрәт үзенең өндәмәсен. — Әмма зирәк һәм үткен акыллы кемсәләр алданмыйлар, бәлки кяфернең бу рәсемле (рәвешле) күп хәйлә вә алдау кылуы сәбәпле, гаять гарьләнеп, ачуларыннан вә гиззәтләреннән ул кяфернең итенә ачыгып, канына сусыйлар. Чөнки беләләр: ул кяфер, гәрчә бу әйтелгән рәвешчә хәвефкә төшсә дә, үзенең сүзен вә ирадәсен (ниятен) җиренә җиткерде».

Өндәмәнең бу урынында Батырша хәзрәт җирле халыкның теңкәсенә тигән тоз мәсьәләсен дә күтәреп чыга. Элек

халык тозны таулардан һәм күлләрдән бушка алса, хәзер акча түләп, руслардан алырга тиеш була. Шуның өчен ясакларыгызны киметәбез, дип алдап, халыктан кул куйдырганнар. «Бу эшнең соңыннан шул мәгълүм булды, — дип яза Батырша хәзрәт, — рахмани хәзинәдән, таулардан вә күлләрдән тоз алмак вә җирләребезне вә суларыбызны әүвәлге кагыйдәбезчә биләмәк кулыбыздан китте. Моннан соң җиребезгә вә суыбызга ябышырга вә тотынырга дәлилебез вә җавабыбыз калмады».

Идел-Урал арасында яшәүче мөселманнарның бөтен яктан да рус җәберенә дучар булуларын исбат иткәч, Батырша хәзрәт тагы сәясихәрби мәсьәләләргә күчә. Билгеле булганча, мөселман кешесе буларак аны иң борчыганы — русларның аларны башка мөселманнарга каршы сугышта файдаланулары, казах-кыргыз белән яу кырында бәрелештерүләре. «Вә дәхи аң булыгыз, — дип яза Батырша хәзрәт, — кяфер рус телидер ләшкәр (гаскәр) җибәрергә, безләрне рус белән бергә кыргыз-казахның өстенә чабарга, ясак бирмәгән вә багынмаганлыклары өчен, ягъни буйсынмаганнары өчен. Моның максаты шул: аларны үзләренә буйсындырып, безләрне уртада калдырып, көннәнкөн безләргә камәллек белән фетнә вә җәфа ирештермәккә. Ягъни ул казах таифәсе белән ирләрне орыштырып, каннарыбызны түктереп, киләчәктә ул таифә белән безнең арабыздан солыхны вә татулыкны кидермәктер, ягъни бетерергә телиләр. Вә арабызда фетнәләр чыгарып, ул таифә белән бер-беребезгә ышанычыбызны вә таянычыбызны бетерергә телиләр».

Батырша хәзрәт русларны хәзергә бары тик мөселманнарның берләшү куркынычы гына тотып тора, ди, «шуңа күрә ул кяфер шикләнеп һәм төрле ягын уйлап, мәкерле хәйләләрен дәвам итә», — дип яза Батырша хәзрәт үзенең өндәмәсендә. Һәм Батырша хәзрәт русларны иң нык куркыткан гамәлне кылырга өнди — ул мөселманнарны кяферләргә каршы берләшергә, кулга корал тотып, дин өчен, ирек өчен изге сугышка күтәрелергә чакыра: «Әй, мөэминнәр вә әй, мәүхидләр! Әй, егетләр вә, әй, карилар! Әй, атлылар вә әй, җәяүлеләр! Коралланыгыз! Чыгыгыз, җиһад кылыгыз! Малларыгыз вә тәннәрегез белән Аллаһның әмеренә буйсыныгыз!» — дип яза Батырша хәзрәт, халыкны кяферләргә каршы изге сугышка чакырып.

Шушы иң җитди сүзен әйткәннән соң, Батырша хәзрәт тагы Коръәнгә мөрәҗәгать итә, әйткәннәрен шәригать белән дәлилли. Ул бу урында «Тәүбә» сүрәсенең 41нче аятенә таяна, Коръәннең «Җиңел күрсәгез дә, авыр күрсәгез дә, сугышка чыгыгыз вә Аллаһ юлында малыгыз, җаныгыз белән сугышыгыз! Бу сугышта сезгә яхшылык бар, әгәр белсәгез», дигән сүзләрен дәлил итә. Батырша хәзрәт кяферләрнең күп булып күренүеннән курыкмаска куша. «Аллаһ ярдәм бирсә, сезне җиңүче булмас, Аллаһ сезне җиңелүгә дучар итсә, кем сезгә Аннан башка ярдәмче булыр?» — ди. «Безгә кяфер рус белән көрәшү һәм сугышу тиеш, аның гаскәре күплегеннән хәвефләнеп, җиһадтан баш тартмыйбыз», — дип яза.

Шулай итеп, ислам әһеле, галимнәр, күрше казах-кыргыз халкы белән киңәшкәннән соң, күтәрелешнең вакыты билгеләнә — шул елның гает бәйрәменнән соң, ягъни 1755 елның 3 июле. Бу хакта дүрт юл халкына хәбәрләр җибәрелә, аңлату, әзерлек эшләре башлана. Батырша хәзрәт, яу башы буларак, үзенең өндәмәсендә үк бу көрәшнең стратегик максатларын һәм тактик алымнарын билгели. Төп максат — Идел-Урал мөселманнары берләшеп, бу җирләрдән баскынчы

русларны куып чыгару, биредә яңадан мөселман-татар дәүләтен торгызу, кяферләрнең Урта Азиягә һәм казах далаларына таралуын, экспанциясен туктату. Яуның тактик алымнары — руслар бу әзерлекне сизеп алып, гаскәр җибәрсәләр, теләсә кайсы вакытта аларга каршы күтәрелергә әзер булу, нинди хәлдә дә мөселманнарга берберләрен ташламау, монафикълар коткысына бирелмәү, рус яклы сатлыкларга каршы көрәшү... Батырша хәзрәт мөселманнарның бу рәвешле берләшә алуларын зур дәүләт дип саный, аларны биргән вәгъдәдә нык торырга чакыра, күңелләрен дәртләндерер өчен, Хәлифәттән ярдәм килүен дә өметләнеп хәбәр итә: «Әй, мөэминнәр, җиһад итегез! Җиһад итегез! Мөселманнарның шулкадәр серләшеп, киңәшеп, иттифак итеп вәгъдә куешуларын казаныш һәм дәүләт икәнен белегез! Ничә еллар берләшә һәм серләшә алмаган мөселманнар берләштеләр. Бу дәүләтне вә бу ганимәтне заиг итмәгез, ягъни, мөмкинлекне әрәм итмәгез вә кулын көйдермәгез... Тагы икенче мәртәбә киңәшеп, гәһедләр куешканчы, әллә нинди фетнәләр пәйда булыр...»

Өндәмәдән күренгәнчә, Батырша хәзрәт Идел-Урал арасында басып алучы русларга каршы мөселманнарны берләштереп, изге сугыш башлап җибәрергә чакыра, шуңа фәтва бирә. Бу зур эштә ул халык белән дә, дин әһелләре белән дә киңәшә.

Кайбер галимнәрнең исбатларга тырышуынча, Батырша явы, имеш, икътисади максатлар гына куйган. Бу фикерне бигрәк тә Батырша явының милли һәм дини якларын күрергә теләмәгән рус тарихчылары язып килде. Коммунистлар заманы өчен дә мөселманнарның ирек өчен көрәшенә социаль-икътисади төсмер бирү кулай иде, шушы ук ялгыш юлдан кайбер татар-башкорт галимнәре дә китте. Бүген дә әле тарихчылар арасында Батырша күтәрелешен тоз өчен көрәшкә генә кайтарып калдырырга тырышучылар бар. Бу, нигездә, ялгыш фикер, чөнки өндәмәдән күренгәнчә, Идел-Урал халыклары үзләренең дини һәм милли бәйсезлекләре өчен Россия империясенә, баскынчы русларга каршы изге көрәшкә күтәрелгәннәр.

Кызганычка каршы, Батырша явы империя гаскәрләре тарафыннан явызларча бастырыла, русларга ярдәмгә җирле халыкларның сатлык түрәләре килә. Батырша хәзрәт куйган олы максатларны ислам диненнән ерак торган кайбер җирле кабиләләр, бигрәк тә башкортлар, аңлап бетермиләр, җиһад урынына байларны таларга тотыналар, шул сәбәпле өсләренә кара болыт кебек рус гаскәрен китерәләр... Кызганычка каршы, геополитик җирлектә дә барысы да Батырша хәзрәт кисәткәнчә килеп чыга, Идел-Урал халыкларын канга батырып, аларны файдаланып, Россия империясе Урта Азиягә, казах далаларына үтеп керә... Батырша күтәрелеше җиңелүгә дучар була, Батырша хәзрәт һәм аның якыннары коточкыч җәзаларга тартылалар, әмма алар бу дөньядан Идел-Урал халыклары өчен тиңсез батырлык эшләп китәләр. Батырша мулла үз гомере бәрабәренә Идел-Уралны ахыргача чукындырудан саклап кала, халыкка хакыйкатьне аңлатып өлгерә. Империягә каршы яңа яуларга яңа көрәшчеләр әзерләп калдыра... Бу вакыйгалар үтеп, 20 елдан соң Пугачёв явының нәкъ менә аның туган якларында — Уралда башланып китүе, бу көрәшнең бөтен Идел-Уралга таралып, татар явына әйләнүе, Батырша шәкертләренең, кулга корал алып, Казанны руслардан коткарырга килүе ул башлаган җиһадның дәвам итүен күрсәтә...

Дәвамы киләсе саннарда

ГАЗИЗӘ СӘМИТОВАНЫҢ ТУУЫНА 150 ЕЛ

«МИН БЕРЕНЧЕ ЧӘЧӘКЛӘРНЕ ЭЗЛИМ...»

РӘДИФ ГАТАШ,
Татарстанның халык шагыйре,
Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты

БЕРЕНЧЕ ШАГЫЙРӘБЕЗ КЕМ ИКӘН БЕЗНЕҢ? УЗГАН ГАСЫРНЫҢ 60-70 НЧЕ ЕЛЛАРЫНДА, ӘЛЕ ҮЗЕМ ДӘ ЯШЬ ШАГЫЙРЬ САНАЛГАНДА, ШУНДЫЙ СОРАУГА ҖАВАП ЭЗЛӘҮ ХАЛӘТЕ КИЧЕРГӘН ИДЕМ МИН.

Бу — 1967 елның гыйнвар санында «Казан утлары» журналында басылган бер шигырьне укыгач булды. Нәкый агабыз Исәнбәт публикациясе иде ул: «Бу шигырьнең шагыйрәсе кем? (XVIII гасыр поэзиясе үрнәкләреннән)» — дип бирелгән бу «илаһи бәеттә», тәгаен, Лука Канашевичлар тарафыннан Себергә сөрелгән бер кеше (кайбер строфалардан хатын-кыз дип тә аңларга була, соңрак тикшерүчеләр аның Казан мулласы Ишбулат икәнен ачыкладылар) язмышы чагылдырылган.

Казаннан килгән солдатның
Сачкенәсе лә төрмәдер
[төргән, үргән].
Казанда булган туфрак
Күзгенәмә лә сөрмәдер.
Казан да дигән хуш шәһәр
Бездән лә калды күп йырак.
Казанда булган җаннардан
Арада булды әлфирак.

Аннан әлеге шигырьдә дин юлында иң башлап хак пәйгамбәрне яклаган җефете хәзрәти Хәдичә, барча үксезләр анасы Миһербан һ.б. телгә алына. Һичшиксез, биредә Тубылга куылган мулланың төрмә-крепостьта хатынын, балаларын сагынуы чагыла. Әмма әсәрнең авторы хатын-кыз булуын өзеп әйтә алмыйбыз. Авторы билгесез әсәрләр рәтендә аны Х.Госман белән З.Максудова да, ниһаять, безнең көннәрдә Марсель Әхмәтҗанов та «XVIII гасыр әдәбияты. Поэзия, 2006» исемле тансык, бик кыйммәтле ядкәрләр, күп яңа исемнәрне һәм исемсез шигъри иҗатны эченә алган мәҗмугасында бастырып чыгардылар. Чыннан да, илаһи бәет шул бу кадерле әдәби ядкәребез!

Бу шигырьне уку тәэсире белән мин фәкыйрь дә шундый бер тезмә язып куйган идем. Гаеп итмәсәгез, аны биредә игътибарыгызга тәкъдим дә итәргә батырчылык иттем:

Нинди көчләр белән ясалдың син,
Татар кызы җаның
Шигъри хыял дөньясына илткән
Бөек рухи адым?!
Куркытулы сүзләр — каргыш,
язмыш —
Кануннарны таптап,
Изге йортка килгәнме Ил кызы,
Пәрәнҗәсен ташлап?!

Корбан сораганга кырыс дөнья,
Гүя җебен кисеп,
Ул калдырган шәхси бәхетен дә, —
Бай хәситә итеп...
Ул калдырган шатлык-уеннарын,
Халкын хаклап, чорга
Ул аваздаш иткән нечкә хисен
Моң дөньясы — Җырга...
Шундый булгандыр, дим,
кыю адым —
Изге ул хатирә.
...Ядымда гел дога укыр идем,
Кемгә дип әйтергә? —
Исемеңне нигә калдырмадың,
Беренче шагыйрә?!

Әйе, еш килә күңелгә беренче шагыйрә турындагы уй. Әдәбият тарихы китапларын актарам, фольклор әсәрләрен — авторы, әлбәттә, билгесез җырларны, бәетләрне хәтердән үткәрәм... XIX гасыр ахырында бергәбергә Казан, Себер, Әстерхан, Сембер һ.б. төрле төбәкләрдә пәйда була хатын-кыз әдибәләр, шагыйрәләребез. Күп еллар дәвамында галим Мөхәммәт Гайнуллин җыеп чыгарган «Өмит йолдызлары»быз болар. Мәгърифәтче, белемгә омтылган, хатын-кыз азатлыгын, ирләр белән тигез хокукын яклаган Галимәтелбану Биктимерова, Хәнифә Гыйсмәтуллина, Галимә Рәхмәтуллина, Хәбирә Насыйрия (Каюм бабаның энесенең кызы), һәм, әлбәттә, бик тә үзенчәлекле, талантлы шагыйрәбез Газизә Сәмитова (1862-1929)... Бу әдибәләрнең хикәя, шигырь китаплары, сүзлекләр бастырып чыгаруы мәгълүм. Әлеге уяну дәверенең беренче чәчәкләре! Г.Биктимерова, бер шигырендә язганча, 1905 елның шифалы җилләрен тоя:

Ачылды һәр тараф гөлләр,
Тәганни итә (сайрый. — Р.Г.)
былбыллар.

Әйе, бу — шул чор өметләре һәм алар тиз сүнә; әлеге саналган әдибәләр үзләре дә кыска гомерле була (Газизә апабыз Сәмитова гына 1929 елга кадәр яши). Әмма аларга алмашка Мозаффарияләр, Гыйффәт туташлар (З.Бурнашева, Сания Гыйффәт), Зәйнәп Сәгыйдәләр үсеп чыгасы зәминне әзерләячәк чын милләт аналары мәйданга килә. Болар — милләтнең олуг хатын-кызлары. Болар — Зөһрә Акчурина, Фатиха Аито-

ва, Ләбибә Хөсәения һәм Фатыймаи-Фәридәләр, Мөхлисә Бубыйлар... Һәммәсе романнарга, дастаннарга лаек затлар, чын ил-милләт кызлары болар!

Риза казый Фәхретдиннең «Мәшһүр ханымнар» китабы белән рухланып, 1907 елда «Әльислах»та шул исемдә шигырь бастырган, хатын-кызларга игътибар, мәхәббәт таләп иткән Маһруй Мозаффарияне хәтерлик. Һәм аның шигыреннән рухланып, яшәүгә, милләтнең көченә ышанычы артып, «Юк, үлмим, торам әле» дигән мәкалә һәм шигырь язып газетта чыгарган Сәгыйть Рәмиевне... Мин дә шул мәшһүр шагыйребез хәлендә: «Шәхесләребез» сериясендә чыккан «Милләт аналары» исемле китап тәэсиреннән айный алмый йөрим... Һәм беренче шагыйрәләребезне уйлыйм.

Әйе, чыннан да, кем булган бездә беренче шагыйрә? Гомумтөрки әдәби телендә «дәуран сөргән» чордан эзләргәме аны? Чичәнбикәләр дә булган, хәтта хәзер дә бар бит. Ә татар-төркиләренең Хәрәзем, Дәһлиләрдә яшәп иҗат иткән Надирә, Зәбунниса кебек атаклы солтан, хан кызлары, чын шагыйрәләре? Ә безнең Сөембикә? Ул да — иркен дала халкы, күңел иҗаты белән бергә зур белемгә ия булган олуг зат.

Шигырь язмаган дисезме аны? Ә соң аның Сафагәрәй хан төрбәсендә сыктау-елау сүзләре чын шигърият түгелмени? Романында Рабит Батулла да аны икеләнмичә шагыйрә итеп күрә. Ә Казандагы сарай мохите? Мөхәммәдьярлар, Кол Шәрифләр? Нугай һәм Кырымның солтанатлы бикәләре дә бу җәһәттән үз заманының шигърият гашыйклары булган, мөгаен... Кайсы хәрабәләр астында йә кайсы мәмләкәтләрнең китапханәсендә аларның мирасы? Хәер, Әстерхан өлкәсе Ташлыяр авылында туып, шунда яшәгән (бабалары Казан-Тәтеш ягы кешеләре) Газизә Сәмитова әсәрләре дә Ленинград (Петербург) кулъязмалар институтында сакланган дәфтәрләре аша безгә 1965 елда гына китап булып килеп иреште. Аны өйрәнеп, төзеп, мәкалә язып, дөньяга чыгаручы галим Җәвад Алмаз рухына тагын бер дога барсын, рухы шат булсын ул күпне кичергән гали затның!

Ә Газизә Сәмитова — әлегә безгә билгеле «беренчеләр»дән булган, XIX гасырның соңгы чирегендә иҗат иткән шагыйрәбез — безнең күңелләрдә аның кабатланмас рухи һәйкәле торырга хаклы...

Мәгърифәтче, аңга, белемгә өндәгән, «изгегә тарткан» каләмгә дан җырлаган, төрле телләр өйрәнүгә ирешкән, әмма «төркем (төрки телем, язуым мәгънәсендә) барга күркем бар» дип ышанган шагыйрә үзенең шәхси тормышын, язмышын, мәхәббәтен дә чын шигърият әсәрләре биеклегенә күтәрә алган. Кыскалык, төгәллек һәм халык җырлары, мәкальләреннән килгән тел-сурәт чаралары Газизә апабыз иҗатын калку итеп күрсәтә. Халыкчан сүз үрнәге дисәң дә ярый. Бу яктан ул Кандалый бабабызга да якын. Әйтерсең лә Сәхибҗамал үзе кулына каләм алган, «гашыйк мелла»га җавапнамәләр, үгетнамәләр яза!

Агыйделнең агын җирендә
Ак та балыкларга азык юк.
Үзем шәригатьнең юлын беләм,
Хәсрәт күп күргәнгә язык юк.

Кандалый белән якын фикердәшлек менә бу шигырь юлларында да табигый үрелеп килә:

Вакыт берлә табу мөмкин
Көмеш, алтын вә якутны.
Якутны күпме сарыф итсәң дә,
Табып булмас бу вакытны!
Ә сабырлыкны ничек данлый ул!
Сабырлы баш сәламәтдер,
и дуслар!
Сабыр — гүзәл галәмәттер,
и дуслар!

Укучыларыбызны Газизә апабызның шигырьләренә ешрак күз салырга чакырасы килә. Моннан йөз егерме еллар элек язылган шигырьләр бүген дә бик ышанычлы, матур яңгырый, ихласлык белән, хатын-кызга хас кабатланмас аһәңнәр белән яраттыра. Дәвам ителәме соң бүген аның традицияләре? Һичшиксез! Менә алдымда бер яңа яшь шагыйрәнең китабы. Шуннан юллар китерәм, үземә ошаган мисаллар, хатын-кыз кичереше мизгелләрен.

...И, Ходаем,
Пар канатлы
Сабырлык бир!

Яки:

Нигә шулай бөтен нәрсә
Синең хакта сөйли?!
Бөтен дөнья сине сөйли —
Ничек түзим сөйми?!

Һәм менә бу юлларны укыйк:

Бу дөньяда бүген тик икәү без,
Җилләр тынган, вакыт туктаган.
Табигать тын. Димәк, мәхәббәтне
Кешелек һәм Ходай хуплаган.

Ничек битараф калып булсын мондый халәткә, мондый шигъри югарылыктагы Сөюгә?! Ә менә бу юллар?

Ник минем иң керсез хисләрем
Ялганга, мәкергә ялганган?
Мин генә түгел бит, ялганга
Мәхәббәт Аллам да алданган...

Һәм менә шигъри яшьлек чәчәкләренең җимешле җәйгә күчүен күреп, уллары белән аларның атасы — ире биргән гаилә бәхетен тирән кичереп, сөенеп (Ә Газизә апаныкы алай булмаган, гел беренче сөйгәнен сагынып яшәгән ул!), хатын-кызның тормыштагы урынын, язмышын билгеләүдә кызыклы нәтиҗәләр дә ясап куя бу тумыштан ук шагыйрә булып яратылган яшь ханым: мин тетрәнеп укыдым бу юлларны!

Мин беркем дә түгел,
Тик яклаучы ир-ат хакын.
Ирем — батыр. Ирем — алтын,
Ә мин — җылы учакларга
Ялкын өстәп торыр хатын.

Мин беркем дә түгел,
Бары ике улым-бөркетемә әни генә!
Язучы да түгел... хатын гына,
әни генә.
Ә бәлки бу иң мөһимедер,
Кемнәр белә?!

Тормыш җитеш булу, канәгатьлек, туклык кына тудыра алмас иде бу юлларны. Мөгаен, бу да шагыйрәләр һәм халык язмышы турында төрле чорда, төрле ситуацияләрдә, ракурсларда карап, күреп, уйлануның бер чагылышы. Моны югарыда китабыннан без өзекләр китергән Эльмира Җәлилова да раслый, безнеңчә: Милли Әнкә җаны бу! «Икебезгә бер гомер» дип атала аның китабы. Мәгънәле исем!

Ә шагыйрәләр гомере, иҗаты, күңел дөньясы, гомумән, гыйбрәтле, бай һәм төрле. Газизә апабыздан башлап бүгенге күренекле шагыйрәләребезнең һәммәсен дә күзәтеп, сөенеп укып баручы буларак әйтәм моны. Хис һәм фикер чишмәсе һич тә кибәсе юк аларның, чөнки гүзәл затларыбызның үз йөрәкләрендә тибеп, җыр булып бәреп чыга ул. Күп алар, талантлы шагыйрәләрне һаман тудыра тора халкым.

Ә бүген дога белән 150 яшьлек шагыйрәбезне яд итәм: «Мин беренче чәчәкләрне эзлим...»

Редакциядән: *Хөрмәтле укучыларыбыз! Сезне алдагы саннарыбызда «Хатын-кыз шагыйрәләребез» дигән өр-яңа сәхифә белән таныштырырга уйлыйбыз. Сәхифәне Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Р.Гаташ алып барачак.* ■

«ЛАЕКЛЫ БУЛЫЙК БЕЗ БУ ЯКТЫ ЗАМАНГА...»

(Хәйдәр Гайнетдин иҗатына күзәтү)

НУРФИЯ ЮСУПОВА,
филология фәннәре кандидаты,
Казан (Идел буе) федераль университеты доценты

Татар әдәбияты гаять бай, үзенчәлекле һәм күптөрле, мин аны төрле төстәге асылташлардан җыелган гәрәбәдәй күз алдыма китерәм. Алар арасында һәрвакыт истә тотылып, әсәрләре даими укылып, тикшерелеп-бәяләнеп торган әдипләр-асылташлар белән янәшәдә объектив һәм субъектив сәбәпләр нәтиҗәсендә игътибар үзәгеннән читтәрәк калган, әдәби тәнкыйтьтә үз бәясен алмаган иҗатлар да бар. Вакытсыз арабыздан киткәннән соң, шәхесе дә, әсәрләре дә күләгәдә калган Хәйдәр Гайнетдинов иҗатын мин шундыйлар рәтенә кертер идем. Вакытлы матбугат битләрендә дөнья күргән мәкаләләрдә иҗатының читтә калуы, фәнни басмаларда да исеме, иҗаты искә алынмау, зур китапханәләрдән дә шигырь җыентыкларын табып булмау һ.б. бу фикерне куәтли...

Хәйдәр Гайфетдин улы Гайнетдинов (1952-2000) 1952 елның 27 ноябрендә Татарстанның Зәй районы Дүрт Мунча авылында туа. Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, бер ел колхозда эшләп чыныккан егет, тормышта үз юлын эзләп, Казан дәүләт университетына килә, 1971-1976 елларда татар филологиясе бүлегендә белем ала. Әдәби белемен һәм багажын тирәнәйтү максатыннан, 1989 елда Мәскәүдә Әдәбият институты каршындагы Югары әдәби курсларны тәмамлый. Шуннан соңгы гомерен ул тулысынча журналистикага һәм әдәби иҗатка багышлый.

Хәйдәр Гайнетдинов (Хәйдәр) әдәбият мәйданына җитмешенче елларда аяк баса. 1974 елдан республика

матбугатында әсәрләрен бастыра башлый, лирик шигырьләрен һәм «Иске кара урман» поэмасын туплаган беренче җыентыгы «Ут теле» исеме белән 1982 елда дөнья күрә. Күләме ягыннан зур булмаган иҗатында ул татар шигъриятен лирик шигырьләргә, поэма һәм балладаларга баета, хикәя һәм повестьлары белән проза өлкәсендә үзен сынап карый. Шулай да аның каләме шигърияттә үткенрәк, әлеге мәкалә кысаларында да без аның лирик иҗатына тукталырбыз.

Хәйдәрнең лирикасы тема, мотивлар, жанрлар төрлелеге ягыннан да, образ-детальләрне төрле мәгънәләрдә «уйнату»ы белән дә үзгә һәм кызыклы. Лирик шигырьләрендә өч тип лирик герой күзәтелә. Берсе — мәхәббәттән, туган ягыннан җылы эзләүче, табигать һәм яшәештәге матурлыкка сокланучы лирик, икенчесе — заман шаукымына хас төстә ил халкының батырлыгына сокланучы патриот, өченчесе — гомер язын узып баручы, тормыштагы яшәеш каннунарын эзләүче философ-герой. Алар төрле жанрларга караган әсәрләрдә формалаша һәм әсәрдән-әсәргә үсеш-үзгәрештә бирелә.

Гражданлык лирикасына мөнәсәбәтле күтәренке пафос, оптимистик рух белән өртелгән әсәрләрендә сугыш авырлыкларын, үз башына төшкән төрле бәла-казаларны җиңеп чыккан, язмыш сынауларын лаеклы кичкән халык, ил образы пәйда була. «Хөкем», «Солдат абый белән тиктормас малай турында хикәятләр» һ.б. шигырьләре, «Исем», «Хушлашу» кебек балладалары солдатның, сугыш вакыйгаларында һәлак булганнарның кичерешләрен үзәккә ала. Мәсәлән, «Исем» балладасының сюжет нигезенә Бөек Ватан сугышы белән бәйле вакыйгалар салына, сугыш кырында батырлык күрсәткән пионер малайларның тиңдәшсез батырлыгына дан җырлана. Шуңа бәйле төстә балладаның хис-кичереш дулкыны да горурлану һәм соклану, мәхәббәт һәм нәфрәт хисләренең алышынып, үзгәреп торуына көйләнә. Илгә хезмәт итү эзсез югалмый, ил өчен үлгәннәрнең исеме үлемсез, халык хәтерендә мәңге яши дигән чорга авазлаш фикер әсәрне үтәли кисеп бара. Бу юнәлештәге шигырьләр җиңүче солдатны югары күтәрә, тыныч тормышны данлый, лирик герой җиңүче ил халкы белән горурланучы, тормышны ятаучы буларак чыгыш ясый.

Шигъри иҗатының үзәгендә торган күңел лирикасы үрнәкләре шагыйрьнең үз тормышына бәйле мизгелләрне тергезә, югалту-табышларга бәйле хис-тойгыларын, хыял-омтылышларын укучыга җиткерә, хисләрнең үсеп-үзгәреп торуына омтыла. Шуңа мөнәсәбәтле Хәйдәрнең бу жанрга караган әсәрләрендә лирик герой белән авторның якынаю сыйфаты алга чыга, лирик мин саф мәхәббәткә омтылучы, табигать һәм яшәештәге матурлыкка сокланучы булып формалаша. Мондый типтагы шигырьләрдә лирик геройга хас хис-тойгыларның табигать күренешләре белән янәшәлектә ачылуы күзәтелә. Хис-тойгының гомумиләшүе юану өлешендә бирелгән яшәеш, мәхәббәт хакындагы уйлануларда, тормышка кагылышлы фикерләрдә чагыла.

Шагыйрьнең күңел лирикасында табигый төстә мәхәббәт темасына еш мөрәҗәгать ителә, ул бер төркем мотивлар аша ачыклана: яшьлекнең садәлеге, мәхәббәтнең иң зур кыйммәт, яшәү мәгънәсе булуы һәм яшәештә илһам табу. Әлеге мотивлар «Без очабыз», «Ишеттем ерактан...», «Яшим хәзер үткәннәрдә...», «Ямьле алан...», «Куенымда идең...», «Хыял иле...», «Ә кайчандыр...», «Шаулый һаман колагымда...», «Көн яктысы калган күзләреңдә...» һ.б. шигырьләрнең үзәгендә ята. Мәсәлән, сагыш хисенең үсеш-үзгәрешенә корылган «Ишеттем ерактан...» шигыренә күз салсак, сөйгән ярын югалткан, яралы күңелен юатып яшәргә мәҗбүр лирик

герой сызлануы белән очрашабыз. Сөйгәненә мөнәсәбәтле берничә символик образ-деталь аркылы мәхәббәткә бәйле фикерләр белдерелә, алар исә лирик геройның каршылыклы халәтен төгәлләштерә. Беренче-икенче строфаларда сагышның сәбәбе — яратып та, мәхәббәтенең кабул ителмәвендә булса, өченче строфада көрешә алмау мөмкинлеге, кеше гомеренең чиклелеге кебек үзгәрә. Беренче-икенче строфаларда айлы чәчәк — мәхәббәтнең җылысы, назы, миләш-баланнар — юлны яктыртучылар, күз нурлары — яратуның кайнарлыгы булып төгәлләшә. Шулар аша мәхәббәт кеше җанында саклана торган иң илаһи төшенчә югарылыгына күтәрелә. Соңгы строфадагы *«Күчкән булыр, бәлки, яңгырларга, — йөгереп чык та сөенәсөенә чылан!..»* юллары шигырьне ирреаль эчтәлек белән баета. Шигырьдә автор позициясе бу дөньяга килгән һәркем гомер юлында мәхәббәт хисенә лаек дигән фикер булып гомумиләшә: *«Бу юллардан узу насыйп булса, / Һәркем яраталыр минем сыман».*

Күңел лирикасы әниләр, авыл, туган як темаларына да еш мөрәҗәгать итә, лирик геройның яшьлегендә калган авыл хатирәләре, туган ягындагы вакыйга-халәтләр кичерешнең сәбәбенә әверелә. Бу темага язылган лирик әсәрләр еш кына гомумкешелек кыйммәтләре, яшәү мәгънәсе турында уйланулар белән үрелеп бара. Шагыйрьнең «Барып кайт син туган якларыма…», «Авырып ятканда», «Йөгерә дулкын-дулкын булып…», «Тургай рәсеме» һ.б. шигырьләрендә үткәннәрнең якты хатирәсен саклаган авыл, изге туган җир образы пәйда була, яшьлекнең үтүе, кире кайта алмау, якты көннәрне сагыну, чарасызлык — барысы бергә кушылып, сагыш хисен тудыра.

Туган як темасына караган «Барып кайт син туган якларыма…» шигырендә болын, дога укучы кошлар, аккош итеп очыручы күлләр, мендәр кебек ташлар, җиләк-җимеш белән сыйлаучы урман кебек образ-детальләр ярдәмендә туган якны ярату тойгысы күз алдына килеп баса, образ-детальләр туган якның кеше өчен иң кадерле һәм газиз җир булуын укучыга җиткерә, аны изгеләштерә. Бу чор шигъриятендә, гомумән, авыл кешесен идеаллаштыру, яшәешен әхлакый камиллек югарылыгына күтәрү, табигать белән тыгыз бәйләнешен, табигыйлеген ассызыклау мотивлары күзәтелә. Әлеге шигырь кысаларында да кеше изге туган җиренә лаек булып яши алырга тиеш дигән идея-фикер аерылып чыга:

Әйләнеп кил минем туган яктан,
«Нинди кеше син?» — дип сорама.
Туган якларыма лаек булыр
Изгелекләр миндә юк икән,
Кешегә дә хәтта санама!

Шигырьдән-шигырьгә кошлар образына мөрәҗәгать ителә, еш кына күпмәгънәле метафора дәрәҗәсендә кулланылган тургай образы, аның сайравы, моңы туган як матурлыгын җиткерә, бер үк вакытта лирик геройның туган җиренә мәхәббәте дә, читтә яшәүче кешенең күңелендәге моң халәте дә булып укыла һәм туган җиргә мәдхия җырлауга кушыла. Аерым шигырьләрдә тургай образы татар поэзиясен яңа эчтәлек белән баета. Мәсәлән, «Үз гомерендә бу дөньяның…» шигырендә үзенчәлекле сурәт тудырыла: тургай — ялгызлыктан ямь тапмаган җан антиномиясендә тургай кеше җанын чистартучы мәгънәсен ала. Соңгы строфада кабатланган «Тургай моңы юды күңелемне» тезмәсенең сабыйлык белән янәшәлектә бирелүе әлеге фикерне тагын да көчәйтә.

Мондый юнәлештәге шигырьләрдә традицион образларга әверелгән сандугач, каен, чәчәк, йолдыз образларына, төсләр символикасына, табигать күренешләренә, ел фасылларына

еш мөрәҗәгать ителә. Автор аларны төрле мәгънәләрдә «уйнатырга» ярата. Мәсәлән, каен — сагыш, каен — мәхәббәт, чәчәк — сөю янәшәлекләре шундыйлардан. Сары, зәңгәр һәм ак төсләр Хәйдәр иң яратып мөрәҗәгать иткән төсләр булып аерылып чыга. Шушы юлда ак төс / ак кар, күңел аклыгы, сөю аклыгы янәшәлекләре пәйда була, сары төс сагыш, мәхәббәтне югалтудан туган үкенү, үткәннәрнең хатирәсе билгесенә әверелә, зәңгәр төс — хыял, теләк-омтылышлар, яшьлек мәхәббәте булып төгәлләшә. Көз / гомер көзе, мәхәббәтнең көзе, яшьлекнең көзе, яз / яшьлек, мәхәббәтнең кайнар чагы, күңел язы янәшәлекләре лирик герой гомеренең төрле этапларын һәм халәтләрен чагылдыра.

Х.Гайнетдиновның бер төркем шигырьләрендә яшәү мәгънәсенә, яшәү кыйммәтенә, иҗатка мөнәсәбәтле уйланулар алга чыга. Мәсәлән, «Төнге карлар керә тәрәзәдән...» шигырендә күңел уты иҗат, шигърият символы итеп бирелә. Шатлык-кайгы оппозициясе лирик герой үзе яшәгән һәм хыялында яшәткән дөнья каршылыгын төгәлләштерә, иҗатның тормыш авырлыкларын да шатлык кебек кабул итәргә ярдәм итүен дәлилли.

«Сискәнеп киттем кояшның...» шигырендә дә яшәешкә мөнәсәбәтле фикерләр тергезелә. Баеган кояш — таң кояшы каршылыгы гомер юлының төрле этапларын төгәлләштереп куя. Кояш баешы, гомер агачыннан өзелгән яфраклар, көз образлары яшьлекнең үтүе тудырган үкенеч хисен үзәккә куя. Шушы контекстта таң кояшы яшьлек белән тәңгәлләшә һәм укучыны бер фикергә алып килә: яшьлек кешегә гомер көзендә дә яшәү көчен, яшәү омтылышын бирә.

Таң кояшына карасам,
Инде беттем дигәндә,
Заманнарны кичәрмен
Күк сыңар көне белән дә!

Әнә шулай Хәйдәр Гайнетдинов, традицион юнәлештә иҗат итеп, татар поэзиясендә үз сүзен әйтә, аны мотивлар, идея-фикерләр белән баета. Шагыйрьнең лирик шигырьләреннән үрнәкләрне сезгә дә тәкъдим итәбез.

ХӘЙДӘР ГАЙНЕТДИН ШИГЫРЬЛӘРЕ

***

Барып кайт син туган якларыма,
болыннарда мөмкин аунарга.
Кошлар сайрап дога кылыр иде,
озын гомер теләп таңнарда.

Суларында коен,
алар бер дә
упкынлы һәм усал түгелләр.
Йөзә белмисеңме?
Аккош итеп
очыртырлар сине бу күлләр.

Әллә нинди каты, җансыз кебек
тоелса да сиңа бу ташлар,
егылсаң да куркып кала күрмә, —
мендәр белән алар адашлар.

Ә карурман сине иң-иң тәмле
җиләк-җимеш белән сыйлар да...
һәм аннары әкрен-әкрен генә
керешер ул әкият сөйләргә.

Әйләнеп кил минем туган яктан,
«Нинди кеше син?» — дип сорама.
Туган якларыма лаек булыр
изгелекләр миндә юк икән,
кешегә дә хәтта санама!

***

Ут йөгергән инде кар астына,
тыңла, әнә, шаулый гөрләвекләр.
Җылы язның зәңгәр күзләредәй
карап тора күккә күлләвекләр.

Эремидер кебек күрер күзгә,
җәйрәп ята әле ак киңлекләр.
Ут йөгергән әмма кар астына,
ташкын булыр —
шундый мөмкинлекләр.
...Яшибез бит без дә тыныч кына,
чыгармыйча эчтә янган утны.
Һәм бер көнне, ярсу ташкын кебек,
актарылып агар сәбәп юкмы?

Бар ул сәбәп, җитә!
Кайбер язлар
сызылып кына килә, шауламыйча.
Кешеләр дә шулай, башын иеп,
яши кайчак берни дауламыйча.

Юанмагыз шулай сабыр гына
яшәрбез, дип, тын да чыгармыйча.
Йөгерсәме ул ут күңеленә —
түзә алмас бәреп чыгалмыйча.

Карасамы кояш җиргә туры —
бирәчәк ул, кышка нык бирәчәк.

Ашкындыра ташып актарылырга
язны — кояш,
безне — ак киләчәк!

***

Хакыйкатьләр авыр канун булды
яңа туган нәни малайга.
Уйга чумып кердек урманнарга,
тавыш-тынсыз йөрдек далада.

Әкиятләрнең назлы куркынычы
яулап алмас булды күңелне...
Шәфәкъ нуры биек тау өстеннән
түгелде дә җиргә түгелде.

Узды дөнья сабый күңел аша,
бураннары үтте сызгырып...
Ярый әле язмыш шундый булган,
салкыннарда калдык чыныгып.

Хыялыйлар булып калдык тагын,
яратсак та хәтта чынлыкны.
Тик
ишетәм һаман
балачактан
ишетелгән теге тынлыкны...

***

Төнге карлар керә тәрәзәдән,
эри-эри.
Гүя яңгыр ява.
Тамчыларга карап алданырсың —
әйтерсең лә тышта җылы һава...
Дөнья керә шулай — җылы сорый,
өметләрне һаман үзенә сава.
Тәрәзәмдә минем төннәр буе
тетри-тетри күңел уты яна.

Шатлык булып керә дөнья миңа,
кайгы булып шакый тәрәзәмне.
Сорый бит ул бары күңел уты —
биреп җибәр аңа шул бәяне.

Шатлыкларын
меңгә тапкырлап бир,
кайгыларын үзгәрт куанычка,
тетрәп янган күңел уты белән
көннәреңнең ялга очын-очка.

Төннәр буе шулай тәрәзәмдә
тетри-тетри күңел уты яна.
Дөнья белән алыш-биреш бара:
яшәвемне түлим бу дөньяга.

***

Болыт көрте күмгән —
күренми дә
күктә балкып яткан кояш юлы.
Табигатькә баккан тәрәзәдән
җәй рәсемен салкын яңгыр юды.

Уңды төсләр спасс яңгырында,
җилләр уйный сары яфрак белән.
Күзләр белән бергә нинди уйлар
уза икән Әнкәй күңеленнән?..

Мин сагышың булып йөрим, Әнкәй,
күңелсездер сиңа ялгыз чакта.
Теге тупыл һаман шаулыйдыр ул,
ямансулык биреп тирә-якка.

Тегермән күк, җилне тарта да ул
шау-шу коя яфрак арасыннан.
Тыңлыйсыңдыр, Әнкәй, тупыл гына
шомлы хәбәр сиңа сөйләр сыман.

Кайгырмачы, Әнкәй, син барында
кояш кына балкый безнең җанда.
Гел кайтырмын, Әнкәй, һәрвакытта
якты шигырь булып синең янга!

***

Сусылулар коена елгаларда,
офыкларда балкый кызгылт урман.
Җилләр исә әле кыйбла яктан,
ә мин барам менә көзге юлдан.

...Сары алма сыман түгәрәк җир,
өзелер дә кояш нурларыннан,
килеп төшәр кышка,
ак буранга...
Мин сискәнеп куям уйларымнан.
Җан җилбәгәй киткән,
бара идем
табигатьнең көзге юлларыннан...

***

Сискәнеп киттем кояшның
баешлы карашыннан...
Яфрак кебек өзелә көннәр
гомерем агачыннан.

Саклап кала алмам, ахры,
көземә дигәннәрен:
яшәячәк көннәремнең
күрәм өзелгәннәрен.

Талгын гына җилдә дә ул
шыбырдап алыр кебек,
коелыр да барча көне
шәп-шәрә калыр кебек.

Таң кояшына карасам,
инде беттем дигәндә,
заманнарны кичәрмен
күк сыңар көне белән дә!

Дусларга

Ни генә күрсәк тә,
юрамыйк яманга.
Лаеклы булыйк без
бу якты заманга.

Юрамыйк язмышка
бәхетсез киләчәк —
болытлы көннәр дә
яшенләп көләчәк.

Табигать кызганмый
биргән бит моңнарны —
ачып сал күңелеңне,
тылсымлы дөньяны.

Яшикче риясыз.
Олы җан каршында
йөрәккә әйләнер
мең еллык ташың да! ■

ӘДИПЛӘРЕБЕЗ МИРАСЫННАН

УРМАНЧЫ КЫЗЫ

ФӘНИС ЯРУЛЛИН,
Татарстанның халык шагыйре,
Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты

Боз китә. Су буе балалар шаушуыннан, агачлар шаулавыннан һәм бер-берләренә бәрелеп шартлап ярылуыннан гөр килеп, шаулап тора. Елгыррак малайлар яр буена килеп туктаган бозларга сикереп менәләр дә, тирес һәм төрле чүп-чар өеп, ут төртеп җибәрәләр. Зурраклары, ятьмәләрен болганчык суга тыга-тыга, балык эләктерү ягын карыйлар. Ә яр өстендә, бераз читтәнрәк өлкәннәр карап тора. Алар берни белән дә мәшгуль түгел, бары тик ярсып-ярсып аккан елганы гына күзәтәләр. Ә бозлар ага да ага. Бер караганда, алар әлсерәгән сарык көтүе кебек тыныч кына торсалар, икенче караганда, ачудан ярсыган дошман гаскәредәй, бертуктаусыз тыныч торган ярларны штурмларга тотыналар, тешләрен ыржайтып, ярларны кимерәләр. Елга ачулы, әйтерсең, ул кыш буе хәрәкәтсез яткан ачуын кемнәндер алырга тели.

Ә ярның теге ягында, зур ялгыз зирек агачын кочаклап, бер кыз басып тора. Аның күзләре моңсу, йөзендә чиксез зур сагыш һәм хәсрәт чагыла. Җил, аның тыгыз, йомры гәүдәсен күтәреп алып китәргә теләгәндәй, шашып-шашып исә. Кысып бәйләгән зәңгәр яулыгы астыннан чыгып торган маңгай чәчләрен тузгыта. Кыз маңгаена төшкән чәчләрен дә рәтләп куймый, әйтерсең, ул ярсып искән җилне дә, үкерешеп аккан бозларны да күрми. Давылда сыгылган яшь каен кебек, аны үз кайгысы сыгып төшергән. Ул елгага карап шатлана алмый, бозлар үзләренең озын тешләрен ярларга китереп батырган саен, кыз да тешләрен кысып куя. Әйтерсең лә бозлар ярларга түгел, ә аның йөрәгенә китереп кадыйлар.

Әйе, аның кайгысы зур. Кызны үлемнән коткарган кешенең гомерен урлады бу елга. Моннан соң кыз бервакытта да табигатьнең бу ярсу көченә тыныч күңел белән карый алмас инде. Быелгы яз аның йөрәгендә төзәлмәс яра калдырды.

Өченчекөн генә әле ул нинди шат, нинди бәхетле иде. Кар астыннан яңа калкып килгән умырзаялар җыеп, букет ясады. Кәкре каен ботагына асылынып, туйганчы атынды, елгалар ерды. Бабасына агачлардан төрле кортлар чүпләшергә ярдәм итте. Инде көн шулай шатлыклы гына үтеп барганда, ул бәхетсезлеккә юлыкты. Берни уйламый йөгерә-йөгерә өенә кайтып килгәндә, карлы чокырга чумды. Чокыр ярыйсы ук тирән, ә төбендә су иде. Кыз озак маташты. Салкыннан тәнен көзән җыерды. Барлык киемнәре манма су булып, аны һаман аска сөйрәделәр. Тотынган саен җепшек кар ишелеп, чыгарга ирек бирмәде. Кыз актык көчен куеп кычкырып җибәрде һәм янындагы бер агачның сузылып торган ботагыннан эләктереп алды.

Салкын кар суы җелекләренә кадәр өшетеп өлгергән иде инде. Ул, дер-дер калтырап, бабасы янына, урман өенә чапты. Ә кичкә таба аның бик нык тәне кызыша башлады. Бабасы кызның тәнен спирт белән ышкыды, җәй көне җыеп киптергән нindидер яфраклар алып кереп, аркасына япты. Болардан соң кыз бераз калтыравыннан туктады, йокымсырап алды. Ләкин аның тынычлыгы озакка сузылмады, бөтен тәнен көзән җыерырга тотынды. Кыз бөтенләй бөреште, тартышты. Бабасы үзенең бердәнбер оныгының үлем белән тартышып ятканын тыныч кына күзәтеп тора алмады, тиз генә якындагы авылга хәбәр итәргә чапты. Иң якын авыл Умарталы авылы иде, ләкин анда барыр өчен елга аркылы чыгарга кирәк, ә елгада боз күтәрелеп тора. Харис бабай үзе өчен кайгырмады, ул мондый елгаларны гына түгел, ун тапкыр зурракларын да кичкәне бар. Ә менә врач бер белмәгән урманчы оныгы өчен күрәләтә үлемгә барырмы соң? Менә шул сорау борчыды аны. Чынлап та, бу бик хаклы борчылу иде. Яз кояшының кайнар карашы астында череп таркалырга торган калын бозлар менә-менә бөтенләй убылып төшәр кебек. Кайбер урыннарда боз өстенә су чыккан да бөтенләй бозы булмагандай агып ята. Харис бабай мондый урыннардан бик сакланып, таягы белән бозның ныклыгын тикшереп кенә атлый. Алай да аягы вакыт-вакыт ярылган боз араларына төшеп киткәли, итек куnычларыннан аягына су үтеп кергән һәм атлаган саен лачтор-лочтыр килеп эчне пошыралар. Харис карт, ниһаять, ярның икенче ягына килеп җитте, итегендәге суны да түгеп тормыйча, авылга ашыкты.

Харис карт турыдан-туры медпунктка юнәлде. Ләкин аның юлы уңышсыз булып чыкты, медпунктта җыештыручы карчыктан башка кеше юк иде.

— Духтырыбыз Каенлыкка китте шул, — диде ул. — Киткәненә ике көн инде, нишләптер кайтып җитә алмый әле. Юллар өзелеп, тоткарланып ятамы?!

— Алай икән! — диде Харис карт көрсенеп. — Инде кая барыйм икән соң?

— Духтыр бик кирәк булса, теге Зарифуллага барып кара, — диде җыештыручы. — Ул, пенсиядә булса да, кеше йомышын аяк астына салып таптамый.

— Аларның өйләре кай тирәдәрәк?

— Моннан әллә ни ерак түгел, чыгу белән калай түбәле йорт, аннан соң рәттән дүрт шифр түбәле, аларны үткәч, тагын алты чүлмәк түбәне үтәсең дә җиденчесе — Зарифулла абзыйлар.

Харис карт, җыештыручы хатын өйрәткән буенча түбәләр санап, Зарифуллаларга китте. Ул килеп кергәндә, карт фельдшер балык тотарга ятьмәләр үреп маташа иде. Аларның бөтен өйләре җеп белән чорналып, үрмәкүч оясына охшап калган. Картны шактый ук җыерчык баскан, ләкин ягымлы йөзендә үз эше белән бик нык мавыгу сизелә. Ул хәтта Харис карт кергәнне сизми дә калды. Ә күреп алгач, аклангән сыман:

— Менә яз җитте бит, балыкка йөрергә иде исәп, — дип куйды. — Хәзер безнең эше карт-корыга шуннан башка эш тә калмады инде.

— Эшләгән кешегә эш бар инде анысы, — диде Харис карт. — Менә мин дә сиңа бик зур йомыш белән килгән идем әле. Кыз чирләп китте. Пунктка барганыем да, духтырлары күрше авылга китеп, кайта алмый ята икән.

— Алай?! — диде Зарифулла, Харисның хәленә кереп. Үзе шунда ук кулына чорналган җепләрне сүтеп ташлады. — Ә соң безнең Микулай фельдшер миңа ачуланмас микән? Аның эшенә тыкшыну була бит бу. Мин бит хәзер правасыз кеше.

Шулвакыт эчке яктан чыгып килүче хатыны сүзгә кушылды.

— Нәрсә сүләнеп торасың инде, кеше анда ут йотып, ярдәм сорарга килгән, ә син правам юк дип маташасың. Кешегә ярдәм итү правасын синнән беркем дә алмаган. Пенсиягә чыктым дип, мич башына менәргә ашыкма әле.

Карчыгының бу сүзләрен ишеткәч, карт бераз рәнҗеп:

— Мин бармыйм дип әйтмәдем бит әле. Бигрәк төптән каера башладың. Минем мич башына менәргә җыенганым юк, — диде. Һәм чуалган җепләрен дә җыештырып тормыйча, җыенырга тотынды.

Ул никтер каушап киткәндәй күренә. Өстенә кияргә дип пальтосын кулына алгач, әллә никадәр җиңнәрен табалмыйча торды. Пальтосын өстенә кигәч, кулындагы бүреген эзләп мәшәләнде. Белмим, нәрсә аны шулай дулкынландыргандыр: бәлки, үзенең тагын кешеләргә кирәклеген тоеп шатланудан каушагандыр. Бәлки, моннан кырык ел элек беренче тапкыр авыруга ярдәм күрсәтергә баруы исенә төшкәндер. Ничек кенә булмасын, карт дулкынланган иде.

Елганы кичү хәвеф-хәтәрсез генә үтте. Харис бабасы карт фельдшер белән килеп кергәндә, Роза, мәк чәчәгедәй кызарып, урын өстендә ята иде. Аз гына башын калкытып карады да тагын да бөркәнебрәк ятты. Чиксез нык калтыраудан кызның тешләре тешкә бәрелеп китә. Калтырануын басар өчен, тешләрен кысып карый, ләкин файдасы тими. Зарифулла, авыруны карар алдыннан, башта бик әйбәтләп сабынлап юынды, операциягә әзерләнгәндәй кат-кат сөртенде, тик шуннан соң гына, ак халатын киеп, кыз янына килде. Авыруның диагнозын ул Харис картның сөйләве буенча ук чамалаган иде. Ләкин тагын җентекләп, ничек авырып китүе турында сорашты, пульсын тыңлады һәм тәненең кайнарлыгын үлчәде. Кызның хәле җитди иде. Кичекмәстән пинициллин ясарга кирәк!

Зарифулла алып килгән медикаментлары арасыннан шприцын табып кайнарга куйды һәм даруларын барларга тотынды. Кечкенә чемоданда үзенә кирәкле даруның булмавын күргәч, карт куркынып китте. Ул берьюлы бөтен нәрсәсен бушатып ташлады. Ләкин пинициллин бик аз, бары берничә мәртәбә укол ясарлык кына алынган иде. Пинициллин урынына карт шуңа охшаш башка шешәләр алган булып чыкты. Карт үзенең гайрәте беткән күзләрен шелтәләп алды. Нишләргә? Кызга дүрт сәгать саен укол ясап торырга кирәк. Ә аның даруы бер көнгә җитәрлек кенә. Кызның ике як үпкәсе дә шешенгән булырга тиеш, кимендә бер атна өзлексез дәваларга кирәк. Больницага җибәрү турында уйларга да мөмкин түгел — елгада боз кутәрелергә тора. Мондый чакта күрәләтә кешене үлемгә җибәрү генә булачак.

Шприц күптән кайнап чыкты, ләкин карт фельдшер артык борчылуыннан аны күрмәде. Бары тик ул турыда Харис карт исенә төшергәч кенә айнып китте. Харис карт аның кинәт бик күңелсезләнеп китүен күргәч, үзенчә юрады: «Розаның хәле бик куркыныч ахры», — дип уйлады ул һәм фельдшерның икенче якка чыккан вакытын туры китереп, ни өчен кинәт борчуга төшүен сорады.

— Кирәкле дарулар алынмаган, — диде фельдшер.

— Алайса мин барып кайтыйм, — диде Харис.

— Син барып берни дә чыгара алмассың шул. Менә үзем дә пинициллин урынына бүтәнне алганмын бит. Ярый әле берничә уколлык булса да пинициллин килгән. Югыйсә килүемнең файдасы шуның кадәр генә булыр иде.

— Алайса нишлибез соң?

— Әлегә берни эшләргә дә кирәкми, — диде фельдшер. — Бер тәүлеккә җитәрлек дару бар. Авыруны врачсыз калдырырга ярамый, ә иртәгә дарулар беткәч, үзем кайтып алырмын.

— Мин боз кузгалганчы сезгә барып килим, — дип карады Харис тагын. Ләкин фельдшер:

— Минем даруларны кеше табарлык кына түгел, — дип каршы төште. Шуның белән бу турыда башка сүз булмады. Карт фельдшер белән Харис төне буе йокламыйча кызны саклап чыктылар. Авыруның хәле куркыныч иде, ул вакыт-вакыт саташып кычкырды яки үзен белештермичә сикереп торды. Бары тик иртәнгә таба гына берике сәгать йоклап алды.

Икенче көнне төштән соңга дару бетте. Тизрәк авылга ашыгырга кирәк иде.

— Мин сине озата барыйм, — диде Харис фельдшерга. — Елганы берүзең кичүе кыен булыр.

— Юк, юк, авыруны ялгыз калдырырга ярамый, — дип каршы төште Зарифулла карт. — Юлны мин үзем дә табармын.

Зарифулла карт, теге якка чыкканда, елганы хәвефсез генә үтте. Өенә кайткач, ул карчыгының әзерләгән чәен дә эчеп тормады, тизрәк юлга ашыкты. Карчыгы аның муенындагы шарфын рәтләп бәйләде, аннан картының өстендәге пальтосына бераз карап торды да:

— Өстеңдәге пальтоңның җылысы калмаган, яңасын ки, хәзер кичке салкын төшәргә тора, — дип картына яңа пальто кидерде.

Зарифулла карт чыгып китте, тышта караңгы төшә башлаган иде инде. Ул елга өстен караңгылык каплаганчы дип ашыга-ашыга атлады. Кызу барганлыктан, йөрәге сикереп-сикереп тибәргә тотынды. Аркасыннан тир бәреп чыкты. Карт пальто төймәләрен ычкындырып җибәрде, болай иткәч, бераз җиңелрәк булып китте. Менә ул, ниһаять, елгага килеп җитте. Язгы кичнең кара канатлары киң елга өстенә җәелгән. Тонык кына су аккан тавыш ишетелә. Вакыт-вакыт бозлар ярылып киткән тавышлар ишетелеп, болай да шомланган күңелгә шом өсти. Зарифулла карт кырыйда гына үсеп утырган бер талны сындырып алды, аны таяк итеп, бозларга төрткәләп алга атлады. Ашыкканлыктанмы, аның еш кына аягы таеп китә. Озын куныч-лы итегеннән су кермәсә дә, пальто итәкләре инде манма су булган. Ул шулай таягы белән карманып, елганың уртасына килеп җитте. Зарарсыз гына моның кадәр юл үткәч, Зарифулла батыраеп китте. Күңеле күтәрелеп, тәне җиңеләеп киткәндәй булды. Хәзер теге як ярга да күп калмады, инде турыга гына барса да куркыныч юктыр. Тизрәк авыру янына урап кайтырга кирәк. Зарифулла карт, беренче тапкыр эшкә чыккан көндәге кебек канатланып, эчке бер җиңеллек белән тиз-тиз бара башлады. Шулвакыт бер аягы чокырга туры килде, Зарифулла карт кинәт кенә бер читкә тайпылды. Ләкин икенче аяк та боз ярыгына кереп китте. Ул талпынып алга атлаган иде, язгы боз кинәт кенә убылып, Зарифулла картны үз эченә йотты. Аның колакчын бүреге генә бозлар өстендә утырып калды. Бөтен елга өстен кара шәүлә каплады.

Харис карт белән Роза аны ул көнне озак көттеләр, ә иртән Харис карт аның бозга ябышып каткан бүреген табып кайтты. Ике көннән боз кузгалды. Бар кеше боз киткәнен карарга су буена төште. Роза да, хәле авыр булуга карамастан, карт фельдшерга соңгы сәламен ирештерер өчен су буена килде. Ул, ялгыз зирек агачын кочаклап, аккан бозларны күзәтә. Тик үкерешеп аккан бозларны да, көләч балаларны да күрми. Күз алдында мөлаем йөзле, аңа иң авыр чакта ярдәм кулы сузган Зарифулла карт тора. Бик күп тапкыр бозлар китәр, бик күп тапкыр язлар килер, ләкин бу яз бервакытта да аның күңеленнән чыкмас. ■



ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР

Соңгы сүзе аның сүзсез иде,
Әмма көчле иде сүзләрдән…

Илдар Юзеев

ИЛЕ БАРНЫҢ ТЕЛЕ БАР

ГҮЗӘЛ НӘБИУЛЛИНА, ЛИЛИЯ ГЫЙЛӘҖЕВА,
филология фәннәре кандидатлары

Үткер сүз, тапкыр сүз — уй бинасы,
Тәмле сүз, татлы сүз — ил йоласы.
Тыңлап кына торса ни булган,
Фикерсез озын сүз — тел зинасы.

***

Иң кирәкле сүз әйтергә
вакыт җитми,
Тел зинасы төп гамәлне оныттыра.

Гамил Афзал

Кеше елан түгел, аның теле агусыз, диләр. Ничек кенә агулы әле! Бер сүз белән кешене аяктан егарга мөмкин. Икенче төрле сүз белән терелтергә була. Телдә — агу, телдә — дару.

***

Ялгыш ычкынган сүзләрдә кешенең әйтергә тиеш тапмаган, әмма чынлыкта уйлаган фикерләре әйтелә.

***

Утыз тештән чыккан сүз утыз авылга тарала.

***

Әгәр ышанмасыннар дисәң, дөресен сөйлә.

***

Гүзәл вәгазь ямьсезрәк әйтелсә дә, матур итеп үтәргә тырыш.

Әхсән Баян

***

Дөньяда кемгә дә газиз һәм үтә ягымлы бердәнбер кешегә генә әйтелә торган бу мөкатдәс сүзне (әни сүзен) сиңа игелек күрсәтә башлаган икенче берәүгә шундый ук садәлек, самими эчкерсезлек белән әйтү, чыннан да, авыр да, уңайсыздадыр ул.

Гурий Тавлин

Туган телен сансызлаган үзе дә сансыз. Иң яманы — ана сөте белән кергән изге, иң күркәм гореф-гадәтләребезне әкренләп югалта баруыбызда. Кеше өчен иң каһәрле, каргышлы язмыш — милли горурлык хисенең үтерелүе.

Мәхмүт Хәсәнов

Туган телне саклау бүгенге көндә кешелек экологиясен саклау дәрәҗәсендә тора. Тел — кеше рухының формасы, эчтәлеге һәм аның яшәү шарты. Тел — рухи экология. Туган телдә — мең еллар буенча гореф-гадәтләр хәзинәсенең сөземтәсе, әдәп һәм әхлак кануннары, мең еллар туктаусыз язылып торган тарихның хакыйкый эчтәлеге.

***

Сүзне төрлечә әйтеп була. Бер үк сүзгә теләсәң — шатлык, теләсәң — кайгы, кирәк чакта ихтирам яисә нәфрәт сыйдырып була. Сүз — шул ук, ә аның тәэсире тулысынча үзгә. Искиткеч нәрсә ул — сүз.

Миргазиян Юныс

Тел нәрсә әйтергә теләмәс.

***

Тел кешене гөл итә,
Тел кешене көл итә.

Кави Латыйп

Сүз — сүзне, сүз күңелне җылыта.

***

Ерык авыздан кирәксез сүзләр коела торган була.

***

Сүз — пычак, яралавың мөмкин.
Сүз — ефәк, ялганлавың ихтимал.

***

Сүзеңнең кадерен белергә теләсәң, телеңнең урынын бел.

Аяз Гыйләҗев

Ана телен оныткан — анасын да оныткан.

***

Тапкыр сүз мәгънәне тапкырлый!

***

Кыеклап әйтсәң дә, турысын әйт.

***

Сакау карга каты каргылдый.

***

Әйтер сүзең юклыкны сиздермәс өчен, озак сөйләргә туры килә.

***

Тыңласыннар дисәң, аз сөйлә,
Ишетсеннәр дисәң — кычкырма...

***

Тапкыр сүз өчен кыска вакыт кирәк — яшен тизлеге белән җавап биргәндә, җиңелрәк туа ул. Дары да тыгыз урында көчлерәк шартлый.

Шәүкәт Галиев

Сүз-гайбәтне ерып чыгу диңгез кичүдән дә авыр икән.

***

Сүз — тамыр. Тамыр корыса —
юк тарих һәм юк гомер.

Саҗидә Сөләйманова

Йөрәкнең беренче дошманы — авыр сүз.

***

Тел астында бал да, агу да була.

***

Бер бүлмәгә җыйналган татарга икенче телдә — урыс телендә сөйләү күпчелекнең күңелендә һәрвакыт каршылык, кирелек һәм шул ук вакытта мескенлек, хокуксызлык тойгысы тудыра.

Нурихан Фәттах

Ядрә булсын, ялкын булсын
һәрбер сүзең —
Дошманыңның шакшы җанын
көйдерерлек.

***

Килереңдә язмыйм дисәң
туган телдән,
Сабыеңа бир син аны туган көннән.

Резеда Вәлиева

Һәр туган тел бөек үзенчә,
Гасырлардан күчкән гасырга,
Саклагыз сез туган телегезне —
Иң зур хәзинә ул асылда.

Илдар Юзеев

Тел бит ул гап-гади аралашу чарасы гына түгел. Тел — тәрбия коралы, тел — идеология коралы да. Бу мәсьәлә шаяруны, кабалануны гафу итми.

***

Теле булмаган кеше образлы фикерли алмый. Ә әдәбият ул — образлы фикерләү.

***

Кешене ямьсез сүз әйтеп төзәтеп булмый.

***

Вәт замана: әнисе урысча белми, баласы татарча белми.

Туфан Миңнуллин ■

*Сәхифә «Дөньяда сүзем калыр» (Татарстан китап нәшрияты, 2012 ел) китабы нигезендә даими алып барыла.

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ ЖЫР ҺӘМ БИЮ АНСАМБЛЕ ОЕШУГА 75 ЕЛ

17-18 декабрь көннәрендә М.Җәлил исемендәге Опера һәм балет театрында Халыклар дуслыгы ордены иясе Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамбле оешуга 75 ел тулу уңаеннан юбилей концертлары булды. Концертның беренче бүлегендә яшь композитор Радик Сәлимов иҗат иткән «Җиде энҗе» этномюзиклы, ә икенче өлештә ансамбльнең алтын фондына кергән җыр һәм биюләр тәкъдим ителде. Тамашачылар Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең халкыбызның бай мирасын саклап калу һәм аны киләчәк буынга җиткерүдә бәһаләп бетергесез хезмәт башкаруына янә бер кат инанды.

ҖИДЕ КИТАП — ҖИДЕ МОГҖИЗА

19 декабрьдә Әлмәт шәһәренең Яшьләр үзәгендә ел дәвамында «Рухият» рухи яңарыш фонды тарафыннан нәшер ителгән җиде китапны тәкъдим итү кичәсе булды. Алар — Г.Галәмованың «Җиләкле җәй», Н.Шәрифуллинның «Соңарган сөю», Ф.Мөхәммәтованың «Яшәү кыйбласы», Д.Асыловның «Җир маеның бар җае», Ш.Җиһангированың «Бәхетең үз кулыңда» дип исемләнгән китаплар һәм И.Актайның чуваш телендә хикәяләр, шигырьләр җыентыгы. Шулай ук танылган мәгърифәтче, дин галиме Р.Фәхреддиннең «Шура» журналында моннан йөз ел чамасы элек дөнья күргән мәкаләләренең «Мәшһүр адәмнәр» дигән китапта тупланып, искәрмәләр белән хәзерге укучыга тәкъдим ителүе дә зур яңалык.

ЯҢА ТАТАР ПЬЕСАСЫ — 2012

22 декабрь көнне Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында тугызынчы мәртәбә «Яңа татар пьесасы» конкурсы җиңүчеләрен бүләкләү тантанасы булды. Тәкъдим ителгән 53 пьесаның 16сы икенче турга үткән, шуларның сигезе призлы урынга чыккан. Беренче урын «Әрем исе» пьесасы авторы Илгиз Зәйнигә, икенче урын «Җенле күл» пьесасы өчен Зөлфәт Хәкимгә бирелде. Ә өченче урынга «Авыр туфрагың җиңел булсын» дигән пьесасы өчен шулай ук Илгиз Зәйни лаек булды. Мәдәният министрлыгы хәзерләгән махсус бүләк «Приют» әсәре өчен Ркаил Зәйдуллага тапшырылды. «Җәмгыять һәм яшьләр» номинациясендә Айгөл Әхмәтгалиеваның «Бәхет агачы» пьесасы иң яхшы әсәр буларак танылды. «Балалар һәм яшүсмерләр өчен» номинациясендә И.Зәйнинең «Кәҗә, Сарык һәм башкалар» әсәре югары бәйләнде. Ә кызыксындыру бүләкләре «Ширзәт белән Гөлшад» пьесасын иҗат иткән Гүзәлия Тархановага, «Күзләр» әсәренең авторы Марат Кәбировка бирелде.

МОСТАФА НОГМАННЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

22 декабрьдә «Күзләрем тик сине эзлиләр», «Онытa алмыйм», «Карлыгандай кара күзләр», «Әниләр», «Киек казлар китә» кебек халкыбыз күңелендә мәңге онытылмас җырлар авторы, тәрҗемәче һәм тел галиме, Казан университеты мөгаллиме Мостафа Ногманның (1912-1976) тууына 100 ел тулды. Шул уңайдан декабрь аенда ТР Язучылар берлегенең Тукай клубында һәм Арча шәһәренең «Казан арты» тарих-этнография музеенда шагыйрьне искә алу кичәләре үтте. Әдәби чараларда әдәбият галимнәре, әдипне якыннан белгән шәхесләр, язучы-шагыйрьләр һәм Арча муниципаль районы Башкарма комитетыннан вәкилләр катнашты. Кичәләрдә шагыйрьнең тормыш юлы, иҗаты турында хәтер-хатирә яңартылды, шигырьләренә иҗат ителгән җырлар яңгырады. Кызганыч ки, заманында радиодан көн саен диярлек җырлары яңгыраган Мостафа Ногманның иҗатына игътибар соңгы елларда шактый сүрелгән. Аның 1982 елдан бирле китаплары да басылып чыкканы юк. ■

ЯҢА КИТАПЛАР

XVIII ЙӨЗ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ: ПРОЗА. — Казан: Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2012. — 444 б. — Тиражы 300 данә.

Билгеле бер дәрәҗәдә иҗтимагый тормышны, тарихи вакыйгаларны үзендә чагылдырып килгән татар әдәбияты гасырлар дәвамында бай мирасын булдырган. Иң әүвәл үзенең фикерләү үзенчәлегенә, тел байлыгына таянып, соңрак көнчыгыш һәм Европа әдәбиятларының традицияләрен берләштергән сүз сәнгатебез хәзинәсендә, кызганыч, бүген дә чишелеш тапмаган мәсьәләләр байтак. Шуларның берсе — борынгы һәм урта гасыр ядкәрләрен хәзерге заман укучысына тәкъдим итү. Үз эчендә XVIII йөз татар әдәбияты үрнәкләрен туплаган әлеге җыентык нәкъ менә шул юнәлештәге бушлыкны тулыландыру максатыннан язылган.

Текстларны басмага галимнәр М.Әхмәтҗанов, М.Гайнетдинов, Н.Исмәгыйлов, Ә.Алиева, Р.Мәрданов, Р.Кадыйров, Б.Яфаров һәм И.Мөстәкыймов әзерләгәннәр. Моннан тыш текстологлар тарафыннан һәрбер текстка тулы искәрмә-шәрехләүләр дә китерелә. Китапта тәкъдим ителгән текстларның бер өлеше төрле басмалар аша укучыга инде таныш булса да, җыентык рәвешендә беренче тапкыр дөнья күрә.

Шуңа да бер җыентыкка тупланган XVIII йөз татар прозасының күркәм үрнәкләре чорны, аның әдәби-мәдәни мохитен, халыкның сәнгати фикерләү үзенчәлекләрен эзлекле күзалларга мөмкинлек бирә.

Эчтәлектән күренгәнчә, китапның бер өлешен юл язмалары тәшкил итә. Мәсәлән, «Мортаза бине Котлыгыш әс-Симети сәяхәтнамәсе», «Исмәгыйль ага сәяхәтнамәсе», «Мөхәммәдәмин сәяхәтнамәсе» һәм XVIII гасыр татар хәрбиенең юлъязмасы. Әлеге әсәрләр — сәяхәтнамә, хаҗнамә жанрында иҗат ителгән беренче үрнәкләр.

Аерым текстлар, әдәби чыганак кына түгел, ә тарихи вакыйгаларны яктырткан чыганак буларак та әһәмиятле. Мисал өчен, Батырша «Гарызнамә»се, «Пугачёв күтәрелешеннән бер чыганак» шундыйлардан. Шулай ук XVII-XVIII гасырларда рус хөкүмәтенең һәм христиан руханиларының ислам динен тупас кысрыклавы, дини көчләүләре дәверендә язылган «Булисның нәсрани динен фәсадә, вәйранә шөругъ иткәне» дигән текст; «Каһарман китабы», Хисаметдин бине Шәрәфетдин Мөслиминең «Тәварихе Болгарийә» дип аталган әсәрләре дә тарихи вакыйгаларны тулырак күз алдына китерүгә, шәрехләүгә, эзләнүләр алып баруга хезмәт итә.

Китапка кергән «Искәндәр Зөлкарнәйен һәм хатын падишаһ хикәйәте», «Энҗеле үрдәк», «Бер мөселманның казыйга барганы», «Хикәйәте Әбүлкасим Басрый» кебек хикәятләр — XVIII йөз татар әдәбиятында кече эпик жанрда иҗат ителгән әсәрләрдән. Соңгы ике әсәр «Мәҗмугы-л-хикәят» исемле кульязма җыентыктан алынган. Әлеге җыентыкта шулай ук XVIII йөз авторларыннан Таҗетдин Ялчыгол һәм Ишнияз бине Ширнияз Хәрәзми иҗатларыннан әсәрләр дә кертелгән.

Мәгълүм ки, борынгы һәм урта гасыр татар әдипләренә көнчыгыш мәдәнияте традицияләренә, ислам дине кануннарына нигезләнеп язу хас. Хрестоматия сәхифәләрендә дини-дидактик характерда язылган күләмле әсәр — «Нәсыйхәте-с-салихин» — заманында халык арасында гаять популярлык казанган китап булган.

Хезмәтне төзүче, кереш сүз авторы М.Әхмәтҗановның «XVIII гасыр татар прозасы томы әдәбиятыбыз тарихы белән кызыксынучыларга файдалы басма булыр, халкыбыз тарихын, мәдәниятен аңлауда бер ачкыч хезмәтен үтәр», — дигән ышанычы акланыр дип өметләнергә кирәк. Китап әдәбиятчы, телче һәм тарихчы галимнәребез өчен кыйммәтле чыганак булыр дип өметләнәм.

Ләйсән Бәдретдинова,
филология фәннәре кандидаты

Индекс 54132